| 44. | Йосыф | 23 |
| 45. | Зау | 25 |
| 46. | Кыйас | 26 |
| 47. | ? | 26 |
| 48. | Гаттар | 27 |
| 49. | Гали | 28 |
| 50. | Җәгъфәр | 29 |
| 51. | Җәлкәй | 29 |
| 52. | Габдел җәлил | 30 |
| 53. | Ресмәткыл | 32 |
| | *VII буын* | |
| 54. | Кунак | 33 |
| 55. | Сөяргыл | 34 |

*Искәрмә.* Шәҗәрә текстының төп нөсхәсе филология фәннәре докторы Марсель Бакировның шәхси архивында саклана.

Шәҗәрәнең кулъязмасы бик начар сакланышлы, кәгазе коңгырт төскә керә язган, берничә кисәккә өзгәләнгән 40×30 см зурлыктагы кәгазьгә имән кайрысыннан ясалган коңгырт кара белән язылган. Язулары уңу, кыршылу, ертылу сәбәпле уку өчен гаять кыен иде. Алар вак кына гарәп хәрефләре белән язылганнар. Шулай да соңыннан архивта табылган икенче текст мәгълүматлары бу иске кулъязма укылышының дөрес булганлыгын күрсәтте.

Бу беренче текстта шәҗәрәнең 1840 елларда язылуы турында бер искәрмә бар иде.

М. Бакировтан алынган шәҗәрә текстының күчермәсе Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 99 колл., 1 тасв., 105 сакл. бер. булып хисаплана.

Икенче текст

Поколенная роспись тарханского рода Манашева.

Бу шәҗәрәне тәсдыйк кыйлган пичәтендәге елы 1800 нче ел 30 июне.

Күчермә алынды һиҗри 1344 – милади 1926 нчы 30 гыйнвар.

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
| | *I буын* | | 13. | Рәмкыл вафат | 7 |
| 1. | Манаш вафат | | 14. | Әхмәт вафат | 8 |
| | *II буын* | | 15 | Абай вафат | 9 |
| 2. | Сөләйман вафат | 1 | 16. | Муса вафат | 9 |
| 3. | Тукай вафат | 1 | | *V буын* | |
| 4. | Пулат вафат | 1 | 17. | Атнагыл вафат | 10 |
| 5. | Киләй вафат | 1 | 18. | Атнагыл вафат | 11 |
| | *III буын* | | 19. | Котманай вафат | 11 |
| 6. | Йосыф вафат | 2 | 20. | Котлыгош вафат | 11 |
| 7. | Кадер вафат | 5 | 21. | Ишмәт | 11 |
| 8. | Котби вафат | 5 | 22. | Ишбулат | 11 |
| 9. | Йәмәк вафат | 5 | 23. | Мөхәммәт вафат | 12 |
| | *IV буын* | | 24. | Уразмәт | 12 |
| 10. | Әхмәт вафат | 6 | 25. | Бигәш | 13 |
| 11. | Дускәй вафат | 6 | 26. | Фәррәх | 14 |
| 12. | Габдулла вафат | 7 | 27. | Әсәкәй вафат | 14 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 28. | Йулдаш | 15 |
| 29. | Йулбарыс | 15 |
| 30. | Имангыл вафат | 16 |
| 31. | Сийәргыл вафат | 17 |
| 32. | Чувай | 18 |
| 33. | Шәриф вафат | 19 |
| 34. | Котби | 20 |
| 35. | Биккол | 20 |
| 36. | Арслан | 21 |
| 37. | Ишкилде | 21 |
| 38. | Ишәле | 21 |
| 39. | Мокан | 22 |
| 40. | Ишти | 22 |
| 41. | Гали | 23 |
| 42. | Госман (Кәшин) | 24 |
| 43. | Миңлебай вафат | 24 |
| 44. | Габделҗәлил вафат | 24 |
| 45. | Кайумбирди | 25 |
| 46. | Хөсәен | 27 |
| 47. | Ишмөхәммәт | 28 |
| 48. | Әлмөхәммәт | 28 |
| | *VI буын* | |
| 49. | Сәйедкыл | 29 |
| 50. | Йармөхәммәт вафат | 30 |
| 51. | Ишмөхәммәт | 30 |
| 52. | Миңнегыл | 30 |
| | *VII буын* | |
| 53. | Исхак | 31 |
| 54. | Собханкыл | 32 |
| 55. | Габбас | 32 |
| 56. | Габдулла | 32 |
| 57. | Габдерәхим | 33 |
| 58. | Чиракай вафат | 34 |
| 59. | Ракай | 34 |
| 60. | Солтанморад | 35 |
| 61. | Йәсикәй | 35 |
| 62. | Солтанбик | 35 |
| 63. | Габделҗаббар | 35 |
| 64. | Сәгыйд | 36 |
| 65. | Эзмәй | 37 |
| 66. | Морат хәзрәт | 38 |
| 67. | Абнай | 39 |
| 68. | Фәйзулла | 40 |
| 69. | Фәтхулла | 40 |
| 70. | Сәгыйд | 4! |
| 71. | Халид | 41 |
| 72. | Габид | 41 |
| 73. | Хәлил | 41 |
| 74. | Бәкер | 42 |
| 75. | Габделҗәгъфәр | 42 |
| 76. | Габделҗаббар | 43 |
| 77. | Мөхәррәм | 45 |
| 78. | Гайсә | 45 |
| 79. | Зайсан | 45 |
| 80. | Мөхәммәд | 45 |
| 81. | Дәмин | 45 |
| 82. | Мәкам | 46 |
| 83. | Мәкәй (Рәшит) | 46 |
| 84. | Җыендык | 47 |
| 85. | Сыендык | 47 |
| 86. | Илгәрәй | 47 |
| 87. | Илназыйр | 47 |
| 88. | Азамат | 48 |
| 89. | Шәмсетдин | 48 |
| 90. | Габделлатыйф | 52 |
| 91. | Габдеррафикъ | 52 |
| 92. | Габделвәли | 52 |
| | *VIII буын* | |
| 93. | Рәхмәтулла | 57 |
| 94. | Рәхмәтулла | 58 |
| 95. | Гайнулла | 59 |
| 96. | Фәйзулла | 59 |
| 97. | Габделвахид | 61 |

| 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|---|---|
| 98. | Габделлатыйф | 61 | | *IX буын* | |
| 99. | Габделнасыйр | 61 | 119. | Гобәйдулла | 104 |
| 100. | Габделмәннан | 61 | 120. | Имам Хөснетдин | 112 |
| 101. | Салават | 64 | | | |
| 102. | Халид | 64 | 121. | Мөхәммәдгалим | 112 |
| 103. | Йуламан | 64 | 122. | Мөхәммәдвәли | 112 |
| 104. | Фазый | 64 | 123. | Шәрәфетдин | 112 |
| 105. | Әмин | 65 | | | |
| 106. | Зәбир | 65 | | *X буын* | |
| 107. | Габидулла | 65 | 124. | Ярулла | 121 |
| 108. | Зәбир | 65 | 125. | Мөхәммәтхарис | 121 |
| 109. | Ногман | 66 | 126. | Мөхәммәтвагыйз | 121 |
| 110. | Котлызаман | 66 | 127. | Мөхәммәтсалих | 121 |
| 111. | Исмәгыйль | 66 | 128. | Мөхәммәттакый | 121 |
| 112. | Имам Котлуг-Әхмәт | 66 | 129. | Мөхәммәтсафи | 121 |
| | | | 130. | Габделвәли | 121 |
| 113. | Ибраһим | 66 | | | |
| 114. | Габделмәннан | 66 | | *XI буын* | |
| 115. | Рафикъ | 66 | 131. | Имам Мөхәммәтгариф | 125 |
| 116. | Мифтахетдин | 66 | | | |
| 117. | Рәшит | 83 | 132. | Мөәзин Мөхәммәтшафигъ | 127 |
| 118. | Габделмәннаф | 92 | | | |

Бәгъзы берләрнең исемнәре язылмауның сәбәбе исә, бу шәҗәрәне бер вакыт илә агалары карап утырганда, арадан берсе ачуы илә ертып ала да бирми. Ул кисәк кәгазе табылмый.

Күчереп алынды: 1926 нчы сәнә-и миладия гыйнвар 30 да.

Самар губирнасы Богырыслан өязе Куратовский вулост Гали «Алкин» карийәсе.

1 нче мәхәлләдә имам-хатыйб Мөхәммәтгариф Муради.

Күчермә саклана Гали карийәсендә «аерылган Салих» авылы мөәзине Гозаметдин Гыймадетдин углында. Бу шәҗәрәнең күчермәсендә Ишмәт углы Арслан гына язылган иде. 1912 нче елдагы күчермәдә Ишмәтнең 3 улы барлыгын күрсәтә. Ишәли Морад хәзрәт атасы, 2 – Ишкилде, 3 – Арслан. 1915 нче елдагы күчермә Морат хәзрәтнең 8 углы барлыгын күрсәтә. Шул сәбәбле Морат хәзрәтнең

дә угылларын яздым һәм дә үземнең бабаларымыз язып – бән имам Мөхәммәтгариф Мөхәммәтхарис углы Муради дийә күрсәтә.

*Искәрмә*

Шәҗәрәнең тексты Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлеге Көнчыгышны өйрәнүчеләр архивыннан, 131 ф., 1 тасвир., 32 сак. берәмлегеннән алынды. Ул 26,2×33,5 см зурлыктагы ак кәгазьгә кара төстәге кара белән язылган. Аерым искәрмәләр шәҗәрә тексты эченә кертелмичә аның кырларына теркәлгәннәр. Шәҗәрә таблица рәвешендә, исемнәр түзек түгәрәкләр эчендә бирелгәннәр. Түгәрәкләр бер-берсенә төзек һәм сындырылган тоташ сызыклар белән ялганганнар.

Шәҗәрәне күчереп саклаучы Кенәле елгасы буендагы Гали (әүвәлге Самара губернасы, Богырыслан өязе, Куратовский волосте) авылындагы 1 нче мәхәллә имам-хатибы Мөхәммәтгариф Муради була. Шәҗәрә 1926 елның 30 гыйнварында күчерелгән. Асыл нөсхә Гали авылыннан бүленеп чыккан. «Аерылган Салих» авылы мөәзине Гозаметдин Гыймадетдин углында калган. Асыл нөсхәдә 1800 елның 30 июнендә сугылган мөһере аның инде шул елда язылуын да күрсәтә.

Дүртенче шәҗәрә версиясе

Манаш нәселе шәҗәрәсенең дүртенче версиясенең төп нөсхәсен күрергә туры килмәде әле. Ул текст борынгылыкны чагылдыру ягыннан калган версияләрдән тулырак. Аның сәхифәләрендә Кенәле буендагы Галибай исеме дә, Казан арты Түбән Оры авылындагы тарихта исеме билгеле Котлыгыл да бар. Шулай да ул текстка конкретлык житми, төп асыл нөсхәсен карау кирәк. Шунлыктан Үтәмештә табылган күчермәсе генә файдаланылды.

Манаш нәсел шәҗәрәсенең Үтәмеш авылында табылган нөсхәсеннән бер фрагмент:

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
| | *I буын* | | | *III буын* | |
| 1. | Шәйхелхаҗ | | 3. | Әлхәмед | 2 |
| | *II буын* | | | *IV буын* | |
| 2. | Әлфар | 1 | 4. | Әлфәс | 3 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | *V буын* | |
| 5. | Гали | 4 |
| | *VI буын* | |
| 6. | Солтан = Гөлбостан | 5 |
| | *VII буын* | |
| 7. | Манаш (Миңәш) | 6 |
| | *VIII буын* | |
| 8. | Җөнәй | 7 |
| | *IX буын* | |
| 9. | Котлыяр | 8 |
| 10. | Кодаш | 8 |
| | *X буын* | |
| 11. | Бәхтияр | 9 |
| 12. | Котлыгош | 9 |
| 13. | Әлмәнтай | 9 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | *XI буын* | |
| 14. | Ишмәт | 10 |
| 15. | Котлымәт | 12 |
| 16. | Туча | 13 |
| | *XII буын* | |
| 17. | Әләм | 14 |
| 18. | Йосыф | 15 |
| 19. | Бикмәт | 15 |
| 20. | Колчура | 15 |
| 21. | Әбкә | 15 |
| | *XIII буын* | |
| 22. | Гомәр | 17 |
| 23. | Мортаза | 18 |
| 24. | Сәлимҗан | 18 |
| 25. | Исмәгыйль | 18 |

**Манаш нәсел шәҗәрәсенә карата**

Ибраһим хан тарафыннан бирелгән ярлык текстыннан һәм Үтәмештә табылган шәҗәрә текстыннан аңлашылганча, Гөлбостан хатунның улы Мөхәммәтгали, Мөхәммәт-Газизхан, шәҗәрә материалыннан күренгәнчә, Манаш булып чыга.

Манаш нәселе вәкилләренең тарихына кагылышлы хәбәрләр әүвәл Кама елгасының уң як ярындагы җирләрдә бара. Ләкин анда аларның кайдан килеп чыгулары аңлашылмый. Моңа төшенү өчен яңа чыганаклар кирәк. Алар бөтенләй үк юк түгелдер.

Әйтик, Манаш нәселенең эзләре аның буыннары яшәгән Казан артындагы татар авылларында да сакланып калган. Мәсәлән, Казан арты Түбән Оры авылына 1616 ел чамасында, Нократтан килеп утырган Хуҗа Сәетевләргә кадәр, Котлыгыш нәселе хуҗа булып торган. Түбән Орыдан соң алар Тыңламас (Талнамаз), хәзерге Александров исеме белән мәгълүм Арча янындагы авылда яшәгәннәр.

Манаш нәселеннән булган казаклы татар Булат Манашев Күгәрчен авылыннан (хәзерге Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе төбәге, Күгәрчен авылы) булып 1613 елда Кенәле (Кинель) елгасы буйларындагы биләмәне кондыз аулау һәм бал кортлары тоту өчен

ярлык белән алган. Булат үзе 1618 елда Арзамас янында черкаслар белән сугышта һәлак булган. Шул ук елны Булат Манашевның туганы казаклы татар Киләй Манашевта Кенәле елгасы буенда кондыз аулау һәм бал җыйнау хокукына тарханлык ярлыгы алган. Шул ук елда Киләй Манашев Күгәрчен авылыннан ерак булмаган Чаллы шәһәрлеге янында утар төзү һәм җирләргә хуҗа булу хокукын ала.

Киләй Манашев 1652 елда Балык Бистәсе төбәгенең көнчыгыш өлешеннән агып уза торган Шомбыт елгасы кушылдыклары булган Мешләк һәм Мәме инешләре буйларында да җирләр биләп яшәгән[1].

Манашев нәселе вәкилләре бүтән төбәкләргә дә таралып яшиләр. Мәсәлән, Оренбург өлкәсе, Әсәкәй авылында морза Габделвәли Габденнасыйр улы Манашев яшәгән, Башкортстанның Шаран төбәге Кыр Елан, Тархан авылларына да Манашевлар килеп төпләнгәннәр.

Сөләйман Манашевның 1690 елда Казанда хезмәттә булган улы Йосыфның Мәме Казак Чаллысы авылында (Җөри даругасында) утары була. Шулай ук аның Кенәле (Кинель) елгасы кушылдыклары Кинельчек, Савруш, Аманак, Зычи елгалары буйларында да биләмә җирләре булган.

1690–1691 елларда Кенәле елгасы буендагы Киләй Манашев биләгән җирләрне ярлык белән казаклы татар Ишәй Тохтаровка бирәләр. Ишәй – Киләй Манашевның туганнан туган апасының улы.

Кенәле елгасы буйларында Манашев һәм, аның улы Сөләйманнан башлап, Сөләйманов фамилиясен йөрткән кешеләр, социаль хәлләренә карап, асаба башкортлар дип йөртелә башлыйлар.

Манашев һәм аның улы Сөләйман исемен фамилия итеп йөртүчеләрнең күбесе Кенәле елгасы буенда Гали авылындагы шәҗәрәләргә язылмаганнар. Алардан күренгәнчә, хәтта ки Манашның бертуганнарының исемнәре дә нәсел шәҗәрәсендә юк.

Гали авылында Манаштан туган өч буынның гына исемен һәм нәселен яхшы белгәннәр, Казан ягындагы Манашка хәтле бабалар һәм ул якта калган нәсел тармаклары онытылган.

Галидә Гани бәйне генә онытмаганнар дип әйтергә мөмкин. Татарстанның Чирмешән төбәге Үтәмеш авылында сакланган шәҗәрә пакеты Манашның Гали шәҗәрәләрендә күрсәтелмәгән

---

[1] Писцовая..., 2001. С. 210.

Җөнәй исемле улына карый. Әлбәттә, Үтәмеш кулъязмасында да буталулар киткән булса кирәк. Ләкин бу текстта Түбән Оры авылында яшәгән Котлыгол нәселе тармаклары күренә. Шулай ук бу нөсхәдә Ибраһим ханнан ярлык алган Гөлбостан хатун исеме дә язылган.

Манашевлар шәҗәрәсе тарихыбыздагы тагын бер караңгы сәхифәне ача. Аларның иң борынгы нәсел башы булып Галибай (бәй) тора. Бу Галибай хронологик исәп белән XVI гасыр урталарында Кенәле суы буенда яшәгән. Шуңа күрә Казанда хөрмәттә булган Манашевлар Кенәле буендагы бабалары җирләрен үзләренә вотчина итеп калдырырга тырышканнар. Галибай биләмәсеннән ерак түгел, Болгар шәһәре белән Кенәле елгасы арасындагы Майна елгасы тамагыннан ерак түгел Аптынбай болыннары 1621 елның 10 апрелендә чукынган татар кенәзләре Асановларга бирелә[1]. Бу очракта Нугай Урдасы морзаларының 1576 елда санап киткән «Алибаев и Алтынбаев юрт и Болгарский царев юрт» атамаларына аңлатма бирергә мөмкинлек ачыла.

Беренчедән, боларны Казан ханлыгы төзелүгә тәэсир иткән Галим бәк, Алтынбәк һәм Габдулла ханга бәйләп карар өчен мәгълүмат җитми. Чөнки Аксак Тимердән соң да Болгар шәһәре әле 1431 елгача яшәвен дәвам итә.

Икенчедән, Галибай белән Алтынбайны Габдулла хан яки башка берәр хан балалары белән якынлаштыру – икеләнү уята.

Манашевлар шәҗәрәсе буенча, аларның ерак бабасы Галибай – хан да, солтан да түгел. Алтынбай турында да шул фикерне белдерергә мөмкин. Хәтта аның шәҗәрәсе дә юк. Болгар шәһәреннән дә 1395–1396 еллардан соң житәкче шәхесләр мәгълүм түгел.

Галибай белән Алтынбай йортлары Урта Иделдә Аксак Тимер явыннан исән калган шәһәр кешеләре тупланган урын булырга мөмкин, ләкин анда алар ныклап тамыр җәеп китә алмаганнар. Бәлки Гали авылы, олы су юлларыннан ерак булуы сәбәпле, шул туздырылган шәһәрләрдән күчеп килгән татарлар тырышлыгы белән торгандыр. Алтынбай нигезе Иделгә якын булганлыктан, ушкуйниклар һәм Дон, Жигули буйларыннан килгән юлбасар казаклары тырнагыннан котыла алмыйча юкка чыккандыр.

[1] Жалованная грамота, 1937. С. 169–170.

**Шәҗәрәнең тарихи кыйммәте**

Манаш шәҗәрә текстлары, Ибраһим хан ярлыгы белән бәйлелектә, Казан ханлыгы тарихына һәм, гомумән, Урта Идел тарихына бик мөһим яңа мәгълүматлар өсти.

1. Казанда 1445 елда үтерелгән Галибайның, башка Казан ханнары кебек үк, мөлкәт мәсьәләсендә тарханлык ярлыклары биргәнлеге яңалык булып тора. Аларның бу ярлыклары соңрак алышынган ханнар тарафыннан расланып, яңартылып бирелгәннәр. Ибраһим хан тарафыннан расланган Хәйдәргали солтан, шул ук Галибай тархан ярлыгыннан аңлашылганча, андый ярлыклар ханнар нәселеннән булган кешеләргә дә бирелгән.

2. Жайзәргали солтан үзенең хозурында башка татар ханнарының балаларын да тоткан (Манаш нәселе).

3. Манашевлар нәселенең кинәттән генә Нугай Урдасы биләмәсенә кереп, анда Кенәле елгасы һәм аның тармак елгалары буйларында кондыз аулаулары, кортчылыкларыннан бал җыйнап яшәүләре аларның бу тирәләр белән күптән танышлыгын сөйли. Шаһ нәселе булып ярлык алган Мөхәммәтгали Газиз хан (шаһ) нәселенең биләмәләре әүвәлдә Болгар олысы өлкәсенә караган Азибаев йорты түгелме икән? дигән сорау туа. Шул җәһәттән чукынган татар кенәзе Яков Асановның 1621 елның 10 апрелендә Кама аръягында, Нугай илендә, Майна елгасы тамагын, Үрән елгасы буйларын һәм Алтынбай болынын биләргә алынган ярлыгы кызыклы.

Бу җирләргә ярлыкны Яков Асан морза 1596/97 номерлы документ белән алган була. Анда кондыз аулау, балык тоту урыннарыннан табыш алган. Әлеге Майна тамагындагы Алтынбай болыннары да әлеге адәмгә калган. Аңа хәтле бу җирләр аның атасы Әсән морза кенәз биләмәләре булып торган[1].

Шунысы игътибарга лаек, Манашевлар кебек, Әсән морза кенәз дә Казан арты Җөри даругасындагы Норма елгасы буенда (һәм авылында да. – *М.Ә.*) җирләр биләп торган.

Алибаев һәм Алтынбаев йортлары, Болгар олысы өлкәләре шушы урыннар, мәйданнар булмады микән, дигән фикер туа. Чөнки Урта гасыр европалылары сызган карталарда әле XVII гасырда да Болгар олысы карта-схемасы төшерелеп йөртелгән.

[1] Писцовая..., 2001. С. 210.

Гали авылы бүгенге Самара өлкәсе, Похвистнево районына керә. Похвистнево 1947 елга хәтле татар авылы булып, Котлыгош дип йөртелгән. Җирле татар халкы аны бүген дә Котлыгош дип атый. Аны Манашевлар нәселеннән Котлыгош тархан нигезләгәне бәхәс уятмый.

### *Самара өлкәсе, Камышлы төбәге*<br>*Иске Ярмәк авылы шәҗәрәләр җыентыгы*

*Беренче шәҗәрә*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | 11. | Бакир | 2 |
| 1. | Мактамалы Абделҗәлил Насыйров, 1790 ел | | 12. | Биразетдин | 2 |
| | | | 13. | Фәрхетдин | 2 |
| | *II буын* | | 14. | Хисам | 2 |
| 2. | Шәрәфетдин | 1 | 15. | Гыйззетдин | 2 |
| 3. | Минһаҗетдин | 1 | 16. | Афзал | 3 |
| 4. | Галәметдин | 1 | 17. | Шәйхетдин | 4 |
| 5. | Шиһабетдин | 1 | 18. | Фәләхетдин | 4 |
| 6. | Нуретдин | 1 | 19. | Мисбах | 5 |
| 7. | Гатауетдин | 1 | 20. | Уфа | 6 |
| 8. | Габделгалләм | 1 | 21. | Шәһәли | 8 |
| 9. | Габделбәшир | 1 | 22. | Нуриәхмәт | 8 |
| | *III буын* | | 23. | Зәйнелбәшир | 9 |
| 10. | Гыйзаметдин | 2 | 24. | Бәдгытдин | 9 |

*Икенче шәҗәрә*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *III буын* | |
| 1. | Хисбат, 1740 ел | | 3. | Ибраһим | 2 |
| | | | | *IV буын* | |
| | *II буын* | | 4. | Хәким | 3 |
| 2. | Гафур Даманович | 1 | 5. | Котлыгхәмәт | 3 |
| | | | 6. | Галим | 3 |

## *Өченче шәҗәрә*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *IV буын* | |
| 1. | Хисбат, 1739 ел | | 6. | Ханнан | 3 |
| | | | 7. | Абдрафик | 3 |
| | *II буын* | | 8. | Каюм | 3 |
| 2. | Җаббар Даманович | 1 | 9. | Гани | 3 |
| | | | 10. | Садыйк | 4 |
| | *III буын* | | 11. | Халит | 4 |
| 3. | Абдрашит | 2 | 12. | Рәхим | 4 |
| 4. | Мөхәммәдъяр | 2 | 13. | Хисаметдин | 5 |
| 5. | Галиакбәр | 2 | 14. | Шәрәфетдин | 5 |

## *Дүртенче шәҗәрә*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *IV буын* | |
| 1. | Динеле, | | 6. | Вәли | 3 |
| | 1747 ел | | 7. | Кәлимулла | 4 |
| | *II буын* | | 8. | Хәким | 4 |
| 2. | Искәндәр | 1 | 9. | Әхмәт | 4 |
| | Салих улы | | 10. | Мифтах | 4 |
| | *III буын* | | 11. | Вәгыйз | 4 |
| 3. | Исмәгыйль | 2 | 12. | Ханнан | 4 |
| 4. | Габделмәннан | 2 | 13. | Әһлиулла | 5 |
| 5. | Ногман | 2 | 14. | Зәйнелгабидин | 5 |

## *Бишенче шәҗәрә*
## *(Башкорт урамы)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 1 | 2 | 3 |
| | *I буын* | | | *II буын* | |
| 1. | Фәйзулла | | 2. | Сөләйман | 1 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3. | Гайнулла | 1 |
| 4. | Вильдан | 1 |
| | *III буын* | |
| 5. | Юсуп Сукыр | 2 |
| 6. | Шәһидулла | 2 |
| 7. | Яриәхмәт | 2 |
| 8. | Шәрифулла | 3 |
| 9. | Гарифулла | 3 |
| 10. | Шәрәфетдин | 4 |
| 11. | Хисаметдин | 4 |

## *Алтынчы шәҗәрә*
## *(Алатырлы, 1780 ел)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Йосыф | |
| | *II буын* | |
| 2. | Зәбир | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Госман | 2 |
| 4. | Әмин | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Әхсән | 3 |
| 6. | Габбаз | 3 |
| 7. | Мөхәммәдрәхим | 3 |
| 8. | Садыйк | 4 |
| 9. | Габдулла | 4 |
| 10. | Сыйтдыйк | 4 |

## *Җиденче шәҗәрә*
## *(Алатырлы, 1780 ел)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Йосыф | |
| | *II буын* | |
| 2. | Әмир | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Гале | 2 |
| 4. | Котлыәхмәт | 2 |
| 5. | Хөснетдин | 2 |
| 6. | Фәссәхетдин | 2 |
| | *IV буын* | |
| 7. | Әхмәтгали | 4 |
| 8. | Әхмәдулла | 4 |
| 9. | Сәгыйрь | 4 |
| 10. | Әхмәди | 4 |
| 11. | Шаһи | 5 |
| 12. | Нуриәхмәт | 5 |
| 13. | Шәйхетдин | 6 |
| 14. | Әхмәтҗан | 6 |
| 15. | Әбелгали | 6 |
| 16. | Мөхәммәтҗан | 6 |

*Сигезенче шәҗәрә*
*(Алатырлы, 1780)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *IV буын* | |
| 1. | Йосыф | | 5. | Әхмәтҗан | 3 |
| | *II буын* | | 6. | Шаһимәрдән | 3 |
| 2. | Нәзир | 1 | 7. | Мөхәммәтҗан | 3 |
| | *III буын* | | 8. | Сабир | 4 |
| 3. | Гозәер | 2 | 9. | Гасим | 4 |
| 4. | Зарин Латыйп | 2 | 10. | Сыйтдыйк | 4 |

*Тугызынчы шәҗәрә*
*(Кандыз, Карамалы, 1835 ел)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | | *IV буын* | |
| 1. | Хәбибулла | | 6. | Ярулла | 3 |
| | *II буын* | | 7. | Әхмәдулла | 3 |
| 2. | Фәтхулла | 1 | 8. | Ибраһим | 3 |
| | *III буын* | | 9. | Харис | 4 |
| 3. | Зәйнулла | 2 | 10. | Фатих | 4 |
| 4. | Әһлиулла | 2 | 11. | Зәки | 4 |
| 5. | Хәлиулла | 2 | 12. | Мөхибулла | 5 |

*Унынчы шәҗәрә*
*(Чыгытайлы, 1830 ел)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе | Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|---|---|---|
| | *I буын* | | 5. | Исхак | 2 |
| 1. | Баһаветдин | | 6. | Әбдерәшит | 2 |
| | *II буын* | | | *IV буын* | |
| 2. | Хөснулла | 1 | 7. | Әсхәт | 3 |
| | *III буын* | | 8. | Әкрәм | 3 |
| 3. | Әбделхәмит | 2 | 9. | Баһман | 5 |
| 4. | Исмәгыйль | 2 | 10. | Кауас | 5 |

## *Унберенче шәҗәрә*
## *(Польшадан, 1789)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Биктимер | |
| | *II буын* | |
| 2. | Абдрахман | 1 |
| 3. | Бикбау | 1 |
| | *III буын* | |
| 4. | Вәгыйз | 2 |
| 5. | Газиз | 2 |
| 6. | Мөхәррәм | 2 |
| 7. | Хәлиулла | 3 |
| 8. | Кәлим | 3 |
| 9. | Вәлиулла | 3 |

## *Уникенче шәҗәрә*
## *(Юлтимерле, 1799)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Әбделкәрим мулла | |
| | *II буын* | |
| 2. | Габденгазиз | 1 |
| 3. | Габделхәлим | 1 |
| 4. | Габделхәким | 1 |
| | *III буын* | |
| 5. | Каюм | 2 |
| 6. | Габделхәйер | 2 |
| 7. | Хөсәйен | 3 |
| 8. | Хөсни | 3 |
| 9. | Габдрафик | 3 |
| 10. | Ихсан | 4 |
| 11. | Габделгаттар | 4 |
| 12. | Ахун | 4 |

## *Унөченче шәҗәрә*
## *(Казанлы, Идел буе, 1740 ел)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Ходайбирде | |
| | *II буын* | |
| 2. | Сәйфелмөлек | 1 |
| | *III буын* | |
| 3. | Шәмкәй | 2 |
| 4. | Фәхретдин | 2 |
| | *IV буын* | |
| 5. | Хөснетдин | 3 |
| 6. | Сәлахетдин | 3 |
| 7. | Борһанетдин | 3 |
| 8. | Шәрәфетдин | 3 |
| 9. | Фазлытдин | 4 |

*Ундүртенче шәҗәрә*
*(Күтәрле, 1741)*

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *I буын* | |
| 1. | Рәфикъ Туканаев | |
| | *II буын* | |
| 2. | Төп нөсхәдә язылмаган | 1 |
| 3. | Нигъмәтулла | 1 |
| 4. | Ситдыйк | 1 |

| Тәртип саны | Буыннар тәртибе һәм шәхесләрнең исемнәре | Ата-ана исеме тәртибе |
|---|---|---|
| | *III буын* | |
| 5. | Мөхәммәтрәхим | 3 |
| 6. | Зарип | 3 |
| 7. | Сафа | 4 |
| 8. | Кәрим | 4 |
| 9. | Мөхәммәтгали | 4 |
| 10. | Хәким | 4 |

*Искәрмә*

Шәҗәрәләр җыентыгын хәзерге вакытта Самара өлкәсе Камышлы төбәгенә карый торган Иске Ярмәк авылында 1880 елда туган Әхмәдуллин Гатиятулла җыеп төзегән булган. Аның текстын 1960 елда диалектологик экспедиция барышында Институт галимәсе Гасимә Кәшфи кызы Якупова күчереп алган. Бу текст аның кульязмасыннан 1974 елда күчереп алынган иде.

Шәҗәрә тексты, XVIII гасырның беренче яртысында Нугай Урдасы җирләре тәмам яулап алынгач һәм Калмык Урдасы кабиләләре тар-мар ителгәч, бушап калган җирләрне үзләштерү процессында, Самара, Оренбург далаларындагы җирләрдә барлыкка килгән авыл халкының кайсы яклардан килүен, урнашуын ачыклау өчен кыйммәтле материал бирә.

Анда күпчелек килеп утыручылар Казан, Бөгелмә, Алатырь һәм, хәтта, Польша ягы татарлары булуы күрсәтелә (Казанлы, Юлтимер, Кандыз, Карамалы, Чыгытайлы, Алатырьлы, Мактамалы) һәм шәҗәрәләрдә күченүләрнең 1739–1830 еллар арасында булганлыгы да аңлашыла.

# ЭСПЕДИЦИЯ ТАБЫШЛАРЫННАН: КУЛЬЯЗМАЛАР ҺӘМ КИТАПЛАР ХАКЫНДА

*Салават Галимов*

Татар халкы элек-электән китапка хөрмәт белән караган. Аны саклаган, күчереп язган, китап бастыруның үзенә дә зур игътибар биргән. Нәшер ителгән китапларның язмышы төрлечә, ягъни һәр китапның үз «гомере». Кайбер китаплар бик матур, яхшы сакланган, икенчеләре таушалып беткән, өченчеләре хуҗаларының, укучыларының өстәлмәләре белән чуарланган... Шулай да аларның һәркайсы кадерләп тотылган, буыннан буынга тапшырыла килгән. Аларда халкыбызның тарихы саклана, өмет-хыяллары чагылыш таба, алар аша буыннар бәйләнеше тәэмин ителә. Шуңа да кулъязма һәм басма китапларны өйрәнү аеруча зур әһәмияткә ия. Самара өлкәсенә экспедиция әнә шундый сирәк китапларны, кулъязмаларны барлау, туплау максатыннан да оештырылды.

Төбәктә фәнни эзләнү Гали, Нугай, Яңа Мансур, Иске Мәчәләй, Иске Ярмәк, Яңа Ярмәк, Назаровка, Дәүләткол, Балыклы авылларында алып барылды. Монда гарәп хәрефендәге, татар һәм гарәп телләрендәге 100 гә якын китап тупланды. Кызганыч, алар арасында кулъязма китаплар бик аз иде. Халык һәм имамнар сүзенә караганда, 2014 елда Похвистнево һәм Камышлы районнарына караган барлык татар авыллары бу байлыкларны мәчетләрдә көлтә-көлтә туплап, Самара шәһәренә озатканнар.

Әлбәттә, китапларны саклаучылар – зур хөрмәткә ия кешеләр. Халкыбыз ядкәрләрен бөртекләп җыюда ярдәм иткән Яңа Мәчәләй авылыннан Фәтхуллин Рафаил Әхәт улына, Иске Мәчәләй

авылыннан Исхакова Миннехәят Әхмәдулла кызына, Абдрахманов Ибраһим Миргазыян улына, Нугай авылыннан Сафиуллина Рәйсә Шәрип кызына, Гали авылыннан Кәлимуллина Нәсимә Мидхәт кызына, Латыйпов Госман Габдерәшит улына, Яңа Мансур авылыннан Бигиева Рәшидә Касыйм кызына һ.б.га бик тә рәхмәтлебез. Алардан алынган материаллар безнең архивны тагын да баетты.

Иске Ярмәк авылы мәчете имам-хатибы Габдулла хәзрәт Мөхәмметкәримов та мәчет киштәсендә озак еллар сакланган кульязма битләрен Иститутка тапшырды. Китапларның ул биргән өзекләре халкыбызның тарихын өйрәнүдә, алар арасында таралган, укылган китапларның географиясен киңәйтүдә зур чыганак булыр, дип ышанабыз.



1 нче рәсем

Кульязмаларның күпчелеге бик начар сакланган. Алар – тышлыксыз, бер-ике биттән генә торганнары да бар. Төрле кульязмалардан җыеп туплаганнары да очрады. Аларның иң күләмлесе 46 битне тәшкил итә (1 нче рәс.), ул Иске Мәчәләйдә Исхакова Миннехәят Әхмәдулла кызында сакланган. Тегелмичә генә каты тышлыкка салынган мондый битләр китапларны саклауның үзенчәлекле бер формасы булып тора.



2 нче рәсем

Басма китапларның күпчелеген дини китаплар тәшкил итә. Алар арасында Коръән, «Алты бармак», «Мөхәммәдия» шактый очрады. Самара төбәгеннән тулы һәм тулы булмаган берничә басма Коръән табылды, алар барысы да каты тышлыкта. Тышлыгы чүпрәк белән капланганы да бар (2 нче һәм 3 нче рәс.). Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, халык Коръәнне кадерләп саклаган. Шуңа да Коръәннәр,

кагыйдә буларак, яхшы хәлдә. Самара өлкәсендәге табылдыклар да әлеге кагыйдәгә туры килә.

Элек мәдрәсәләрдә укылган «Мөхәммәдия» халыкта киң таралган китаплардан санала. Самара өлкәсендә дә аның берничә нөсхәсе табылды. Бу «Мөхәммәдия»ләр тулы, зур форматлы, калын китаплар (4 нче рәс.).

Зур форматлы «Алты бармак» та яхшы сакланган. Самара өлкәсендә табылган әлеге дини-дидактик әсәр Казанда 1910 елда бертуган Кәримовлар нәшриятында басылган булган (5 нче һәм 6 нчы рәс.).

Халыкта догаларның кулдан күчереп язылганнары, фотокүчермәләре бар, шамаилләр очрый. Аларның күпчелеге каләм, сирәк кенә карандаш белән гади дәфтәргә язылган. Күчереп язучылары күрсәтелмәгән. Догаларның фотокопияләре соңрак алынган. Басма китаптан алынган фотокүчермәләр берничә. Алар «Рисалә-и фи бәян фазыйлә дога мөстәхәб», «Дога исме әгъзам вә һәм башка шәриф догалар» китапларыннан алынган (7 нче һәм 8 нче рәс.). Арада дини эчтәлекле «Шәриәт әл-иман», «Тәфсир Ногмани» һ.б. китапларның



3 нче рәсем



4 нче рәсем. 1914 елда Казанда В. Еремеева һәм А. Шашабрин нәшриятында басылган «Мөхәммәдия» китабы



5 нче рәсем



6 нчы рәсем



7 нче рәсем



8 нче рәсем



9 нчы рәсем. «Кызганыч хәл» шигыре башы



10 нчы рәсем. «Бүз егет кыйссасы»ннан өзек



11 нче рәсем

фотокүчермәләре дә очрый. Алар якынча XIX йөз ахыры – XX йөз башларына карыйлар.

Халык еш кына төрле жанрдагы әсәрләрне куен дәфтәре рәвешендә бергә туплап язган. Мәсәлән, аларның бер битендә мөнәҗәт булса, икенчесендә – шигырь, өченчесендә – бәет һ.б. Алар халык авыз иҗатын, билгеле бер чор әдәбиятын өйрәнүдә чыганак була ала.

Шундыйлардан Яңа Мәчәләй авылында яшәүче Фәтхуллин Рафаил Әхәт улыннан алынган куен дәфтәрен аерым әйтеп үтәргә кирәк. Бу җыентыкта, мөнәҗәт һәм догалардан тыш, бәетләр, шигырь юллары, кыска һәм озын җырлар (тулы һәм өзекләр) очратырга мөмкин (9 нчы рәс.). Гали авылында яшәүче, заманында мәчет имамы булган Латыйпов Госман Габдерәшит улында табылган китапчык та бик кы-



12 нче рәсем



13 нче рәсем

зыклы. Чөнки монда «Бүз егет» романтик мәхәббәт дастаныннан күчермәләр бар (10 нчы рәс.).

Самара өлкәсенең Похвистнево һәм Камышлы районнарының татар авылларына булган комплекслы экспедициядә табылган иң кыйммәтле табышлардан әл-Җами (11 нче һәм 12 нче рәс.) һәм әлегә исеме билгесез дини эчтәлекле (13 нче рәс.) кулъязмаларны атап үтәргә кирәк. Кызганыч, тулы тасвирлама ясамыйча, бу китапларның кайда, кем тарафыннан күчерелүен һәм кайсы гасырга каравын төгәл әйтеп булмый. Әлеге һәм алдан санап киткән китаплар татар дөньясын өйрәнүдә әһәмиятле чыганак булыр, дип уйлыйбыз.

# ТУГАНДАШЛАР ТЕЛЕ ЯКЫН КҮҢЕЛГӘ

*Дария Рамазанова*

Татарстаннан читтәге өлкәләрдә яшәүче тугандашларыбызга барып очрашудан бер ләззәт аласың.

Самара өлкәсенең Камышлы төбәгендәге татарларның сөйләшен өйрәнү барышында да туган телләрен саклап, халкыбызның гореф-гадәтләрен чын мәгънәсендә үстереп-яшәтеп гомер кичергән татар халкы белән очрашудан бик канәгать булуыбызны хәтерлим.

Самара өлкәсе татарларының сөйләшен беренче һәм фәнни тикшеренүче Г.К. Якупова булган. Татар теленең лингвистик атласын төзү буенча конкрет эшләр башлангач, 50 нче еллар азагында галимә Самара якларындагы сөйләшне өйрәнүгә керешә һәм Атлас өчен 25 татар авылына махсус экспедицияләр оештыра. Сүз уңаенда шуны аерым күрсәтеп үтәргә кирәк, Гасимә Кәшфи кызы – 50–60 нчы елларда татар диалектологиясе фәнен үстереп, канат куючы буынны тәшкил иткән Латыйф Җәләй, Ләйлә Мәхмүтова, Нәҗия Борһановалар белән берлектә зур эшчәнлек алып барган галимәләрнең берсе. Ул – диалектология фәненә тырыш, игътибарлы һәм намус белән хезмәт итеп, бу өлкәдә үз эзен калдыра алган шәхес.

Г. Якупова, – Самара өлкәсендә генә түгел, Татарстанда Кама аръягының көнбатыш өлешендәге татар сөйләшләрен, Түбән Новгород өлкәсенең Сергач төбәгендәге мишәр сөйләшләрен, Зәй буе керәшеннәренең сөйләш үзенчәлекләрен экспедицияләр оештырып өйрәнгән, бай фактик материаллар туплаган һәм аларны төрле басмаларда нәшер итүгә ирешкән диалектолог. Аның эшчәнлегенең әһәмияте тагын шунда, ул тупланган материалларын фәнни эшкәртүгә дә зур игътибар бирә. Ул 1948, 1953, 1958 елларда дөнья

күргән «Диалектологик сүзлек»ләрне төзү, матбугатка әзерләүдә тырышлык күрсәтә һәм татар теленең 1969 елда чыккан диалектологик сүзлегендә автор буларак катнаша. Билгеле булганча, әлеге хезмәт, һәрьяктан уйлап, оригиналь принциплар нигезендә төзелгән сүзлек буларак, татар тел белемендә генә түгел, гомумтюркологиядә дә югары бәя алды.

Күп еллар бергә эшләгән, аның белән бергә Самара өлкәсендәге татар авылларының барысын да Атлас өчен өйрәнеп чыккан кеше буларак, биредә тагын бер әһәмиятле моментны күрсәтеп үтәсем килә. Гасима апа туган телебезне бик яхшы белә һәм аның нечкәлекләренә зур игътибар бирә, тел байлыгыбыз белән горурлана иде, экспедицияләр барышында халкыбызның мәкаль һәм әйтемнәрен, канатлы сүзләрен, үткен һәм кызыклы тәгъбирләрен тиз тота иде. «Татар диалектлары буенча материаллар» (4 чыгарылыш, 1978 ел) дигән хезмәттә телебезнең мәгънә байлыгын чагылдырган бер «көлтә» мәкальләрне дә Гасима апа урнаштырды.

Аның материалны бөртекләп җыя, аларны фәнни өйрәнеп эшкәртә белүе «Татар тел белеме буенча библиографик күрсәткеч» дигән зур хезмәтне җыеп, фәнгә тәкъдим итү өстендә эшләгәндә аеруча нык чагылды.

Фәнгә һәм шул өлкәләрдә эшләүче галимнәргә югары этик мөнәсәбәте белән дә ул безнең барыбызда да үзенә карата зур хөрмәт уятты.

Гасимә апа Якуповага болай киң тукталуымның сере шунда: ул – Самара өлкәсенең Камышлы төбәгендә, шул төбәкнең бик абруйлы гаиләсендә туып үскән, шунда мәктәп елларын уздырган һәм Казанга килеп, югары уку йортында белем алган, аларны халыкка хезмәт итүгә багышлаган, фәндә генә түгел, кешеләрнең күңелендә дә якты эз калдырган шәхес. Шуңа күрә Камышлы төбәге бездә иң башлап Гасима апа турында матур хисләр уята. Ә аның якташлары белән танышу әлеге төбәктә ягымлы апалар-абыйлар, изге күңелле әбиләр-бабайлар, халкыбызның күркәм традицияләрен, күп еллар буе яшәп килә торган гореф-гадәтләрен алга таба да дәвам итәргә омтылган кызлар-егетләр яшәвен күрсәтте. Камышлы ул – З. Ярмәки, Ә. Давыдов, А. Нарбеков, Җ. Гыйльманов, күз врачы Һ. Абдуллина һәм башка шундый олы хөрмәткә ия шәхесләр биргән як. Татарстаннан читтәге

өлкәләрдә дә менә шундый язучылар, фән докторлары, могтәбәр затларыбыз булуы, югары рухлы тугандашларыбыз яшәве халкыбызның киләчәгенә карата зур өметләр, ныклы ышаныч уята.

Минем үземә, «Татар теленең диалектологик атласы»н төзү барышында, Самара өлкәсендәге 25 татар авылын Гасима Кәшфи кызы белән берлектә тагын бер кабат өйрәнеп чыгарга туры килде. Ике ай дәвамында бай материал тупланды һәм алар, тиешле программа күләмендә Атласта да чагылды, диалекталь сүзләр исә татар теленең диалектологик сүзлекләренә (1969; 1993; 2009) кертелде.

Инде Камышлы сөйләшенең төп үзенчәлекләренә тукталып үтик.

Сөйләшнең исеме әлеге төбәктә мәгърифәтле үзәкне тәшкил иткән Камышлы атамасыннан алына. Гасима апаның тырыш эшчәнлеге белән бәйле рәвештә бу сөйләш татар диалектологиясе фәнендә башлангыч этапта ук фәнгә кереп китә.

Сөйләш таралган территориянең, анда яши торган халыкларның тарихы әлегә ныклап өйрәнелгән, дип әйтеп булмый. Төбәктә төрле диалект вәкилләре яши: мишәр (ягъни көнбатыш) һәм урта диалект. Көнбатыш диалект вәкилләренең сөйләше урта диалектның көчле йогынтысы астында үсеш-үзгәреш кичерә. Төбәктәге төп татар авыллары, нигездә, XVII–XVIII гасырларда барлыкка килгән булса кирәк. Мәсәлән, шундыйлардан Җылы Җай, Мулловка, Ярмәк авылларының икесе дә, Кушка районындагы Губанкүл, Камышлы төбәгендәге Камышлы, Байтуган, Усман, Мансур һ.б. авылларны күрсәтергә мөмкин.

Кайбер авыллар чагыштырмача соңрак күчеп утырганнар һәм мишәр диалектына хас грамматик үзенчәлекләрне, аваз әйтелешләрен ныграк саклап киләләр. Мәсәлән, Тат. Выселки, Яңа Мансур, Мәчәләй һ.б. авыллар шундыйлардан.

Бер төркем авылларның исемнәре рус антропонимнарын тәшкил итә: Моисеевка, Иске Җүрәй (ст. Фейзулово), Яңа Җүрәй (Ново Фейзулово), Денис һ.б. Иске Усман авылының да Мәтеби дигән икенче исеме бар икән. Бу авылларның янында кечкенә-кечкенә чуваш авыллары урнашкан булу да аларның тарихының катлаулылыгы турындагы фаразга җирлек була ала.

Кайбер Иске–Яңа бинар позициядә торган исемнәре булган авыллар (мәсәлән, Иске Ярмәк, Яңа Ярмәк), кайчандыр, бер авыл

булганнар, чагыштырмача соңгырак чорда аерылганнар. Аларның сөйләшләре, нигездә, бер төсле. Бу ике авылның халкы шулай да көнбатыш диалектка хас үзенчәлекләргә ия. Алар күчеп килеп утырганда ук ике төркемгә караганнар булса кирәк. Чөнки хәзерге Ярмәк авылларының берсендә *ч* авазының шартлау элементы, күрше Ярмәк авылы сөйләшендәге *чт* авазы белән чагыштырганда, көчлерәк *(тч)*. Шулай да бу ике авылда мишәрлек шактый көчсезләнгән.

Күпчелек авыллар урта диалектка карый: Камышлы, Яңа Усман, Нугай, Тат. Байтуган, Тат. Абдикеево, Бакаево һ.б. Самара өлкәсендә керәшен авылы да бар: Назаровка.

Кайбер авылларның халкы социаль яктан да бертөсле генә булмаган. Татар авылларында халыкны типтәрләргә һәм ясаклыларга бүлеп йөртү очраклары бар. Алькино татарча Гали авылы дип йөртелә, анда 1000 гә якын хуҗалык исәпләнә, 7–9 мәчетле булган, хәзер 3 мәчет эшли. Авыл халкын типтәрләргә бүлү очраклары бар, бу авылда тарханнар катламы да булган. Безнең күзәтүләргә караганда, әлеге бүленешләр ныгып җитми калганнар һәм хәзер ул турыда нигезле, төпле дәлилләр табуы кыен. Монда Самара өлкәсе оешу һәм андагы татар авылларының Уфа һәм Оренбург губерналарыннан аерымлануы зур роль уйнаган булса кирәк. Кайбер авыллар (мәсәлән, Заиткино) XX гасыр башларында Идел буеннан күчеп килгәннәр.

Менә шушы фактлар гына да Камышлы төбәгендәге татар сөйләшенең формалашуы нинди катлаулы тарихи-демографик һәм тел катнашлыгы ситуациясендә баруын ачык күрсәтәләр. Билгеле, бу катлаулылык әлеге авыллар сөйләшенең бердәйлеге урнашуга, (нивелировкага) комачаулаган. Монда тагын татар авылларының Самара өлкәсе территориясендә бик таркау урнашкан булулары да зур роль уйнаган. Камышлы сөйләше Оренбург өлкәсендә формалашкан богырыслан (урта диалект) һәм өлешчә шарлык (көнбатыш диалект) сөйләшләре белән чиктәш. Бик күп тарихи һәм этно-мәдәни вакыйгалар аларның өчесе өчен дә уртак булган. Әлеге сөйләшләрнең формалашуында минзәлә, мамадыш сөйләшләренең дә зур катнашлыгы сизелә. Оренбург өлкәсендәге татар сөйләшләренең лексик-семантик системасы буенча уздырылган тикшеренүләр дә камышлы һәм аның чиктәш сөйләшләре арасында зур уртаклыклар булуын ачты.

**_Камышлы сөйләшенә кайбер күзәтүләр_**

Камышлы сөйләшенең вокализмында кайбер моментларга игътибар итми мөмкин түгел. Мәсәлән, сөйләшкә, нигездә, иренсезләштерү хас. Бу түбәндәге күренешләрдә чагыла:

*а* авазының, әдәби телдән аермалы буларак, иренләшмәгән ачык аваз булып әйтелүе: *қарама, ағач* – агач, *саwап* (савап), *Алла, йалды* (өйалды), *сайлау*, *бозау* һ.б.

Мондый күренешнең нигезендә 2 фактор ята булса кирәк: көнбатыш диалектның көчле тәэсире һәм бу төбәктәге борынгы төрки компонентка иренләшмәгән *а* авазы хас булу (чагыштыр: үзләрендә борынгылыкны саклап килә торган һәм периферияда формалашкан касыйм, бастан, бәрәңге, нократ, пермь, красноуфим, эчкен һ.б. сөйләшләр).

Шул ук вакытта Карабиккул, Назаровка, Бакаево, Камышлы, Яңа Усман, Тат. Байтуган, Иске Усман, Гали, Нугай авылларында *а* авазының иренләшү төсмере булган варианты да бар (кара: Атласның 1 нче номерлы картасы)[1].

Иренсезләштерү әдәби телдәге *о-ө, у-ү* авазларының сөйләштә *ы/ы$^{о}$ , е/е$^{ө}$* , дип әйтелүендә һәм *у > ы, и; ү > и* күренешләренең активлыгында да чагылыш таба.

Мәсәлән: *то$^{ы}$рмыш* – әйтелештә *тормош* – язуда *тормыш*, *бо$^{ы}$лын* – болон, әйтелештә *болон* – язуда *болын*, бо$^{ы}$рылыш, *бо$^{ы}$рылыш,* әйтелештә *боролош* – язуда *борылыш* һ.б.;

*Көeндез* – әйтелештә *көндөз* – язуда *көндез;* көeлке – көлке, *көeн* – көн, *көeчле* – әйтелештә *көчлө* – язуда *көчле* һ.б.

Иренсезләштерү *ы ~ у* күренешендә дә чагыла: *быйақ/бийақ* – бу йак – әд. бу як, *монча/мынча* – әд. мунча, *чыбату* – чуалту, *быйау/бийау*–буяу, *хушбый* – хушбуй, *былса* – булса, *была* – була, *йыбату* – йуату – юату, *намыс* – намус, *бысы* – бусы –әд. монысы һ.б.

*Ө/э (е) ~ү: бөгөн/беген* – әд. бүген, *төгөл/тегел* – түгел, *көңөл/еңел* – күңел һ.б.

*У, ү ↔ о, ө* икеяклы күчешне чагылдыра торган мисалларның бер өлеше көнбатыш диалектка, бер өлеше урта диалекта хас. Мәсәлән: *қуңғ – коңгыз, бутка* – ботка, *йүткерү* – йөткерү, *бүгелмәле* – бөгелмәле һ.б.

---

[1] Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья (I и II том). Казань, 1989 и Комментарии к «Атласу...». Казань, 1989.

Бу күчешләр алынмаларда да чагылыш таба: *былафкы* – булавка, *карбуз* – карбыз, *хекемәт* – хөкүмәт һ.б.

*Ы~а* тәңгәллеге дә ике диалектка да хас булган мисалларда чагылыш таба: *йаңы* – йаңа – яңа, *апыра* – апара; *қыйағаз/қийағыз* – кәгазь, *сындық* – сандык, *тытыш* – тоташ һ.б. Бу күренеш тагын қапқан (әд. капкын), *хайаллану* – хыйаллану – әд. хыяллану сүзләрендә дә күзәтелә.

Қамышлы сөйләшендә кушымчаларда *ы~а, е~ә* тәңгәллекләре чагыла, мондый үзенчәлекнең изоглоссасы күрше богырыслан, шарлык, минзәлә, стәрлетамак сөйләшләрендә дә дәвам итә: *барғынчы/барғанчы*– барганчы, *үсәр/үсер* – үсәр, *табыр* – табар, *қабыр* – кабар, *қабырға/қабарға* – кабарга, *сөзергә/сөзәргә* – сөзәргә, *көтергә/көтәргә* – көтәргә һ.б.

*И* һәм *ә* авазлары тәңгәллегенә түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: *кәртә* – киртә, *кәм* – ким (бу күренешенең изоглоссасы чистай сөйләшеннән үк башлана), *мәләш* – миләш, *эләс-мәләс* – иләс-миләс, *мәктеп*-мәктәп, *сәке/сике* – сәке, *җәйәү/җийәү* – җәяү, *әлбиттә* – әлбәттә, *фирештәләр* – фәрештәләр һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр бар: *күгәwен* – кигәвен, *мәчит* – мәчет, *чили-пешли* – чиле-пешле һ.б.

Әдәби телдә калын сузыклар белән әйтелә торган сүзләрне нечкә итеп һәм, киресенчә, алыштырып әйтү: *берчә* – борча, *йен* – йон*, селәүчән* – суалчан, *чебек* – чыбык, *әмсенү* – ымсыну, *күкшин* – кувшин, *этрәт* – отряд, *әрмийә* – армия һ.б.; *шишә* – шешә, *wағда* – вәгъдә, *чиклаwык* – чикләвек, *кукай/күкәй* – күкәй, *мый* – ми, *йанаша* – янәшә, *анчык* – әнчек һ.б.

Сузыклар өстәлү (*өтөрмән/этермән* – төрмә, *өтөрү* – төрү, *өрөхсәт* – рөхсәт һ.б.) һәм төшү (*марта/мурта* – умарта, *йалды* – өйалды, *иләшә* – ияләшә) очраклары да камышлы сөйләшенә үзенчәлеклелек бирәләр.

Дифтонгларны монофтонглаштыруда да камышлы сөйләшенә хас иренсезләшү күзәтелә: *илә/ийлә* – өйлә, *си*[й]*кемле* – сөйкемле һ.б.

Билгеле бер төркем сүзләрдә әд. *өй* урынына *ү* әйтелә: *сүрәү* – сөйрәү, *күрәү* – көйрәү, *үрә* – өйрә, *үрәнү* – өйрәнү һ.б. Бу мисалларның *ү* вариантын әйтү татар теленең күпчелек сөйләшләрендә бар.

Сузыклар алдындагы *өй* дифтонгы исә *и/и*$^{й}$ монофтонгына яисә *ий* дифтонгына күчә: *сейәл/сийәл* – сөял, *сейәк/сийәк* – сөяк, *кейә/кийә* – көя, *сейенеп/сийенеп* – сөенеп һ.б.

Сөйләштә тагын дифтонгларның мондый тәңгәллекләре бар: *қачы*, *қачан, қачақта (ай>а), қыйаш* – кояш, *қыйма* – койма, *қыйа* – коя (*ой>ый*) һ.б.

Камышлы сөйләшендә тартык авазлар да әдәби телдәгечә әйтеләләр. Үзенчәлекләр исә төрле аваз тәңгәллекләренә, позиция белән бәйле үзгәрешләргә кайтып қала.

Сөйләш *й*-ләштерүче булып тора. *җ>й* гомумән бик актив: *йәрәхәт* – җәрәхәт, *йәнлек* – җәнлек, *йезнә* – җизнә, *йеңгә* – җиңгә, *йан* – җан һ.б. Кайбер сүзләрдә, кеше исемнәрендә *җ//й*: *Йәмнихә/Җәмнихә, йәһәт җәһәт*, *җымға/йымга* – җомга һ.б.

Шулай да сөйләштә аерым сүзләр *җ* белән әйтелүчән: *мәрҗән*, *җиде*, *җийәү, җәймә, көнҗәлә* һ.б.

Закончалыклы күренешләрдән тагын түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк.

Татар теленең үз сүзләрендә борынгы авазлар (п,к) саклану: *керпек, тупрақ, қалпақ, йепәк, йапрак; йақшы, қатын* һ.б.

Алынма сүзләрдәге ят авазларның алмашынуы: *Қәдичә* – Хәдичә, *қаста* – хаста, *Исқақ* – Исхак, *хәдәр/қәдәр* – кадәр, *хәрендәш* – кардәш, *духтыр* – доктор һ.б.

Бер төркем тәңгәллекләрдә борынгы вариантлар саклана: *кели* – тели, *келәнче–теләнче(к~т), кигерү/кигезү, белдерү/белгерү, менгерү/менгезү* (ротацизм борынгырак вариант булып санала), *үләм* – үлән, *чырмау* – чорнау; *негез* – мөгез, *нүwек/мүк, нүwеш* – диал. мөгеш – почмак (*н*-вариантлар көнбатыш диалектка хас).

Бер төркем сүзләрдә ике сузык арасындагы позициядә *қ/к* авазының яңгыраулашуы көнбатыш, тубыл-иртыш, бараба һәм том диалектларына да хас күренеш. Камышлы сөйләшендә бу күренешнең тотрыклылыгы көнбатыш диалект вәкилләре белән тәэсир итешү нәтиҗәсе булырга мөмкин: *йаға* – яка, *туғу* – туку, *игенче/икенче* – икенче, *тығырық* – тыкрык һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр дә сөйләшләрне тарихи планда тикшерү өчен бик әһәмиятле: *читләвек* – чикләвек (т~к), *әрбир* – әйбер (*р~й*), *йәшәйтү* – яшәртү, *қарайу* –

каралу (ай/әй сүзъясагыч кушымчасының активлыгын чагылдыра) һ.б.

Камышлы сөйләшендә тагын *н~л, д~г, й~д, ч~с* (*печнәк* – песнәк, *чиннек* – сенник, *кәчтүм* – костюм, *чимйә* – семья, чәйке – сеянка) һ.б. тәңгәллекләр күзәтелә, ассимиляция, диссимиляция, тартыклар өстәлү яки төшү һ.б. күренешләр бар, алар камышлы сөйләшенең урта диалектка каравын исбатлыйлар.

Морфологик үзенчәлекләргә килгәндә, алар шулай ук камышлы сөйләшенең урта диалектка каравын раслыйлар. Икенчедән, морфологик үзенчәлекләрдә дә сөйләшнең ике диалектның үзара тәэсир итешүе шартларында үсеш-үзгәреш кичерүе мәгълүм.

Сөйләштә урта диалект белән уртак булган түбәндәге үзенчәлекләрне күрсәтергә мөмкин.

Алмашлыкларның составы (*ана/әнә, анаwы/мынаwы, нәрсә, нәрсәкәй* һ.б.).

Алмашлыкларның урын-ара килешләрен урта диалект сөйләшләренә хас вариантта формалаштыру (*аңарға* – аңа, *миңарға* – миңа, *сиңарға* – сиңа, *аңардан* – аннан, аңарда – анда һ.б. *Миңарға, сиңардан* тибындагы формалар минзәлә сөйләшенең янаул, бәләбәй урынчылыкларына, бөре сөйләшенә хас.

I, II заттагы тартымлы исемнәрнең төшем килешенең угыз телләренә хас вариантта ясалуы: *кулымы* – кулымны, *сүзеңе* – сүзеңне һ.б.

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыльне (*белмәгәнмен, язмаганмын, ынытқанбыз* һ.б.) тартым кушымчалары белән төрләндерү (*белмәгәнем, язмаганым, ынытқаныбыз, барганың* һ.б.).

Дәвамлы үткән заман формаларының әдәби телдәгечә булуы: *-а/-ә* иде (бара иде); *-а/-ә торган иде* (*бара торган иде*); *-адыр/ -әдер иде* (*барадыр иие, киләдер ийе*) һ.б.

Киләчәк заманның ике формасын да әдәби телдәгечә куллану: *барырмын, барачакмын* һ.б.

Эчке теләк формасының әдәби вариантта кулланылуы: *күрәсем килә, эчәселәре килә, барасығыз килә.*

*-асы/-әсе* фигыль формасының булуы һәм аның киң мәгънә функциясендә кулланылуы: *барасы юк, барасы иде* һ.б.

Инфинитив, сыйфат фигыль, хәл фигыль формалары сөйләштә әдәби телдәгечә, башка аерымлыклар аларның фонетик яңгырашларында гына күзәтелә.

Камышлы сөйләшендә көнбатыш диалектка хас мондый күренешләрне билгеләп үтәргә мөмкин:

III зат хәбәрлек исемнәргә күплек кушымчасы ялгану: *алар мондалар, аwылда машиналы кешеләр күпләр;*

Зат һәм күрсәтү алмашлыкларының урын-ара килешләрендә *арга-әргә* кушымчалары кулланылуда көнбатыш диалектның роле булуын күрсәтеп үткән идек.

Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек санда тулы (*барамын*) һәм кыска (*барам*) формаларда кулланылуында шулай ук көнбатыш диалектның йогынтысы бар.

Камышлы сөйләшендә күзәтелә торган *–а+булган* конструкциясе көнбатыш диалектка хас форма (*бара булган* – әд.бара торган булган). Күзәтүләргә караганда, бу форма, бигрәктә, катнаш сөйләшләргә хас: стәрлетамак, волгоград сөйләшләрендә бар.

Сөйләштә күзәтелә торган *-рга кели, -ма кели* төзелмәләре урта һәм көнбатыш диалектларның контакт зоналарында кулланылучан.

Камышлы сөйләшендә кулланыла торган *-гынча/-генчә* варианты да көнбатыш диалект тәэсирендә үсеш-үзгәреш кичерә торган сөйләшләрдә күзәтелә һәм көнбатыш диалект йогынтысы булып санала.

Лексик үзенчәлекләр. Камышлы сөйләше, күргәнебезчә, Казан арты сөйләшләренә бик якын тора, алай гына да түгел, ул әдәби телгә дә бик якын. Шулай булса да, сөйләштә үзенчәлекле сүзләр һәм формалар да очрый.

Биредә, иң башта, сөйләшкә хас лексик сыйфатларны һәм лексик рәвешләрне күрсәтеп үтик: *айырым-суйырым* – бүленеп-җарылып, *беткелегесе* – барысы, *заман* – бик тиз, *зерә* – бик (мамадыш сөйләшендә дә шулай ук), *тыйана* – сәбәпсез, тиктомалга, *башала* – бөтенләйгә һ.б.

Рухи мәдәният белән бәйле сүзләр: *аҁлашу* – ярәшү, *әрчиләр* – арчыйлар, *саwым* – туйга алып барыла торган азык-төлек, күчтәнәч, *урнаш* – аулагый һәм шунда пешерелә торган бәлеш яки башка ризык.

*Туганлык атамаларыннан* түбәндәгеләрне ассызыклап үтәргә кирәк:

– сөйләш *би*-система атамалар таралган зонага керә: *бийем* – каенана, *бийата* – каената;

– *абыстай* – бертуган апа, *аға-быраm* – агай-эне, *инәй//әний* – әни, *әткәй/әтәй* – әти һ.б.;

*Кеше белән* бәйләнешле лексика шулай ук әдәби һәм урта диалекттагыча: *алап аwызлы* – зур авызлы, *иләпән* – симез, *йәншек борын* һ.б.; йамбыз – янбаш (чаг.: мишәрчә шулай ук);

*Каралты-кура* исемнәре Оренбург өлкәсендәге сөйләшләр белән уртаклык күрсәтә: вандуш – саман кирпечтән эшләгән каралты, *түбә* – түшәм, *чиннек* – хуҗалык эшләре белән бәйле әйберләрне куя торган каралты, *абзар/сарай* – җылы абзар һ.б.;

*Аш-су: бекери* – ярты таба зурлыгындагы пирог, *келчә* – кабартма, *тура* – киптереп төелгән шомырт, *ҫатлама* – юка камырны каткат бөкләп, турап пешерелгән камыр ашы һ.б.;

*Тормыш-көнкүреш* белән бәйле сүзләр: *бәллү/бишек* – бишек, *битйаулыҡ/селге* – сөлге, *мискин* – кастрюля, *чуман* – талдан үрелгән зур, тоткасыз кәрзин, *күпчек* – мендәр һ.б. Китерелгән мисаллар мамадыш сөйләшенә дә хас;

*Кийем-салым һәм бизәнү әйберләрен* белдерә торган сүзләр камышлы сөйләшенең богырыслан, каргалы, казан арты сөйләшләре төркеме белән уртаклыгын күрсәтә: *дәwәт* – хәситә, *муйынса* – яка чылбыры, *түбәкәй* – түбәтәй, *алйапҡыч* – алъяпкыч, *ҡуштан* – киң балайтәк, *дуп тун* – тире тун;

*Терек һәм терек булмаган табигать: дуwадаҡ/дуғазаҡ* – бала чыгармый торган каз, *бастурғай* – бүдәнә, *тургай* – чыпчык, *чабата тараҡаны* – кара таракан, *чаған* – өрәңге, *ләкә* - чәчелми калган буразна, *аҡлан* – алан, *әмит* – печән кибәне һ.б.

Шулай итеп, Камышлы төбәгендә катлаулы этник ситуациядә, төрле сөйләшләрнең үзара тәэсир итешүе шартларында мөстәкыйль сөйләш формалашкан. Камышлы сөйләше вәкилләре үзләренең туган телен сакларга, үстерергә тырышып, гореф-гадәтләрен, күркәм традицияләрен үтиләр һәм аларны, тагын да баетып, киләсе буыннарга тапшыруны үзләренең изге бурычлары дип саныйлар.

## ТӨБӘКТӘ ЯЗЫП АЛЫНГАН МАТЕРИАЛЛАР

### Йаңгыр ашы

Йаңгыр ашын без ҡыз wаҡытта Йүкәле таудағы аҡ ҡайын йанында пешерә торған идек. Ҡайсы күкәй, ҡайсы май, эченчесе йарма, йә тағын ит алып чығалар. Карчыклар аш пешкинчә дә, аш пешкәч тә намаз уҡыйлар. Аннан йаңғыр теләү башлана. Бала-чаға: «Йаңғыр, йау, йау, йау, иләкләп тә, чиләкләп!» дип ҡычҡырыша

идек, су сибешә идек. Барыбыз да лычма су буладыр ыйық. Әбиләр түгәрәкләнеп, табын йасап, айырым утыра. Бетенебезгә дә үзебез алып килгән саwытларға аш элешен салалар. И тәмне була да ийы шул йаңғыр ашы. Күпер төбенә киләбез дә, қырдан қайтучыларны кетеп тырабыз, су белән қыйындырадырыйық. Шулай теләгәннән сың, Ходайның рәхмәте белән, без сыраған йаңғыр ызақ кеттермичә йаwып та китәдерийе.

Элек киндер ырлығы чәчә идек. Ул кезгә хатле үсә, аннары аны йылқып, ырлығын суғып аласың чибағаш белән. Сабағын суға батырасың. Ул анда бер айлап йата. Судан чығарғач мунчаға элеп қырытабыз, талқы белән талқыйсың, ул сүс була. Аны су тегермәненә алып барып төйдерәсең, аннан соң қабада эрлисең. Йепне киләпкә саласың, терле-терле буйауға буйыйсың, шуннан киндер суғасың. Анардан күлмәк тегеп кийәсең, алйапқычын-ыштанын да тегәләр ийе шунардан. Читсылар әз булған, байларда ғына.

*Сөйләүче: Рафикова Зәйтүнә,*
*Иске Ярмәк авылы. Эксп., 1978*

**Аулагөй**

Элгәре кичен аулақ иләргә җийыладырыйық, анда күлмәк суғар өчөн йеп эрли идек. Шул арада болафкы йәшереш, арқа суғыш уйнап алабыз, гармун уйнап йәшләр керә йе, бийешә тырған ыйық.

Озақ йаңғыр йаумаса, әбиләр, бала-чаға, без қызлар әрберебез ашамлық җийабыз, су буйында аш пешерәбез, бала-чағаны ашатабыз. Эштән қайтқанда тықрықларда, урамға чығып, алар өстөнә дә су сибәдер ийек.

Боз киткән чақта җәшләр, қызлар гармуннар белән су буйына җийылабыз, анда бийешәбез, көр йегереш уйныйбыз, суға салам йандырып йебәрәбез.

Тече қақы элгергәч урманға барадырыйық, айақларда чыпталы чабата, әрекмән йапрағы белән буйалған чабата кийә ийек, анда қаршы уйын уйный идек. Кырукның эчендә қызлар була, тышта йәшләр була, йегетләр «акну» дийеп арқаға суғып кырукның уртасына алып чығалар. Кемне алып чықсалар, шул кеше йыр йырларға, йә бийергә тийеш була.

*Сөйләүче: Фәттахова Гыйльменур,*
*Камышлы районы, Дәүләткол авылы*

**Каз өмәләре**

Беренче салқыннар төшкәч, аwылда қаз үмәләре башлана. Анда күберәк қызлар, йегетләр қатнаша. қартлар қазларны суйалар, ә без қызлар аларны йолқабыз, эш бик тиз бара, бер генә қызның да йегетләр алдында сынатасы килми, тырышып-тырышып йолқасың. Эше дә тиз барсын, қазның да тиресе йыртылмасын бит әле. Қазларны йолқоп бетергәч, үдә қазларның эчен арчыйбыз. Қазларны ике айағыннан бәйләп, берничәне-берничәне кийәнтәгә асып, су буйына төшәбез. Анда қазларны йақшылап йуwабыз. Хужалар сый-хөрмәт әзерли. Кичкә йал итәргә йәшә. Кичен инде йәшләр җыйылып, уйнап, бийеп, йал итәбез. Қара-қаршы йыр әйтешәбез. Тақмаққа йә гармунға биибез, йөзек йәшереш, күршең белән татумы, шиша тәгәрәтү уйыннары уйныйбыз. Йәшләрнең иң йаратқан уйыны әйлән-бәйлән. Йәшләр қулға қул тотонып, түгәрәк булып басалар, уртада бер кеше була. Җыр бетүгә, уенның тақмағын, җырлағанда, уртадағы кеше үзенә бер пар сайлап ала да қултықлашып бииләр. Аннан соң уйын шулай дәвам итә, тақ қалған кеше уртада қала, тағын бер озын җыр җырлыйлар да тақмақ әйтә башлыйлар.

*Камышлы районы,*
*Гали авылында язып алынды*

**Сугыш вакытында**

Суғыш ацылғацтан ирләрне суғышқа заттық, аwылда бетен эштә қатын-қызлар, бала-цаға калдык. Суғышның бетен аwырлығы безнен эскә теште, әле хазер дә исемдә алар. Игеннәр элгергәц бетен аул халкы қырға цығалар иде, игенне лабагрейка белән уралар иде, бер малай атлар қыwа, икенцесе урылған уцмаларны гиргә (җиргә) тешерә бара, қатыннар келтә итеп бәлиләр. Кез кене йаңғырлар йауа, келтә цылана, эскиртта ул қыры тора. Шайтан арба белән келтәләрне бер куцаға йыштыралар, кибән қуйарға. Башында қартлар тора, кибәнне қуйарға зур осталык кирәк, келтәләрне дерес тезмәсәң су үтә, йә кибән ишелеп тешә. Кибән йанына барабан қуйалар да келтәләрне суғалар. Биш-алты кеше келтә цүwә, ике кеше саламын алып тора, ансын малайлар, без вазилка дибез, шының белән тарттырып алып китә эйеләтырған амут йанына.

Кез кенне урнаш йасыйбыз, бер аулақ үдә, кырук йасап уний идек, бии идек. Йарты тенгә хәдәр, аннар үләребезгә таралыша идек.

*Похвистнево районы,*
*Мәчәләй авылында язып алынды*

**Авыл тарихы турында**

Бақый бабай шушы тауның башына килеп басқан, ди, ақбүз атқа атланып. Алар аға-бырат булғаннар. Йәрмәкнең балалары. Берсе Ғәли, берсе Усман, берсе Бақый. Бу Йәрмәк бабай бик шәп палкабудис булған. Ул үзе төп башқорт икән. Бер патшаны суға ырғытқаннар ачу белән. Шуны Йәрмәк саздан чығарған. Ул, нәрсә бүләк итим, дигән. Ул уйлаған-уйлаған да, мәңгелек җир бир, дигән, Суқ (*елга исеме*) буйыннан бақыр қазық белән гранаwайт итеп патша зимләмирләре айырып биргәннәр. Өч улы җиткәч, Йәрмәк бабай аларны урнаштыра менә шушы җиргә. Қайсығыз қай тешне тели, ат атланып эзлиләр. Ул өзенә дә усатбы ала. Менә шушы Бақый бабай ат менеп килә дә шушы тау башына ақбүз ат белә, қарап тора хәзер, қарый да бу қай төш удобный утырырға, Суқ буйын су баса, теге йақтан қайынлы йылғасы килә. Қайынлы йылғасы буйына утырмый, бу йақны қарый. Мында да йылға бар, чишмәләр дә бар. Шушы чишмәле җиргә йылға буйына урнаша, шушында йәши. Йақыннарын әпкилә, туған-тумачасын. Бай малайын өйләндерә. Балалары була Бақыйның да. Бу килен бик уңған, бик чибәр, бик чиста, ақ тәнле була, ақ ана диб атыйлар аны. Бер истәлек булсын, тарихка кереп қалсын, дип, Ақана, дип атыйлар шушы суны. Шуннан Бақай аwылы башланып китә инде. Ә менә Йәрмәктә Йәрмәк бабай үзе утыра. Бик ипле, бик йайлы җир. Қырлар зур, башта Мәтеби дигән аwылға утыра, Иске Усманға. Шуннан Суқ буйына дип, Йаңа Усманға килеп урнаша балалары. Йәрмәк бабай килгән хәзер тоқомы белән. Кеше әз, йер буш қала. Элгәре бит күчмә халықлар була күченеп йөри торған. Паwузкалыларны туқтата да: «даwай утырығыз, түлке мөселман булсағыз ғына, дингә килсәгез генә» – ди. Бу халықлар мишәрләр, типтәрләр була. «Без үзебез чуқындырудан качып киттек», диләр дә, урнашалар, бер мәхәллә була. Аннар соң унике паwазкәле чуwашларны китертә, аларны да дингә китерә, бер йаққа урнаштыра аларны.

# ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШЛӘР
# ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Флера Баязитова*

Самара өлкәсенең төньяк өлешендәге Похвистнево һәм Камышлы районнарында татар халкының урта һәм мишәр диалекты вәкилләре яши. Әлеге төбәк – Татарстанның һәм Оренбург өлкәсенең «ут күршесе», биредә яшәүчеләр үзара аралашып, йөрешеп торалар.

Самара өлкәсендәге урта диалектка караган сөйләш – фәндә камышлы сөйләше дип билгеләнгән. Ул көнчыгыштан Оренбург өлкәсендәге богырыслан сөйләше, төньяктан Татарстандагы минзәлә һәм мәләкәс сөйләшләре белән тоташа. Камышлы сөйләше беренче мәртәбә 1959–1960 елларда диалектолог Г.К. Якупова тарафыннан өйрәнелгән. Ул, Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласын төзү өчен, махсус программа нигезендә диалектологик экспедицияләргә чыгып, бай материаллар туплаган һәм мәкаләләр бастырып чыгарган. Самара өлкәсе совет чоры елларында Куйбышев өлкәсе дип аталды. Мәсәлән, диалектолог Г.К. Якупованың «Куйбышев өлкәсе татарлары сөйләшенең кайбер морфологик үзенчәлекләре» (1962), шулай ук «Камышлы сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре» (1974) исемле мәкаләләре билгеле. Әлеге материаллардан файдаланып, диалектолог З.Р. Садыйкова «Камышлы сөйләше» дигән мәкалә язып бастырды (2008).

Архив материалларына һәм риваятьләргә караганда, урта диалектның камышлы сөйләшенә кергән татар авылларына Казан арты һәм хәзерге Татарстанның Тау ягы төбәкләреннән күчеп килгән кешеләр тарафыннан нигез салынган. Шулай ук Минзәлә якларыннан күчеп утыручылар да булган. Мәсәлән, Похвистнево районындагы иң зур татар авылы Гали (Алькино) әле соңгы елларга кадәр Татар-

станның Балык Бистәсе районындагы Күгәрчен авылы белән йөрешә, үзләренең чыгышларын шул авыл тарихы белән бәйле дип саный.

Югарыда күрсәтелгән хезмәтләргә һәм үзебезнең 2014 елда Похвистнево һәм Камышлы районнарына оештырылган экспедиция материалларына нигезләнеп, камышлы сөйләшенә кыскача күзәтү ясап китәм.

## Камышлы сөйләше

### *Фонетик үзенчәлекләр*

Сузыкларның ясалышлары һәм составлары ягыннан камышлы сөйләше әдәби телдән аерылмый. Шулай да кайбер авазларның әйтелешендә дә, кулланылышында да берникадәр аерымлыклар күзәтелә. Алар сөйләшнең фонетик үзенчәлекләрен тәшкил итәләр һәм төрле типтагы аваз тәңгәллекләренә кайтып калалар.

*А* авазы, әдәби телдәге кебек, иренләшкән *а*$^{о}$ булып әйтелә: *а*$^{о}$*й, ķа*$^{о}$*рға, ба*$^{о}$*ла*$^{о}$*лар* һ.б.

Камышлы сөйләшенең характерлы үзенчәлекләреннән киң һәм тар сузыкларның, алгы һәм арткы рәт сузыкларының тәңгәллеген санарга була.

*Ы~а* – аерым сүзләрдә билгеле: *йаңы* – йаңа (яңа), *ķыйағаз*/ *ķийағаз* – кәгазь, *сындыķ* – сандык, *тотыш* – тоташ, *апыра* – апара.

*Ы~а, э(е)~ә* күренеше кушымчаларда күзәтелә: а) хәл фигыль формаларында: *барғынчы*//*барғанчы* – барганчы, *килгенче*//*килгәнче* – килгәнче; б) *-ыр*/*-ер* формала киләчәк заман фигыльләрдә: *йаwыр*//*йаwар* – йаwар (явар), *табыр*//*табар* – табар, *үсер*//*үсәр* – үсәр, *көлер*//*көләр* – көләр; в) инфинитивта: *сатырға*//*сатарға* – сатарга, *ķабырға*//*ķабарға* – кабарга, *сөзергә*//*сөзәргә* – сөзәргә.

*А~ы: ķапķан* – капкын: *Ķапķанға бер тычķан эләккән.*

*Ә~и* бер төркем сүзләрдә беренче иҗектә күзәтелә: *мәләш*// *миләш* – миләш, *кәртә* – киртә, *кәм*//*ким* – ким.

*И~ә: сәке*//*сике* – сәке, *пирәмәч* – пәрәмәч, *пилмин* – пилмән, *тирәзә*//*тәрзә* – тәрәзә, *җәйәү*//*җийәү* – җәйәү (җәяү), *фирешто* – фәрештә.

*О, ы~у: монча*//*мынча* – мунча, *ырлау* – урлау, *йыбату* – йуwату (юату), *чыбалу* – чуwалу (чуалу), *быйау* – буйау (буяу).

*У, ү~о, ө: бутķа* – ботка, *бүгелү* – бөгелү, *йүткерү* – йөткерү.

Сирәк очрый торган тәңгәллекләр: *у~а: мурта* – умарта; *и~э(е): мәчит* – мәчет; *ү~ө: үрүк* – өрек; *ү~и: күгәwен* – кигәвен.

Әдәби телдәге арткы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә алгы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *йен* – йон, *берчә* – борча, *бәлчек* – балчык, *кечерткән* – кычыткан, *мәтәштерү* – маташтыру. Алынма сүзләрдә: *әртис* – артист, *әптик* – аптека, *әрмийә* – армия.

Бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге алгы рәт сузыкларына арткы рәт сузыклары тәңгәл килә: *ана* – әнә, *мына* – менә, *кукай*/*күкәй* – күкәй, *йанаша* – йәнәшә (янәшә), *чиклаwык* – чикләwек, *шиша*/ шешә, *чиган* – чегән.

Сузыклар төшү. Сүз башында сонор авазлар алдыннан килгән *и, э, о, ө* сузыклары төшә: *зату* – озату, *йалды* – өйалды, *зақ* – озак. Сүз уртасында һәм ахырында *ә* авазы төшә: *тәрзә*/*тәрәз* – тәрәзә, *иләшә* – ийәләшә (иялəшә). Рус алынмаларында сүз ахырындагы *а* төшә: *гәҗит* – газета, *әптик* – аптека, *кәрҗин* – корзина.

Сузыклар өстәлү. *Ы(е), ө* авазлары өстәлә: *эчерек* – черек, *өтөрмә*/*этермән* – төрмә, *өтөрү* – төрү, *эшәл* – шәл, *ылампы* – лампа, *ыриза* – риза.

Дифтонглар. Камышлы сөйләшендә дифтонгларның монофтонглашу күренеше ике очракта күзәтелә:

тартык авазлар алдыннан килгәндә, *-өй* дифтонгына *-и*$^{й}$ дифтонгонды туры килә: *си*$^{й}$*кемле* – сөйкемле, *и*$^{й}$*лә* – өйлә, *си*$^{й}$*лә* – сөйлә, *ки*$^{й}$*лә* – көйлә.

*Өйрә, өйрәнү, сөйрәү, сөйләү, төймә* сүзләрендә *-өй* дифтонгы монофтонглаша: *үрә, үрәнү*//*өрәнү, сүрәү, сүләү, түмә;*

*-өй* дифтонгы сузык авазлар алдыннан килгәндә *-ей(әй)* яисә *-ий* дифтонгы белән тәңгәлләшә: *сейәк*//*сийәк* – сөяк (сөяк), *кейәнтә*// *кийәнтә* – көйәнтә (көянтә), *кейә*//*кийә* – көйә (көя), *сейәл*//*сийәл* – сөйәл (сөял).

Тартык авазлар ясалышлары белән әдәби телдәгеләрдән аерылмыйлар. Кулланышта гына кайбер үзенчәлекләр күзәтелә.

*Б~w*. Ике сузык арасында килгәндә, әдәби телдәге *w* авазына сөйләштә *б* тартыгы туры килә: *чыбар* – чуwар (чуар), *чыбан* – чуwан (чуан), *йыбату* – йуwату (юату), *чыбалу* – чуwалу (чуалу).

*W~в*. Рус сүзләрендәге ирен-теш *в* авазы сөйләштә ирен-ирен *w* белән тәңгәлләшә: *wагун* – вагон, *силсәwит* – сельсовет, *заwут* – завод, *wакзал* – вокзал, *wәринйә* – варенье.

*М~б*. Аерым сүзләрдә ирен-ирен *б* авазына *м* авазы тәңгәл килә: а) сүз яки иҗек башында: *мере* – бөре, *мереләнгән* – бөреләнгән, *малан*/*балан* – балан, *мәке*/*бәке* – бәке, *бүлме* – бүлбе; б) ике сузык арасында: *чымылдық* – чыбылдык;

*М~н* сүз уртасында: *нәмәрсә* – ни, нәрсә, *чырмау* – чорнау, *үләм* – үлән, *патмус* – поднос;

*Н~м*. Бер төркем сүзләрдә сүз башындагы *м* авазы *н* белән алмашына: *негез*//*мөгез* – мөгез, *нүwек*/*мүк* – мүк, *нүwеш* – диал. мөгеш (почмак).

*П~ф: керпек* – керфек, *йапрақ* – йафрак (яфрак), *тупрақ* – туфрак, *қалпақ* – калфак; алынмаларда: *нәпсе* – нәфес, *пән*//*фән* – фән, *Латыйп* – Латыйф, *Пәрқый* – Фәрхи һ.б.

*Ф~п: фәрдә* – пәрдә, *сәдәф* – сәдәп.

*З~р* тәңгәллеге фигыльләрнең *-қыр*/*-кер* формалы йөкләтү юнәлеше кушымчаларында күзәтелә: *йатқызу*//*йатқыру* – йаткыру (яткыру), *меңгерү*//*меңгезү*//*мендерү* – менгерү, *кигезү*//*кигерү*//*кидерү* – кидерү, *йеткезү*//*йеткерү* – җиткерү, *белгезү*//*белгертү*//*белдерү* – белдерү, *тигезү*//*тигерү*//*тидерү* – тидерү, *үткәрү*//*үткәзү* – үткәрү.

*Т~ч*. Берничә сүздә әдәби телдәге *ч* авазына *т* тәңгәлләшә: *тишмә*/*чишмә*, *тишен*/*чишен* – чишен.

*Й~җ*. Камышлы сөйләшенә сүз башында, нигездә, *й*-ләштерү хас: *йемеш* – җимеш, *йеп* – җеп, *йәнлек* – җәнлек. Шулай ук гарәп теленнән кергән сүзләрдә: *йан* – җан, *йаза* – җәза, *йымға* – җомга, *йамал* – җамал. Ләкин аерым сүзләрнең башында, сирәгрәк сүз уртасында да, *җ* авазы кулланыла: *җиде, җитен, җилтерәтү, җәймә, мөрҗә, Минҗамал*.

*Й* һәм *җ* авазларының параллель кулланылу очраклары да бар: *йыр*//*җыр* – җыр, *йер*//*җир* – җир, *йелпуч*//*җилпуч* – җилпуч, *йаwа*//*җаwа* – җаwап (җавап), *Йәмилә*//*Җәмилә* – Җәмилә һ.б.

*Й~һ*. Ялгызлык исемнәрендә сүз уртасында сузык авазлар алдындагы *һ* авазы төшеп, аның урынына *й* барлыкка килә: *Фәймә* – Фәһимә, *Шийап* – Шиһап, *Майнур* – Маһинур.

*Г~қ*/*к*. Бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында яки сүз башында саңгырау *қ*/*к* авазы яңгыраулаша: *игенче*//*икенче* – икенче, *туғу* – туку, *йаға* – йақа (яка), *тығырық*//*тықырық* – тыкрык, *ғымбағыш*//*гембағыш* – көнбагыш.

*К~т.* Берничә сүздә әдәби телдәге тел очы *т* тарты гына сөйләштә тел арты *к* тәңгәл килә: *түбәкәй* – түбәтәй, *кели* – тели, *келәнче* – теләнче.

*Қ~х* түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *қатын* – хатын, *қаста* – хаста, *қазна* – хәзинә, *Қәдичә* – Хәдичә, *Қәнифә* – Хәнифә.

*Х~қ.* Аерым сүзләрдә әдәби теләге *қ* авазына *х* туры килә: *хәрендәш* – кардәш, *wахыт* – вакыт, *духтыр* – доктор, *тырахтыр* – трактор.

Ассимиляция (авазларның охшашлануы). Түбәндәге сүзләрдә тел очы *н* тартыгы үзеннән соң килгән ирен-ирен *б* авазына өлешчә охшашлана: *умбиш* – унбиш, *умбер* – унбер, *ғымбағыш* – көнбагыш, *Ырымбур* – Оренбург.

Тел очы *н, л* тартыклары үзләреннән соң килгән авазларга өлешчә (ясалу урыны ягыннан) охшашланалар: *бырыңғы* – борынгы, *әллә қачаңғы* – әллә қайчангы, *йаңғыш* – йалгыш (ялгыш) *йаңғал* – йалган (ялган).

Диссимиляция (охшашсызлану) күренеше берничә сүздә теркәлгән: *чешле* – шөшле, *чүкеш* – чүкеч, *патмус* – поднос.

Тартыклар төшү. *Лт* авазлар тезмәсендә *л* авазы төшә: *йуғату* – йугалту (югалту), *қузғату* – кузгалту.

*Ғ/г: сәәт* – сәгать, *тирмән* – тегермән. Гарәп алынмаларында: *азап* – газап, *азаплану* – газаплану, *Аптулла* – Габдулла, *Усман* – Госман, *Әптерәшит* – Габдерәшит; *й: ашаулық* – ашйаулык (ашъяулык); *н: сыңыдан* – соңыннан, *белә* – белән.

*Һ* авазы гарәп-форсыдан кергән сүзләрдә төшә: *әwәс* – һәвәс, *әйбәт* – һәйбәт, *Әдийә* – Һәдия, *Идийәт* – Һидият.

### *Морфологик үзенчәлекләр*

**Исемнәр.** I һәм II зат барлык сандагы тартымлы исемнәрнең төшем килеше угыз телләренә хас кушымча *(-ы/-е)* ярдәмендә дә формалаша: *битеме* – битемне, *китабыңы* – китабыңны. Бу күренеш бигрәк тә өлкән буын кешеләре сөйләше өчен хас.

Икеләтелгән тартым кушымчасы *қай* сорау алмашлыгында, *каршы, туры* бәйлек сүзләрендә һәм кайбер башка сүзләрдә очрый: *Қайсысы* (кайсы) *қайан килгән монда. Кылуп қаршысында аларның өйләре. Аwылның тирмән турысында бабай әйтер. Киленесе үдә тора.*

*-қай/-қәй* иркәләү кушымчасы сөйләштә әдәби телгә караганда активрак кулланыла: а) туганлык терминнарында: *инәкәй/әңкәй, әткәй, абзыкай, бабықай, балақай;* ә) кешегә карата кулланыла торган иркәләү сүзләрендә: *йаныкайым, мескенкәйем, бәбекәйем;* б) *ипекәй сүзендә: Арыш ипекәйен кисәдерийек;* в) *нәрсә, нәстә* сорау алмашлыкларында: *нәрсәкәй, нәстәкәй*.

Сан категориясе. Әдәби телдән аермалы буларак, *-лар/-ләр* күплек кушымчасы III зат хәбәрлек исемнәргә ялганып килә ала: *Атасы белә инәсе мондалар. Алар өйдәләр*.

Алмашлыкларның составы һәм ясалышы ягыннан сөйләш әдәби телдән аерылмый. Шулай да берникадәр үзенчәлекләр табыла.

Зат алмашлыкларының юнәлеш килеше берлек санда, *миңа, сиңа*, аңа формаларыннан тыш, икеләтелгән кушымча белән ясалган *миңарга, сиңарга, аңар/аңарға* рәвешендә дә кулланыла: *Аңарға инде, бәйрәмгә бер йыл хәзерләнделәр. Миңарға бер бабай очрады*.

Күрсәтү алмашлыклары. Әдәби телдәге күрсәтү алмашлыклары (*менә, бу, ул, шул, шушы, теге, әнә* һ.б.) белән беррәттән, сөйләшкә *мона, мына, монау, мынаwы, ана, анау, анаwы, wана* (< рус.) алмашлыклары да хас: *Мынаwы* (менә + бу) *күзем күрми. Анаwы* (әнә + ул) *ғына йортлары ана*.

Сорау алмашлыклары әдәби телдәгечә. *Нәрсә?* сорау алмашлыгы белән параллель *нәстә, нәстәкәй, нәмәстә* вариантлары да кулланыла: *Бер нәстә дә ашамый. Нәстәкәйләрне сорыйсыз?*

**Рәвешләр.** Ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән *-ны/-не, -лыкта/-лектә, -ғылықта/-гелектә* кушымчалары ярдәмендә вакыт рәвешләре ясау актив: *қышны, қышлықта, қышқылықта* – кышын; *җәйне, җәйлектә, җәйгелектә* – җәен.

*-лай/-ләй, -лый/-лий* кушымчалы ярдәмендә рәвеш ясау очраклары бар: *Хәзер тырмыш бүтәнчәләй* (бүтәнчә) *бит. Башқачалый* (башкача) *ишетелгәне йуқ*.

Лексик рәвешләрдә түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә: *бер мәлне* – бервакыт, *замат* – бик тиз, *зерә* – бик: *Зерә тәмне безнең бәрәңге*.

**Фигыльләр.** Затланышлы формалар. Фигыльләр нигездә әдәби телдәгечә. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең I зат берлек саны тулы һәм кыска вариантларда кулланыла: *барам//*

*барамын, күрәм//күрәмен: Мин аны күреп беләмен, хәтерли алмыймын.*

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль (*онытқанмын, онытқансың* һ.б.) сөйләштә тартым кушымчалары ярдәмендә дә төрләнергә мөмкин: *барғаным, күргәнем* (барганмын, күргәнмен), *барғаның, күргәнең* (баргансың, күргәнсең), *барганыбыз, күргәнебез* (барганбыз, күргәнсең), *барганыбыз, күргәнебез* (барганбыз, күргәнбез), *барғанығыз, күргәнегез* (баргансыз, күргәнсез): *Мин эштә булғанымдыр ул wақытта.*

Дәвамлы үткән заман әдәби *-а/-ә иде (-а/-ә + -ыйы/-ийе) (қайта иде), -а/-ә торған иде (килә торган иде), -адыр/-әдер иде, идер иде (-ыйы/-ийе) (сүлидер иде)* формалары белән белдерелә: *Бик эссе йыллар буладырыйы урақ өстендә. Кичке уйыннарға чығадырыйық йәш чақта.*

Камышлы сөйләшендә *-а булған* формасының да шактый киң кулланылуы күзәтелә: *Эч аwыртса, киндер майы эчә булғаннар. Печәнне тырма белән җыйа булғаннар.*

Киләчәк заманның сөйләштә ике формасы күзәтелә.

Билгесез киләчәк заман. I зат берлек санның әдәби телдәге тулы *(-ыр/-ер + -мын/-мен)* формасы белән беррәттән, кыска *(-ыр/-ер + -ым/-мен)* варианты да кулланыла: *килермен//килерем, барырмын//барырым: Сез қайтуға чәй қайнатып қуйарым* (куярмын). *Мин аны күрсәм әйтерем (*әйтермен*).*

Фигыльнең нигезе *р* авазына беткән очракта, I һәм II зат берлек һәм күплек формаларында кушымчадагы *р* авазының берсе төшәргә мөмкин*: барымын* – барырмын, *барыбыз* – барырбыз, *барысың* – барысың, *барысыз* – барырсыз, *күремен* – күрермен, *күресез* – күрерсез.

Билгеле киләчәк заман (*-ачак/-әчәк*) формасы сөйләштә сирәк очрый: *Җир дер селкенәчәк. Wатылачақ түгел ул саwыт.*

Боерык фигыльнең II зат берлек һәм күплек саннары, әдәби телдәгечә, фигыль нигезе белән тәңгәл килә: *уқы – уқығыз, эшлә – эшләгез.*

Теләк фигыль. Әдәби телдә борынгы *-гыры/-гере* формасы усаллык теләүне белдерә: *Тамағына таш кергере* (әтәчкә карата әйтелгән). *Телең қырғыры.*

Сөйләштә мондый фигыльләргә *-сы* тартым кушымчасы ялгана, алар кире һәм уңай теләкне белдерә ала: *Их, шәле читләп бәйләгән булғырысы* (булса иде).

Эчке теләкне белдерү өчен, әдәби телдәге *-асы килә* формасы белән беррәттән, сөйләштә аның *-асы кели* варианты да кулланыла: *Мыннан җәйәү йөрисе килми аның. Суғыш туқталғач та өйгә қайтасы килде. Қайтасы келидерийе. Бик сүләсем дә келәми әле.*

Ният, максатны белдерү өчен *-мақчы, -мақчы бул, -рға телә, -рға келә, -ма келә, -рға ит, -рга* (дип) *исәплә, -рга йөре* формалары таралган: *Мин қызыма барырға келим. Мында кизләү йасама келиләр.*

Камышлы сөйләшендә *-рга кели, -ма кели* формаларының да кулланылуын янәшәдәге күрше мәләкәс сөйләше йогынтысы белән аңлатырга мөмкин.

*-асы/-әсе + -(ы)йы/-(и)йе (-асы/-әсе* иде), *-ырга/-ергә + -ы(ы)йы/(и)йе (ырга/-ергә* иде), *-сын/-сен + -ыйы/-ийе (-сын/-сен* иде), *-са/-сә + -(ы)йы/(и)йе (-са/-сә* иде) формалары, әдәби телдәге кебек, теләкне, киңәшне, үтенечне белдерә: *Wәт сезгә күрсәтәсийе шул киндер күлмәкләрне. Җәй җылы булсыныйы.*

З а т л а н ы ш с ы з  ф о р м а л а р. Инфинитивның сөйләшкә әд. *-ырға/-ергә* формасы хас һәм аның, мишәр сөйләшләрендәге кебек, киңрәк кулланылышта булуы күзәтелә: *Эрәхәт, утын кертергә түгел, су кертергә түгел.*

Тамыры *р* авазына тәмамланган фигыльләргә *-ырга* кушымчасы ялганганда, кушымчадагы *р* төшә (*барыға, керегә*).

И с е м  ф и г ы л ь н е ң  сөйләштә әдәби телдәге *-у/-ү* кушымчалы формасы актив кулланыла: *Дүрт йез йыл, диләр инде аwыл утыруга.*

С ы й ф а т  ф и г ы л ь. Сөйләштә сыйфат фигыльнең *-ыр/-ер* формасы киң кулланылышта йөри: *Килер кеше килми қалмас. Бульшыр кешем йуқ. Барыр wахыт җитә. Ит сақлар урыныбыз йуқ.*

Х ә л  ф и г ы л ь л ә р. Сөйләштә, нигездә, әдәби телдәге формалар киң таралган. Аларның фонетик вариантлары булуы гына үзенчәлекле.

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклыгы, нигездә, әдәби телдәгечә, ягъни *-мый/-ми, -мыйча/-мичә* кушымчалары ярдәмендә ясала. *Мунча керәлмичә қала.* Шуның белән беррәттән, *-мыйчы/*

*-миче* фонетик варианты да актив йөри: *Йықламыйчы китаб уқып утыра. Куйбыштан йазу килмиче хәл итә алмыйбыз. Чәй эчмиче китәсез.*

Хәл фигыльнең әдәби *-ганчы/-гәнче* кушымчалары белән параллель *-гынча/-генчә* фонетик вариантлары да кулланыла: *Сез уқып чыққынчы* (чыкканчы) *тигез җирләр түмгәккә әйләнеп әле. Әрмийәгә киткенче* (киткәнче) *тырактырда эшләде. Қайтқынчы* (кайтканчы) *хаты булмады.*

Әдәби телдәге *-ганда/-гәндә* (кайтканда, киткәндә), *-ышлый/-ешлий* (кайтышлый, китешли) формалары белән беррәттән, сирәгрәк булса да, *-уwышлый, -үwешлий (қайтуwынча, китүwенчә)* кушымчалы хәл фигыльләр дә очрый: *Қайтуwышлый* (кайтышлый) *сезгә дә керербез. Китүwешлий генә күрдем мин аны.*

Әдәби телдәге *-ғач/-гәч* һәм аның катлаулы варианты *-гачтын/-гәчтен* кушымчалы хәл фигыльләр сөйләштә бер үк мәгънәдә йөриләр: *Быраз барғачтын туқтап йал итеп ала. Йаңғыр йауғачтын җил дә туқтады.*

*-мастан/-мәстән* кушымчалы хәл фигыль сөйләштә актив кулланыла. Ул әдәби телдәге *-мыйча/-мичә* формасына туры килә һәм төп эшнең башкарылу рәвешен белдерә: *Бер туқтамастан* (туктамыйча) *эшкә йөри. Йегетне күрмәстән* (күрмичә) *ризалық биргән бу қыз.*

*-мастан/-мәстән* төп эшнең максатын белдерә һәм әдәби телдәге *-мас өчен/-мәс өчен* формасына туры килә: *Нигез саласың буралап суwық кермәстән* (кермәсен өчен). *Тузан кермәстән* (кермәсен өчен) *әләм инде ул пәрдәне.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.** Камышлы сөйләшендә, нигездә, әдәби телдәге бәйлекләр кулланыла. Шуның белән беррәттән, аларның түбәндәге вариантлары да бар: *Белә/белән: Атасы белә анасы мондалар. Чақлы/чикле/чәкле/тигелтен/тигентен, тикле, хәдәре* – хәтле: *Моның ғына хәдәре малайы. Күпергә тикле йүгердем.*

**Теркәгечләр.** Сөйләштә, нигездә, әдәби телдәге теркәгечләр кулланыла. Түбәндәге үзенчәлекне генә күрсәтеп үтәргә мөмкин: *исә* теркәгече сөйләштә әдәби телгә караганда активрак күзәтелә: *Алайса* (алай + исә) *үземә кире бир. Мине күрдисә* (күрде исә), *өйенә кереп қача.*

*Исә* теркәгече кушма җөмләләрдә ешрак кулланыла. Ул сәбәп җөмләдәге үткән заман фигыльләргә ялгана һәм күпчелек очракта зат кушымчалары ала: *Йортқа чықтисәң* (чыктың исә) *малыңтуwарың, терлекләрең бар. Җәйгә чықтым исә, эшкә йөридерийем. Йазға чықтылар исә, җирне тырмалыйлар бер қат.*

## Синтаксик үзенчәлекләр

Сөйләштә, әдәби телдәге чаралар белән беррәттән, *әллә, эрәзе/эрәҗе* (< рус. разве) сүзләре ярдәмендә (сорау кушымчаларыннан башка да) сорау җөмләләр ясала: *Әллә кийәүләре қайтқан? Әллә мунча йақтың, қодача?*

Иярченле кушма җөмләләрдә ияртүче һәм ияргүче җөмләләр, әдәби телдәге чаралар белән беррәттән, *шуннық белән* һ.б. бәйлек сүзләр ярдәмендә үзара бәйләнәләр: *Әле қул аwыртқаннық белән* (аwыртқанға) *ипи салғаным йуқ. Элгәре су қаты булды, шуннық белә* (шуңа күрә) *ашлық уңмады.*

Кушма җөмләләрдәге компонентлар интонация ярдәмендә генә дә үзара бәйләнәләр: *Көннең буйы сүләтеп утыр, сүли ул.*

## Лексик үзенчәлекләр

Камышлы сөйләшенең лексик составы әдәби телгә бик якын тора. Диалекталь сүзләр тормышның төрле өлкәләренә карый. Аларның зур өлешен төрки сүзләр һәм тамырлар тәшкил итә. Сөйләштә, татар сүзләреннән тыш, алынмалар да кулланыла.

Лексик үзенчәлекләрнең кайбер тематик төркемнәрен генә күрсәтеп китәбез.

Туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр: *инәй//инәкәй//әнекәй//әний – әни, әткәй//әтәй//әтий – әти, әбкәй/әбий – әби, бабақай//бабай – бабай, абыстай* – а). үзе белән бертуган апа, б) үзеннән олы хатын-кыз; *тута(й)* – үзе белән бертуган апа, *түтәй/түткәй* – а) үзе белән бертуган апа, б) әтисе яки әнисенең апасы яки сеңлесе, в) иренең апасы; *быраm//абзый//абзықай* – бертуган абый, *быраm//эне//*энекәш – эне; *аға – быраm – агай* – эне, *ылан* – бала, *берләч* – бер генә, бердәнбер бала, *бийем* – каенана, *бийата(й)* – каената, *бийаға* – иренең абыйсы.

Кеше белән бәйле сүзләр: *алап аwыз* – зур авызлы, *қырчын* – әрсез, *мышый* – мыштым, астыртын, *телен телчә йарған* –

тел бистәсе, *йамбыз* – янбаш, *танау* – борын, *чәлтер* – балтыр, *чәркә* – сыйрак, *тәкмәрләп төшү* – мәтәлеп төшү.

Й о л а л а р: *ақлашу* – кызны ярәшү, ризалык бирү, *йақшы сүз бирү* – вәгъдә бирү, *битйаулық бирү* – ризалык билгесе итеп сөлге бирү, *кәләшкә керү* – кыз куенына керү, *әрчи йегете* – кияү егете, *кеше үткәрү* – мәҗлес ясау, *урнаш* – а) аулак өй. б) аулак өйдә пешерелә торган ашамлык.

Т ө з е л е ш, к а р а л т ы – к у р а һ.б.: *бүлкә* – бүлмә, *тупса* – бусага, *түбә тақтасы//түбә* – түшәм, *түшәм* – өсте турыга япкан лапас, *кәчәк//тәрәзә йаңағы* – тәрәзә яңагы, *ишегалды* – өй алды, *табақлық* – аш өендә савыт-саба куюе өчен стенага беркетеп ясалган шүрлек, *усатбы* – йорт урыны, *чиннек* (< рус. сенник) – печән, арба, чана һ.б. йорт кирәк-яраклары кую өчен такталардан ясалган каралты, *абзар//сарай* – кыш көне мал ябу өчен ясалган җылы каралты, *карды* (< рус. карда) – җәен мал ябу өчен ясалган өсте ачык каралты.

А ш а м л ы к л а р: *баwырсақ* – чәкчәк, *ширпылы қатлама* – (йомыркага һәм каймакка басылган камырны юка итеп җәеп, аны берничә кисәккә кисеп, һәр кисәкне аерым-аерым итеп майда кыздырып алалар һәм берсе өстенә берсен куеп, катлы-катлы итеп төрәләр; катлама таралып китмәсен өчен, аңа каен агачыннан ясалган шырпылар кадап куялар), *бөкөри* – бөккән, *қара бит* – өстенә төелгән киндер орлыгын ягып пешерелгән кабартма, *қыстырған* – эченә төелгән шомырт яки балан салып пешерелгән күмәч, *пажалу* – өшегән бәрәңге күмәче.

К ө н к ү р е ш ә й б е р л ә р е: *битйаулық* – сөлге, *бәллү//бишек* – бишек, *күпчек* – мендәр, *бидрә//чиләк* – чиләк, *тустыған* – чынаяк чокыры, *мискин* – кастрюля, *аштабақ//шаwа* – зур табак, *қашықлық* – кашыклар тезеп кую өчен ясалган шүрлек, *себерке* – ат тырмасы.

К и е м - с а л ы м: *түбәкәй* – түбәтәй, *муйынса* – яка чылбыры, *айлапқыч* – алъяпкыч, *куштан* – бала итәк.

Т а б и г а т ь, җ и р - с у: *ақлан* – ачыклык җир, *нажқағай* – аҗаган, *ләкә* – чәчми калдырган җир (буразна), *чаған* – өрәңге, *умит// әмит* – печән эскерте.

Х а й w а н н а р: *дуwадақ* – а) бала чыгармаган ялгыз кош-корт, б) йортсыз, нәсел-нәсәпсез кеше; *бастурғай* – бүдәнә, *чабата тарақан* – зур кара таракан, *селәүчән* – суалчан.

## Мәләкәс сөйләше

Самара өлкәсенең төньяк районнарындагы кайбер татар авылларының сөйләше мишәр диалектына карый. Бу сөйләш күрше Ульяновск өлкәсендә таралган мәләкәс сөйләшенең дәвамы булып тора. Бу территориягә татарлар (нигездә темников мишәрләре) XVII гасыр урталарында Сембер һәм Самара ныгытылган хәрби линияләрен төзү эшләре белән бәйле рәвештә, шулай ук ирекле күчү юлы белән дә килеп утырганнар. Самара өлкәсендәге мәләкәс сөйләше Г.К. Якупова, З.Р. Садыйкова тарафыннан өйрәнелгән («Татар халык сөйләшләре». Ике китапта: Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казань: Мәгариф, 2008. 96–103 битләр). Мәләкәс сөйләшен тасвирлаганда З.Р. Садыйкова мәкаләсе һәм Л.Т. Мәхмүтованың «Опыт исследования тюркских диалектов» (М., 1978) исемле монографиясе файдаланылды. 2014 елдагы җәйге экспедиция вакытында Самара өлкәсенең Похвистнево һәм Камышлы районнарындагы Иске Мәчәләй, Яңа Мәчәләй, Яңа Мансур, Балыклы авылларының сөйләше мишәр диалектына караганлыгы ачыкланды.

### *Фонетик үзенчәлекләр*

Мәләкәс сөйләше фонетик үзенчәлекләре ягыннан мишәр диалектының башка сөйләшләре белән уртак. Шулай да сөйләшне билгели торган аерымлыклар да бар. Алар, нигездә, кайбер авазларның әйтелешендә, аваз тәңгәллекләрендә һ.б.да чагыла.

**Сузыклар.** Сөйләштәге сузык авазлар, бигрәк тә *а, ә, ү* авазлары, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, алгырак позициядә ясалалар.

*А* сузыгы – иренсезләшкән, арткы рәт авазы: *кар, карт, барабан.*

*О~ө* ирен сузыклары, иренсезләшеп, *ы~е* булып әйтеләләр: *сылы* – солы, *тырмыш* – тормыш, *тезелеш* – төзелеш. Башка мишәр сөйләшләрендәге кебек, бер төркем сүзләрдә *о* авазы үзе дә әйтелә: *осак* – усак, *орлау* – урлау, *корчак* – курчак һ.б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә, төрле фонетик күренешләргә кайтып кала.

Сузыклар тәңгәллеге. *ы~а, э(е)~ә* аерым сүзләрдә күзәтелә: *йаңы* – йаңа (яңа), *кагыз/кәгыз* – кәгазь, *малый* – малай, *сындык* – сандык һ.б.

*Ы~а, э(е)~ә* күренеше кушымчаларда да чагыла: а) хәл фигыль формаларында: *баргынчы(к)/баргынча(к)* – барганчы, *килгенче(к)/килгенчә(к)* – килгәнче; ә) *-ар/-әр* кушымчалы фигыль формаларында: *табыр* – табар, *йаwыр* – йаwар (явар), *үлер* – үләр, *келер* – көләр, *белер* – беләр, *сатырга* – сатарга, *кабырга* – кабарга һ.б.

*Ә~и.* Бер төркем сүзләрдә сүзнең беренче иҗегендә әдәби телдәге тар *и* сузыгында киң *ә* сузыгы тәңгәлләшә: *шәкәр* – шикәр, *мәләш* – миләш, *кәбән* – кибән, *кәртә* – киртә, *әпәй* – ипи. Икенче иҗектә: *әнәй* – әни, *әтәй* – әти, *җиңги* – җиңги.

*И~ә* берничә сүздә күзәтелә: *тирәзә/тирәз/тәрәз* – тәрәзә, *фирештә* – фәрештә, *пике* – пәке, *кифен* – кәфен, *силәзин* – диал. *силәзән* – ата үрдәк, *әзрәк* – азрак.

*О, ы~у: монча/мынча* – мунча, *орлау/ырлау* – урлау, *осак/ысак* – усак, *корчак* – курчак, *олым* – улым, *Абдылла* – Габдулла.

*У, ү~о, ө: бутка* – ботка, *куңгырт* – коңгырт, *үмә* – өмә, *үрә* – өйрә, *Үмәр* – Гомәр.

*Ө, е~ү: төгел/тегел* – түгел, *бөген/беген* – бүген, *кеңел* – күңел

Әдәби телдә алгы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә арткы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *йанаша* – йәнәшә (янәшә), *кыдра* – көдрә, *циклаwык* – чикләвек, *кукай* – күкәй, *капыста* – кәбестә, *корка* – күркә, *чаука* – чәүкә, *кычык* – көчек, *чиган* – чегән, *шиша* – шешә, *лаука* – ләүкә.

Әдәби телдә арткы рәт сузыклары белән әйтелә торган бер төркем сүзләр сөйләштә алгы рәт сузыклары белән әйтеләләр: *бәлчек* – балчык, *кечеркән* – кычыткан, *чебелдек* – чыбылдык, *йен* – йон, *чәндер* – чандыр.

С у з ы к л а р  т ө ш ү. Сүз башында сонор авазлар алдыннан килгән *о, у, и, ө, э(е)* сузыклары төшә: *мурта* – умарта, *йәрләү* – ийәрләү (иярләү), *зату* – озату.

Ике сүз арасында килгән беренче сузык төшә: *кыраш* – коры аш (итсез аш), *балитәк* – балаитәк.

**Дифтонглар.** Мәләкәс сөйләшендә, башка мишәр сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглаша.

*-өй* дифтонгы, монофтонглашып, *ү* гә күчә: *ү* – өй, *сүлә* – сөйлә, *кү* – көй, *чү* – чөй, *түмә* – төймә.

*-өй* дифтонгы монофтонглашканда, күтәрелешләре төрле булган сузыклар арасында ирен-ирен *w* тартыгы барлыкка килә: *сүwәк* –

сөйәк (сөяк), *сүwәл* – сөйәл (сөял), *күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *күwә* – көйә (көя).

*-өй, -әй, -уй, -ый* дифтонглары монофтонглаша. Бу очракта ике сузык арасындагы тартыклар палатальләшә: *бар'ам* – бәйрәм, *кат'а* – кайта, *ад'а* – әйдә, *кас'ы* – кайсы, *ар'ан* – әйрән, *бун'* – муйын (муен), *кур'ик* – койрык, *кун'* – куйын (куен).

*-ой, -ый* дифтонглары *-ий* дифтонгына күчә: *киймак* – коймак, *кийаш* – койаш (кояш), *кийар* – кыйар (кыяр), *сийыр* – сыйыр (сыер).

**Тартыклар.** Мишәр диалектына караган барлык сөйләшләрдәге кебек *ук, к, г, ң, х* авазлары сөйләштә тел арты тартыклары булып әйтеләләр: *карга* – карга, *кабак* – капка, *хазер* – хәзер.

Әдәби телдәге өрелмәле *ч* авазы сөйләштә кушык аваз *тч* булып әйтелә: *тчыбык* – чыбык, *тчаука* – чәүкә, *петчән* – печән һ.б. Сирәк очракта *ц*-лаштыру да күзәтелә: *пиц* – пич (мич), *цугынган* – чукынган, *баргацтан* – баргач, *канигәц* – каенигәч.

Сүз башында әдәби *җ* авазына *дҗ* кушык авазы, аерым очракларда *дз, з* авазлары тәңгәл килә: *дзил/зил* – җил, *дзийылыш/зийылыш* – җыелыш; сүз уртасында *з~җ: мердзә//мерзә – мөрҗә* – морҗа, *пәзи* – пәҗи, *кәзә* – кәҗә, *база* – баҗа.

Тартыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр авазлар тәңгәлләшүенә һәм төрле комбинатор үзгәрешләргә кайтып кала.

*Б~w.* Билгеле бер төркем сүзләрдә ике сузык арасында килгән әдәби *w* авазына сөйләштә *б* тартыгы туры килә: *чыбар* – чуwар (чуар), *чыбан* – чуwан (чуан), *йыбату* – йуwату (юату), *чыбалу* – чуwалу (чуалу).

*Б~м: буны* – муйыны (муены), *бучкы* – мичкә, *гарбун* – гармонь.

*М~б* түбәндәге сүзләрдә күзәтелә: *малан* – балан, *мере* – бөре, *күзмәләш* – күзбәйләш (уены).

*П~б.* Составында саңгырау *т* авазы булган сүзләрдә сүз башындагы яңгырау *б* авазы саңгыраулаша: *пыт* – бот, *пет* – бет, *пытак* – ботак, *патинка* – ботинка, *пытпылдык* – бытбылдык (кош).

*М~н* берничә сүздә күзәтелә: *үләм* – үлән, *җилем* – җилен, *патмус* – поднос, *чырмау* – чорнау, *комбагыш* – көнбагыш.

*П~ф* билгеле бер төркем сүзләрдә һәм кеше исемнәрендә күзәтелә: *тупрак* – туфрак, *йапрак* – йафрак (яфрак), *калпак* – калфак, *керпек* – керфек, *Сапый* – Сафый, *Патыйма* – Фатыйма.

*Н~м: нүwеш* – диал. *мөгеш* – почмак, *нүwек* – мүк, *нүгез* – мөгез, *калын* – калым, *тырнау* – тырмау, *түндәк* – түмгәк.

*Н~ң* хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләрдә, күрсәтү алмашлыкларында күзәтелә: *барасын* – барасың, *киләсен* – киләсең, *алырсын* – алырсың, *күрерсен* – күрерсең, *анарга* – аңарга, *шонарга* – шуңарга, шуңа.

*Р, н~л* берничә сүздә: *шауный* – шаулый, *йындыз* – йолдыз, *шурба* – шулпа.

*Д~т: дустыган* – диал. *тустыган* – аш чүмече*, күwәндә* – көйәнтә (көянтә), *ибдәш* – иптәш, *абдырау* – аптырау.

*Т~ч.* Билгеле бер төркем сүзләрдә әдәби телдәге *ч* авазына *т* тартыгы тәңгәл килә: *тишмә* – чишмә, *тиш* – чиш, *тишенү* – чишенү.

*И~җ.* Сүз башында, нигездә, *й*-ләштерү хас: *йер* – җир, *йеп*,– җеп, *йыр* – җир, *йыма* – җомга, *йаза* – җәза, йаwап – җавап.

*Г~к.* Аерым сүзләрдә ике сузык арасында яки сүз башында саңгырау *к* авазы яңгыраулаша: *чигеркә* – чикерткә, *тыгырык* – тыкрык, *тугу* – туку, *йага* – йака (яка), *сигезән* – сиксән, *тугызап* – туксан, *игенче* – икенче.

*К~г.* Яңгырау *г* авазының саңгыраулашуы: *сикез* – сигез, *тукыз* – тугыз, *кебе* – гөбе.

*К~ү.* Бер төркем татар сүзләрендә һәм кайбер алынмаларда да әдәби телдәге *х* авазына сөйләштә *к* авазы тәңгәл килә: *катын* – хатын, *йакшы* – йахшы (яхшы), *маскар* – мәсхәрә, *каста* – хаста, *җымак* – оҗмах.

*Х~к: wакыт//wахыт* – вакыт, *кадәр//хадәр* – кадәр, *духтыр* – доктор, *тырахтыр* – трактор.

Ассимиляция (авазлар охшашлануы). Кайбер сүзләрдә тел очы *н* тартыгы үзеннән соң килгән ирен-ирен *б* авазына охшашлана: *умбиш* – унбиш, *умбер* – унбер, *гөмбагар* – көнбагыш.

*Л* авазы үзеннән соң килгән *г* авазына өлешчә охшашлана: *йаңгыз* – йалгыз (ялгыз), *йаңгал* – йалган (ялган), *йаңлыш//йаңгылыш* – йалгыш (ялгыш), *аңгару* – аңлау.

Тартыклар төшү. *Лт* тезмәсендәге *л* төшә: *йугату* – йугалту (югалту), *итү* – илтү, *кузгату* – кузгалту.

Гарәп алынмаларында тирән тел арты *ғ* авазы төшә: *айып* – гайеп (гаеп), *аза* – әгъза, *сәәт* – сәгать, *Абдулла* – Габдулла, *Нәймә* – Нәгыймә, *йыма* – җомга.

Гарәп-фарсы алынмаларында *h* авазы төшә: *әр* – һәр, *ич* – һич, *әммәсе* – һәммәсе, *шәәр* – шәһәр, *Гелҗийан* – Гөлҗиһан, *Майнур* – Маһинур, *Шийап* – Шиһап, *Фәймә* – Фәһимә.

### *Морфологик үзенчәлекләр*

**Исемнәр.** I һәм II нче зат берлек сандагы тартымлы исемнәрнең төшем килеше кыскартылган *-ы*/*-е* кушымчалары белән, ягъни угыз телләрендәгечә формалаша: *Күземе* (күземне) *кийаш чагылдыра. Шатлыгымы* (шатлыгымны) *уртаклашыр кеше йук. Бер куйымы* (куемны – әд. сарыгымны) *саттым*.

III зат берлек санда икеләтелгән тартым кушымчасы ялгану очраклары бар: *Катнысы* (хатыны) *эшкә йөри башлаган. Берсесе* (берсе) *дә сүземне тыңнамый* (Берсе дә сүземне тыңламый).

*-кай*/*-кәй* иркәләү кушымчасы сөйләштә, әдәби телдәгегә караганда, активрак кулланыла. Ул туганлыкны белдергән исемнәргә ялгана: *бабакай, әбекәй, әтекәй, анакай, тутакай, абзыкай, йаныкай*.

Кыскартылган кеше исемнәренә *-ай*/*-әй, -ук* кушымчалары ялганып килә. Бу очракта иркәләү мәгънәсе сакланмый диярлек: *Ибрай – Ибраһим, Марук – Мәрьям, Исмай – Исмәгыйль, Латук – Латифа*.

**Алмашлыклар.** Зат алмашлыкларын куллану буенча сөйләштә үзенчәлекләр күзәтелми.

Күрсәтү алмашлыклары. Әдәби телдәге (*менә, әнә, бу, үзе, шул, теге*) күрсәтү алмашлыклары белән беррәттән, сөйләштә *мын, муни, мыни, мынигынак, ана, ват, вата, ватә, ванә, ване* (< рус) һәм тартым кушымчалы *бусы, улсы, шулсы* алмашлыклары актив кулланыла.

*Шул* күрсәтү алмашлыгыннан ясалган *шолай, шылай, шондый, шындый, шонарга, шынарга* сүзләре сөйләштә актив кулланыла.

Сорау алмашлыклары. Әдәби телдәге *нәрсә, ничек* сорау алмашлыклары урынына *нәстә* алмашлыгы йөри: *Нәстә халләр?* – Хәлләр ничек?

**Сыйфатлар.** Сөйләштә сыйфатларның грамматик формалары, кулланылышы әдәби телдәгечә. Үзенчәлек итеп түбәндәгене күрсәтергә мөмкин: *зур* һәм *кече* асыл сыйфатларының чагыштыру дәрәҗәсен икеләтелгән (*-раг*/*-рәг* + *-рак*/*-рәк*) кушымча өстәп ясау очраклары бар: *Бу кечрәгрәге* (кечерәге) *кызымның. Зурракрагы* (зуррагы) *йукмы халатның?*

Саннарның ясалышы һәм кулланылышы әдәби телдәгечә.

**Рәвешләр.** Лексик рәвешләрне куллану буенча сөйләш, нигездә, әдәби телгә якын тора. Диалекталь характердагы лексик рәвешләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: *батыр* – яхшы, нык, *шап-шактый* – әйбәт итеп, *берцәк/берцик* – бераз, *буйлата* – тоташтан, *гелән* – һаман, *тенә* – кичә, *үңгә/үзгә* – башка, *дырук* – кинәт, *насила* – көч-хәл белән. Мисаллар: *Алма-тилмә эшлиләр чегендердә. Укырга бик батыр безнең балалар. Алар үңгә сүлиләр, безнеңчә төгөл.*

Ясалма рәвешләр, нигездә, әдәби телдәге чаралар белән ясалалар. Кайбер аермалыклар да бар.

*-лата/-ләтә* кушымчалары белән рәвешләр ясалу шактый актив: *Әдә утыр, аша кан'арлата* (кайнар көе). *Әллә кырылата* (коры килеш), *әллә йүwешләтә* (йүwеш килеш) *чабыша минек белән.*

*-лый/-лий: Бу чечелиме* (төче камырданмы) *питрач? – Йук, ачылый* (ачы камырдан). *Кан'арлый* (кайнар килеш) *ашап куйам ашны.*

Сөйләштә *кышын, җәйен, йазын, көзен* вакыт рәвешләре белән беррәттән, *кышлыгын, кышлыкта, җәйлеген, җәйлектә, көзлеген, көзлектә, йазлыгын, йазлыкта* рәвешләре дә кулланыла: *Җәйлектә аwылга кат'ам. Кезлегендә капыста пиругы пешерәм.*

*Кен (тен) буйы, кыш (җәй) буйы, йаз (кез) буйы* тезмәләре белән беррәттән, *тен ката, кыш ката, йаз ката, кез ката, кен сәтә* кебек катлаулы рәвешләр дә актив: *Кене буйы эштә утыра. Тен ката* (төн буйы) *йаңгыр йауды.*

**Фигыльләр.** Затланышлы фигыль формалары. Хикәя фигыль. Сөйләштә хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек саны кыска (*барам, киләм*) һәм тулы (*барамын, киләмен*) вариантларында кулланыла: *Куй итен бик йаратып бетермимен. Урамга чыксам, тауны күрәмен.*

II зат берлек санда хәбәрлек кушымчасының борынгырак *-сын/-сен* варианты сакланган: *И йерәк кенәм, бик матур йырлыйсың.*

Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат берлек саны, әдәби телдән аермалы буларак, еш кына *-дыр/-дер* хәбәрлек кушымчасы ялганып ясала: *Сүлидер дә* (сөйли дә) *үзе келәдер* (көлә).

Билгеле үткән заман, әдәби телдәге кебек, фигыль нигезенә *-ды/-де* кушымчасы ялганып ясала: бар *-ды-м, кил -де-м. Печәнеме чаптырдым. Аwылга иректем* (авылны сагындым).

Нәтиҗәле үткән заман, әдәби телдәгечә, *-ган/-гән* кушымчасы ялганып ясала (*күр-гән-мен, күр-гән-сең*), аны зат һәм сан кушымчаларыннан башка куллану очраклары да бар: *Мин шолай үдә йаткан* (ятканмын). *Син әле бер нәстә күрмәгән* (күрмәгәнсең).

Моннан тыш, сөйләштә нәтиҗәле үткән заманның *-ып/-еп/-п* + хәбәрлек кушымчасы белән ясалган формасы да актив йөри: *Ничә аwылга чыгыпсын* (чыккансың), *әйбәт туфли дә кимәпсен* (кимәгәнсең). *Үзебезнең кешегә китепсен* (баргансың).

Дәвамлы үткән заман сөйләштә әдәби (*-а* иде) формасы белән белдерелә*: Бу wакытта урамда утыралар иде карчыклар. Ыйык кийә идек саплыны* (кунычлыны).

Билгеле киләчәк заман (*-ачак/-әчәк*) сөйләш өчен характерлы түгел. Бу форма сирәк кенә *йук* һәм *төгөл* сүзләре белән кулланыла: *Анда барып, ызак тырачагым йук* (озак тормаячакмын).

Боерык фигыльнең ясалышы һәм кулланылышы әдәби телдәгечә: *укы, эшлә*. Мәсәлән: *Буш баллунымны нүwешкә куй. Йырлар йырлагыз.*

Теләк фигыль. Эчке теләк (*-асы килә*) сөйләштә *-гы/-ге, -кы/-ке* + *кел* конструкциясе белән белдерелә: *Казанга бәк баргым кели* (барасым килә). *Йемешсез чәй эчкем keләми. Йылагым келәп китте* (елыйсым килеп китте).

Максатны, теләкне белдерү өчен *-ма/-мә* формасы һәм *кели* (< тели) ярдәмче фигыле белән ясалган конструкция кулланыла (*барма кели, килмә кели*): *Мине ике балам белән шушы кеше алма keләде* (алырга теләде). *Айытка барма келибез* (барырга телибез).

*-ырга кели* формасы сирәк кулланыла: *Тырырга келәми* (теләми) *аwылда. Йаңгыр йаwырга кели* (тели) *ахырсы.*

Максатны, ниятне белдерү өчен инфинитивның *-мак/-мәк* кушымчалы архаик формасы һәм *келә* ярдәмче фигыле белән ясалган конструкциясен куллану да очрый: *Ирләр чакырмак келибез* (чакырмакчы булабыз).

Фигыль юнәлешләре. Билгеле булганча, мишәр һәм урта диалект сөйләшләре йөкләтү юнәлешен формалаштыруда бераз аерылалар: урта диалекттагы *-кыр/-кер, -гыр/-гер* (яктыр, үткәр, кигер) кушымчаларына мишәр диалектында шуларның з- вариантлары тәңгәл килә )яткыз, күргәз, үткәз), гомумән, мишәр диалектында *-гыз/-гез* вариантлары киңрәк кулланыла.

Самара төбәгендәге мишәр сөйләшендә йөкләтү юнәлешендәге ике вариантның икесен дә куллану тенденциясе күзәтелә: *нидер/кигез, кигер, белдер/белгез/белгерт, йаткыр/йаткыз, үткәр/үткәз, мендер/меңгез/меңгер*.

Уртаклык юнәлеше урынына төп юнәлеш формасын куллану очраклары бар: *Катының белә йакшы сүлә* (сөйләш).

Төп юнәлеш урынына кайтым юнәлешен куллану: *Йыртта тайылып* (таеп) *йыгылдым. Йегетләр кергәндә селге астына качынып* (качып) *утыралар кызлар.*

Фигыль дәрәҗәләре сөйләштә *-гакла/-гәклә, -акла/-әклә, -ыкла/-екл*ә кушымчалары белән ясалалар: *Эшләкләдем* (эшләштердем) *дә тирләдем. Укыклыйбыз* (укыштырабыз) *инде гәҗитне*.

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитивның *-ырга/-ергә* формасы хас: *Миңа да кеше күрегә кирәк, ди*.

Исем фигыльнең сөйләштә *-у/-ү* кушымчалы формасы кулланыла: *Хазер печән чабу wакыты. Хазер урманга йерү йук*.

Исем фигыльнең *-ыш/-еш* формасы да күзәтелә: *Әллә сезнең йакта дәwәни дийешме* (дияләрме?). *Кызларны элек сыратып биреш* (бирү гадәте) *иде.*

Сыйфат фигыль. Хәзерге заман сыйфат фигыль, әдәби телдәге кебек үк, *-а/-ә/-й + тырган* (кийә торган күлмәк) һәм *-учы/-үче* (белүче кеше) формалары белән белдерелә: *Артымнан килүче кеше йук*.

Киләчәк заман сыйфат фигыль *-ар/-әр, -ыр/-ер/-р* кушымчалары белән формалаша: *барыр урын, күрер күз, йегәр алаша*.

Хәл фигыль. Сөйләштә *-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыль киң кулланыла: *Куйларым бар, алар кез кене бәрәннәп куйалар. Ызбаларын сатып киттеләр.*

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклыгы әдәби телдә *-мый/-ми, -мыйча/-мичә* формалары белән ясала. Сөйләштә, болардан тыш, *-мыйнча(к)/-минчә(к), -мыйчы/-миче, -мыйынча/-мийенчә* вариантлары да кулланыла: *Эшләмиче* (эшләмичә) *эш чыкмый. Кунаклар килмичәк* (килмиче) *ашны өстәлгә куймагыз*.

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* һәм *-гачтан/-гәчтән* кушымчалы хәл фигыльләр актив кулланылышлы: *Кар йаугач ук йулга чыгабыз. Эш беткәчтән* (беткәч) *көч тә бетте.*

*-ганчы/-генче* кушымчалы хәл фигыльнең сөйләштә *-гынчы/-генче, -гынча(к)/-генчә(к)* кушымчалы вариантлары еш кулланыла:

*Кат'ып җиткенче* (җиткәнче) *йырлап кат'т'ы. Аш пешкәнчәк* (пешкәнче) *үдә генә утырдым.*

*-мастан/-мәстән (-масын өчен*) кушымчалы хәл фигыль төп эшнең максатын белдерә: *Сөт ачымастан* (ачымасын өчен) *пүгрәпкә* (базга) *куйдым.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.** Сөйләштә, нигездә, әдәби телдәге бәйлекләр кулланыла. Моннан тыш, аларның түбәндәге вариантлары да бар: *белә/беләп* – белән. *Икешәр пила белә* (пычкы белән) *килеп утын кистеләр.*

*Сартын* (өчен, хакында): *Үлем сартын* (хакында) *сүләдек әле. Шул ыланы сартын* (өчен) *китте.*

Максат мөнәсәбәтен белдергәндә, *өчен* бәйлегенә *-гә* юнәлеш килеше кушымчасы ялгана: *Кышлык эченгә* (өчен) ашлык чәчкәннәр.

*Ката, сәтә* бәйлекләре, тәүлек һәм ел фасылларын белдерә торган сүзләр белән килеп, дәвамлы вакытны белдерә: *кыш ката* (кыш буе), *тен ката* (төн буе), *кенсәтә* (көн буе): *кенсәтә* (көн буе) *сине сүләдек. Кыш ката* (кыш буе) *урман кистек.*

**Теркәгечләр.** Сөйләштә әдәби телдәге теркәгечләр кулланыла: *да/дә, та/тә, ни, әле, ә, тик, йә, әллә, әгәр, әгәр дә ки.*

Кисәкчәләр. Сөйләштә әдәби телдәге кисәкчәләр (*бик, инде, гына, ук* һ.б.) актив кулланыла. Шулай да кайбер үзенчәлекләрне билгеләп үтәргә мөмкин. *Бит, ич* раслау кисәкчәсе урынына *вет, вит* (< ведь) рус теленнән кергән алынма еш очрый: *Дөрес вит* (бит) *инде.*

Мәгънәләре ягыннан күрсәтү алмашлыкларына якын торган *мени, мыни, муни*; рус теленнән кергән *вата, вана* кебек кисәкчәләр актив йөри. *Әмән* – охшату-чагыштыру кисәкчәсе: *әмән ут* (гүя ут), *йыгыра гына.*

### *Лексик үзенчәлекләр*

Лексиканың зур өлешен гомумтатар сүзләре һәм тамырлары тәшкил итә. Сөйләштәге диалекталь сүзләрнең күбесе мишәр диалектының башка сөйләшләре белән уртак. Рус, гарәп, фарсы, мордва телләреннән кергән сүзләр дә бар. Биредә диалекталь лексиканың кайбер тематик төркемнәрен күрсәтеп китәбез.

Й о л а л а р , б ә й р ә м н ә р белән бәйләнешле сүзләр һәм сүзтезмәләр: *саwым* – туйга алып барыла торган күчтәнәч: гадәттә азыктөлек һәм ике каз; *мәзәк* – яшьләр кичәсе, аулак өйдә үткәрелә торган кичә, *кәләшкә керү* – кыз куенына керү, *әрчи йегете* – кияү егете һ.б.

Туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр: *әнәй//анай//анакай* – әни, *әтәй//атай//атакай* – әти, *әби//әбкәй//зур әнәй* – әби, әтисенең яки әтисенең әнисе, *бабай//бабакай* – бабай, әнисенең яки әтисенең әтисе, *абыстай//апа//тутай* – бертуган апа, *әзи//әбзәй//әзәй* – бертуган абый, *әптәй* – а) үзеннән олы кардәш хатын-кыз; б) олы яшьтәге хатын-кыз; *дәдәй* – әнисенең яки әтисенең абыйсы, хәрендәш-нәсел, *бырат* – ир туганы, *ылан* – бала, *нук//нука* – оныक, *тудыкай* – туганнан туган, *йиңгә/җиңгә/җиңгәчи* – абыйсының хатыны, *бертума* – бертуган, *тумачи* – каенсеңел белән җиңги тиңдәш булган очракта бер-берсенә эндәшү сүзе, *абыз астай* – каенсеңелләренә эндәшү сүзе, *тайым* – үзеннән кечеләргә иркәләп эндәшү сүзе.

Кешенең тән төзелешен, сыйфатларын белдерә торган сүзләр: *табан* – үкчә, *чәркә/чәлтер* – сыйрак, *йәйәк* – яңак, *гурла* – тамак, *карсак* – тәбәнәк буйлы, *бырамый* – биләмче, *галыш* – ялангач, *мыштым* – тыныч холыклы, *дастуйын* – таза гәүдәле, *тәтәби* – күп сөйләүчән, *бырлыгу* – борчылу, *йерәкләнү* – кызып китү, *йарпайу* – төзәлү, *рәнҗү* – авыру, *чирләү*, *тыну* – ял итү, *серме кыйылу* – сөмсере коелу.

Аш-сулар: *май ашы* – бавырсак, *питырач* – ачы камырдан пешерелгән вак күмәчләр, кечкенә ипи, *кагыт* – как, *ләwәш* – бәлеш, *пажалу* – өшегән бәрәңге күмәче, *эрек* – эремчек.

Хуҗалык, тормыш-көнкүреш сүзләре: *ызба* – өй, йорт, *кухна* – алачык, *йырт* – ишегалды, *мөйөш//мийеш* – почмак, *путалак* – түшәм, *йеслек//бит себергеч* – сөлге, *шаwа* – зур агач табак, аш табагы, *бидрә* – чиләк, *винек* – себерке, *кучарка* – кисәү агачы, *куз* – утлы күмер, *калуса* – тәгәрмәч.

Кием–салым: *пыйма* – киез итек, *түбәкәй* – түбәтәй, хәшәп – чабата кебек үреп ясалган башмак, *дәwәт//чапук* – хәстә.

Үсемлекләр дөньясы: *кузгалдак* – кузгалак, *мышкы* – киндер, *киндераш* – киндер орлыгы, *элән* – җитен, *кучан* – әрекмән, *кырмаwык* – тигәнәк, *паңгы* – гөмбә.

Хайван атамалары: *дуwадак* – бала чыгармаган каз, *кырка* – күркә, *тешекәй* – саулык, *дәwә* – дөя, *йарка* – бер яшьлек сарык, *пырамыш* – төклетура.

Табигать: *бума* – буа, *ырашкы* – бозлы яңгыр, *нәҗүм* – салам белән балчык кушып ясалган измә, *мәте* – үзле балчык.

## Туй йолалары

**Йаучы** – кыз димләүче, егет белән кызның гаиләсе арасында арадашчылык итүче.

*– Йаучы итеп бик тәүфикле кешене җибәрәләр. Нәселе ошамаса бирмиләр ийе элеке. Йаучы ақыллы, оста кеше булса, эшне әйбәт башқара*. (Иске Ярмәк)

**Башкода:**

*– Башкода йөрү булды элек. Ике арада йөреткәннәр башкоданы, озак кына да йөреткәннәр. Эшне башкарып чыкса, аны бик зурлыйлар башкоданы. Тугыган йеслек* (сөлге) *бирәләр башкодага*. (Яңа Мәчәләй)

**Кыз соратырга килү.**

*– Хәзер инде ата-инәсе килә йегет йагыннан. Кызны сораталар, сүләшәләр, килешәләр.*

**Йакшы сүз бирү:**

*– Кызны бирергә риза булсалар, йакшы сүз бирәләр, йаулык бирәләр кийәү йагына.*

**Ақлашу:**

*– Қыз йағыннан йаулық биргәч, инде ақлашқан, дигән сүз чыға. Йаулық бирү – қызны бирергә риза булу, ақлашу була. Никахқа әзерләнә башлыйлар инде ақлашқач та. Никах көне билгеләнә.* (Гали)

**Йаулық бирү, битйаулык бирү:**

*– Қызны сорарға баралар да риза булсалар, йаулық биреп җибәрәләр. Йаулық ул битйаулық инде, чүпләмле. Минем инәкәйнеке бар.*

*– Битйаулықны чүпләү қалағы белән санап суғалар аны. «Ышанмақлыққа» дип бирәләр битйаулықны.*

*– Битйаулық бирәләр йегет йағына. «Без қызыбызны бирергә риза», дип.*

*Битйаулық хәзер дә бирәләр, чиккән битйаулықны. Бик матур була ул. Кийәү буласы кеше битйаулықны машинасына тағып, қуwанып қайтып китә. «Қызны бирәләр», – дип.*

*Элгәре ул суққан битйаулық булған, қызыл башлы, чүпләмле.* (Гали)

**Қолақ сөйенчесе:**

*– Қыз йағыннан йаулық биргәч, йегет йағыннан қолақ сөйенчесе китерәләр. Қолақ сөйенчесенә қызға матур йаулық китерәләр. Йаулық почмағына күпмедер ақча түнәп китерәләр. Бик матур баш йаулығына төйнәп китерәләр «қолақ сөйенчесе» дип.* (Гали)

**Кәләшкә керү** – *ул кыз куйынына керү була инде. Никахтан соң кыз өйендә кийәү кәләшкә керә. Кийәү белән кыз катышалар, аларның қәдерле чаклары була инде. Торуларына көн сайын мунча, мунчадан чыгуга кийәү коймагы булды. Элек тары онынннан кийәү коймагы пешерәләр*. (Яңа Мәчәләй)

**Ишек баwы тоту:**

– *Кийәү кеше кәләше йанына кергәндә ишек баwы тоталар малайлар:*

*Ишек баwы – бер алтын*
*Безнең апай – мең алтын.*
*Тизерәк акча бир, җизнәй,*
*Бүген тышта бик салкын.*

*Сикереп төштем бакчага*
*Бастым бакыр акчага.*
*Без апайны бирмибез*
*Биш тиен бакыр акчага*. (Иске Мәчәләй)

**Туй атлары:**

– *Элгәре атлар белән, гармуннар белән йырлашып урам әйләнәләр иде. Қыз белән кийәү беренче атта, мендәрләр қуйған була ат арбасына.*

**Ат тотучы:**

– *Ат тотучы итеп билгеләп қуйалар туйда. Ул биленә қызыл башлы сөлге бәйли. Күренеп тора инде ат тотучы икәнлеге*. (Кызыл Күпер)

**Килен төшү:**

– *Атлар белән төшә инде килен. Капка төбендә каршы алып торалар. Малайлар капка ачарга тийеш.*

*Wазуклар белән төшерделәр киленне, дугаларга сөлгеләр тагып, каланулар элеп*. (Яңа Мансур)

**Капка ачучы:**

– *Капка ачучы малайлар көтеп торалар туй килгәндә. Капка әле бикле тора. Килен буласы кеше бу малайларга пирчәткә ыргыта. Шуннан соң алар капканы ачып кертәләр туй атларын*. (Яңа Мансур)

**Киленгә баллы май каптыру:**

– *Килен кергәндә баллы май каптыралар «Илаһи, тигез мәхәббәт бир» дийәсең дә касәдән алып каптырасың.*

*Кайнана булачак кеше каптыра. Балкашык белән касәне кулыңа тотасың да:*

*«Илаһым, ике йәшкә тигез,*
*Күркәм мәхәббәт бир инде», – дисең.*
*«Бер-берегезгә бал белән май кебек булыгыз».*
*Шулай каптырасың да кереп китәләр.*
*«Йомшак, татлы телле бул», – дийеп каптыра.*

**Килен кергәндә күпчек салу:**

– *Килен кергәндә күпчек* (мендәр) *куйдым да әйтем:*

*«Килен, үдәге сүземе, нажҗымы*[1]*,*
*Тышка ташыма,*
*Кеше сүзенә, карама,*
*Мине, канананы сүләмә,*
*Мин сине сүләмим, киленем.*
*Килен, мин әтәм,*
*Син мине сүләмә,*
*Мин сине сүләмим,*
*Сиңа китерерләр биш сүз,*
*Син мине сүләсәң,*
*Миңа китерерләр ун сүз.*
*Үдәге нажҗымы тышка ташыма,*
*Тыштагы нажҗымы үгә кертмә», –*

дип әйттем.

*Менә бер киленем тыштагы нажҗымы үгә керткән әле. Wәт шылай әтә идек киленнәргә. Мин үзем шылай әйттем. Бер сүз дә килешмәдек киленем белән.*

*– Килен кергәндә күпчек куйалар бусагага. «Күпчеккә басмыйм», – ди киленем. «Бас, пычыранса үзең йыварсың, киленкәй».* (Яңа Мансур)

**Килен күренеше:**

– *Килен күренеше була. Кан'ана киленгә йаулык бәләтә. Ә килен сөлге тага бит себерергә, кулын себерергә.* (Яңа Мәчәләй)

**Су йулы күрсәтү:**

– *Алып киттеләр мине Кизләү чишмәсенә су йулы күрсәтергә. Чиккән алйапкычымны бәйләдем.*

*Су йулы күрсәткән кешегә минем әрчи кызым кулйаулык бирде.*

---

[1] Нажҗым [< рус. назем] – тирес. Бу очракта кирәкмәгән сүз, гайбәт мәгънәсендә кулланыла.

*Миннән күтәртмәделәр, ике кайын сеңелем күтәрде.*

**Мылтык ату:**

*– Килен су йулыннан кайтып килгәндә кисәк мылтык аталар иде. Ник атканнар? Җеннәрне, шайтаннарны качыру өчен булгандыр инде ул. Хәзер шулай уйлыйм.* (Балыклы)

**Әрчи қызы** – туйда кәләшне озатып, карап йөрүче кызлар.

*– Туйда ике әрчи қызы була. Әрчи қызына йаулық, сөлге бирәләр. Әрчи қызы мунча йаға. Әрчи қыз йағыннан да, малай йағыннан да була.*

*– Әрчиләр табақлар тотып баралар туйға. Ашаулыққа төйнәгән табақ, үзенекен үзе тотып бара, буш бармыйлар туйға.* (Иске Ярмәк)

**Әрчи йегете** – туйда кийәүне озатып йөрүче.

*– Әрчи йегете ақ пирчәткә кийеп йөри, туй бүләге итеп бирәләр әрчи йегетенә ак пирчәткәне.* (Иске Ярмәк)

**Туй күтәрүчеләр, кодагый кертүчеләр:**

*– Туй күтәрүчеләр, дип әйтәләр. Алар туйдағы қодаларны қаршы алалар. Туй күтәрүчеләрнең һәрберсенә бер қода бирәләр, бер пар. Шул бер пар қоданы иртән барып аласың туй күтәрүче булсаң, ашатасың, эчертәсең. Аннан китәләр икенче ашқа.*

*– Биш-алты кеше қодагый кертә дип сүләшәләр иде.* (Иске Ярмәк)

**Туйда бүләкләшү: кыз һәм кияү бүләге. Қыз сандыгы:**

*– Аттағы сандықта қызның бащырсағы була, өйгә эләсе әйберләре була.*

*Сандық өстенә бер үсмер малайны утырталар, сандықны түләп алырға. Ақча биргәч кенә төшә теге малай сандық өстеннән.*

*Қыз бала шулай сандық тутырып килә. Сандығы сандық арбасында килә.*

*Сандықны қызға кийәү йағы бирә. Ул сандықны қыз әйберләрен салалар: Йеслекләрен, намазлықларын.* (Иске Ярмәк)

**Бирнә** – туйда кара-каршы бирелә. Қыз йағы да, кийәү йагы да бирнә бирә. Қыз ақ ойоқбашлар бәйләп қуйа, күлмәк тектерә кийәүгә.

*– Бирнә бирә килен булып төшкәч, җақыннарына. Җаулық, қулҗаулық, наски-пирчәткә, күкрәкләр бирә килен.*

*Сөлге белән намазлык әби белән бабайга була инде.* (Гали)

**Әйбер элү:**

*– Кийәү өйендә кыз әйберләрен эләләр.*

**Түр буйы:**

*– Аны түбә такта (түшәм) йагалый эләләр. Чиккән түр буйлары булды.*

*Чаршау эләләр. Элек бүлмәләр булмаган. Тәрәзә пәрдәләре эләләр тәрәзә башларына. Тәрәзә аралары элеп куялар. Чигеп әзерли идек тәрәзә арасы дигәнен. Чиккән әзерли идек тәрәзә арасы дигәнен. Чигешләрен эләләр иде шулай. Бит йаулыкълар эләләр, өйне бик йәмле итеп бизәп куйалар. Сөлге-салфитлар алып киләләр.*

*Килен әйберләрен туйга хәтле тагып, өйне кийендереп куйалар иде.*

*Килен сөлге элеп куйа бит себерергә. Йеслек – сөлге инде ул. Йеслекне урта ишеккә тагып куйа. Шул йеслек белән мунчага баралар. Ишек башларына, караwат башларына караwат итәгенә челтәрле пәрдә эләләр.* (Иске Мәчәләй)

## Аш-сулар

**Идәндә табын йасау. Идән паласы.**

*– Суккан паласлар була иде, чүбектәнме, йоннанмы, мошко эрләпме. Шул паласны идәнгә җәйеп, шунда утыралар иде.*

**Күпчек** – кечкенә мендәр.

*– Мулла утыра торган турыга күпчек қуйалар иде.*

**Түр йурганы:**

*– Аны сузып салалар утырырга.*

**Табын ашаулыгы:**

*– Ул зур ашаулыкъ була табын ашаулыгы. Қызыл шақмақлы ашаулыкъ. Шунда бөтен ризыкъны тезәләр.*

**Кырук табын:**

*– Идәндә кырук табын җәйәләр. Дүрт-биш кешегә бер аштабақ куйалар иде.* (Яңа Мансур)

**Табынчы** – табын башлыгы; аш бүлүче оста.

*– Идәндәге табында, зур самаwыр йанында табынчы утыра.*

**Аштабақ** – аш сала торган зур табак.

*– Аштабақ белән ашны китереп қуйалар, табынчы салып-салып бирә. Ә элегрәк қашыкълар белән аштабақтан ашаганнар, икеөч урында аштабақ қуйылган.*

**Чәй** – *чәйне табынчы йасап бирә, үзе дә шул арада эчеп ала.*

**Шаwа** – зур агач табак.

*– Шаwа белән итне китерәләр. Кисәкләп туралган итне шаwадан һәркем үзе алып ашый.*

**Кеше үткәрү** – кешеләр чакырып аш мәҗлесе ясау, кунак сыйлау.

*– Кеше үткәрүгә үзем бәлеш салырға җаратам. Қорбан ғайете, мәүлит бәйрәмнәренә кеше үткәрсәң шәб инде ул.* (Гали)

**Туй ашлары. Бәлеш:**

*– Бәлешкә итен турап саласың, йарманы бүрттереп саласың. Арпа йармасы, солы йармасы, бодай, тары йармаларыннан бәлеш салабыз. Әзрәк пешкәч, бәлешнең бөкесен ачып, бер йоморы (чынаяк) шулпа салып җибәрәбез дә тағын пичкә қуйабыз.*

*– Бәлешнең қапқачын ачып, бәлеш бармақларын бәлеш өстенә турап чығарабыз.*

**Бәлеш төбе** – *иң тәмлесе, майда қайнап пешкән була.*

*– «Бәлешнең төбе – муллаға, мунчаның азағы – муллаға», – дигәннәр. Мулланы олылағаннар аwылда.* (Гали)

**Чуйын бәлеше:**

*– Элеке чуйын бәлеше пешерү бар иде. Анарга wак кына иттереп ит, суган, алма (бәрәңге) салалар. Аслы-өсле тутыралар да өстен йабалар, пичкә тыгып куйалар. Ул пичтә, чуйын эчендә кайнап, кызарып пешә, бик тәмле була.* (Яңа Мансур)

**Баwырсақ пешерү:**

*– Баwырсақ пешерергә дә осталық кирәк, рәтен белү кирәк. Безнең Ғәли аwылында баwырсақны менә болай пешерәбез:*

*– Күкәйләрне алдан туңдырабыз да эретәбез. Умбиш күкәйгә булса, бер қашық ғомбағыш майы салабыз, әз генә писук салабыз. Йомшақ қына итеп қамыр басабыз, күтәбез дә кисәбез. Қайнап торған майға салып пешерәбез. Баwырсақны алып қарыйсың. Баwырсақ шиңмәсә, пешкән була. Өстенә қайнаған писук ширбәте сибәбез, зур паткусларға қатырабыз.* (Гали)

**Туй баwырсағы:**

*– Туйға эре баwырсақлар пешерәбез. Йомырқаңы сытасың. Элеке қул белән ийе, хәзер инде миксер белән күпертелә. Шунарга әз генә разрыхлитель, қалақ очы белән генә чәйни суды салып җибәрәсең. Йақшы иләгән ақ онны салып, қамыр басасың да берәр сәғәткә тастымалға этереп* (төреп) *қуйасың. Ул шулай этереп қуйагын җитлегә. Аннары сың инде аны әнәчәләр йасап кисәсең.*

*Гомбагыш майын қайнатабыз. Май эченә салабыз бер йоморы су. Шул сулы майга баwырсақны салабыз, қайнарга қуйабыз. Ул бик матур булып қабарып пешә. Су салмасаң, баwырсақлар йарылып китә, ә су салгачтын баwырсақлар йарылмый. Бик әйбәт кенә булып, қабарып пешәләр.*

*Баwырсақларны сөзеп аласың. Икенче кәстрүлгә қайнарга шикәр қуйасың, өстенә әз генә су салып. Шикәр қайный, тамызып қарыйсың. Җәйелеп китмәсә, шикәр әзер була.*

*Баwырсақларны табаққа салып, табақтагы баwырсақларга шул қайнагап шикәрне қойасың дагын, патнусларга қуйып, қатыра барасың. Ул бик матур килеп чыга. Өсләренә камфитлар сибәсең, қақлар йабасың. Ул инде туй баwырсагы булла.* (Иске Ярмәк)

**Қыз баwырсагы:**

*– Туйга қыз йагыннан баwырсақ пешереп илтәбез. Кийәү йагыннан баwырсаққа он, май китерәләр, қыз йагында пешерәбез.*

*Баwырсақларны зур патнусларга баллап тезәбез, өсләренә йөзем җимешләре, wақ канфитлар сибәбез. Элек таба белән пичтә пешерделәр, ә соңрақ қазанда май эчендә пешерә башладылар баwырсақны.*

**Баwырсақ чыгару:**

*– Олылар табынына баwырсақны чыгарганда қызның әтисе йәки әнисе йагыннан берәр туганы чыгара.*

*Йәшләр табынына баwырсақны күбрәк кийәү йегете чыгара, баwырсақ қырыйына паднус қуйалар. Нәстә салалар инде шул паднусқа йәшләрне қотлап.*

*Баwырсақ чыгару ул «йәшләрне күреп китү, дип әйтелә». Баwырсақ чыгарганда кийәү белән қыз йәнәшә басып торалар.*

**Баwырсаққа қақ қаплап чыгару:**

*– Баwырсақны табынга чыгарганда өстенә йуқа гына йасалган қақ қаплап чыгарабыз. Қақ – төрле җимештән була: алма қагы, қарлыган қагы, җиләк қагы булла.* (Иске Ярмәк)

**Баwырсақ қотлату:**

*– Кийәү йагында баwырсақны қотлаталар. Кем күпме сала. Шулай йегет ызбасында баwырсақ қотлату була.*

*– Кем күтәреп чыга баwырсақны, шул ачып та җибәрә. Башта үзенең бүләген әйтә, аннары гына бүтәннәрдән әйттерәләр. Ике баwырсақны алып қаба да һәркем үзенең бүләген әйтә.*

*– Хәзер баwырсаķны күбрәк аķчалата гына ķотлыйлар туйларда*. (Яңа Мансур)

**Дөге үрәсе:**

*– Сарык итен турап, дөге үрәсе итеп пешергән аш – иң зур сый булған ул, иң дәрәҗәле аш булған, иң затлы аш, ķадерле ризыķ булған*. (Нугай)

**Ләwеш:**

*– Ләwешне йөземнән, ķара җимештән, павидлыдан пешерәләр. Сөткә, күкәйгә генә ķамыр басып пешерәләр.*

**Кыстырган:**

*– Кыстырган салалар туйга. Кыстырган күмәч була, эченә шомырт, йә балан салалар*. (Иске Мәчәләй)

**Ķатлама:**

*– Ķатлама ул баwырсаķ ķамыры кебек ķамырдан пешерелә. Ķамырны җәйәбез, аны кисмиче генә пешерәбез. Зур-зур түгәрәк ķатламалар була.*

**Шырпылы катлама:**

*– Табында үзенә күрә матур була шырпылы катлама.*

*Күкәйгә генә басып җәймә җәйәләр, аны озын тасма кебек, бик тар итмиче генә кисәләр. Уклауга урап, майда пешереп алалар. Таралып китмәскә шырпы кадап куйалар.*

*Туйларга шулай шырпылы катлама пешереп ķуйалар матур итеп.*

**Урамыш:**

*– Урамышны күкәйнең агына гына басып җәйәләр дә, тасма кебек кисеп ыклауга урап пешерәләр, наным*. (Яңа Мәчәләй)

**Аķ җәймә:**

*– Аķ җәймә пешерәләр иде туйларға. Күкәйгә генә ķамыр басалар да, шуны җәйеп, табаға май салып пешереп алалар. Тиз пешә, ķабара. Пич ķызғач ķына пешерәләр. Шулай аķ җәймә, шаķмаķлы шикәр булды.*

**Йока:**

*– Туйларга да, хатемнәр укытырга да йокалар пешрә идек. Зур-зур йокалар, кукайдан гына камыр басып җәйәбез иде. Пичтә кабарып кына пешә ул йока. Йока ул мәзелеснең күркәме иде. Эвеп-эвеп куйалар иде дә сындырып-сындырып ашылар иде*. (Балыклы)

**Табақ белән килү, табақ җыйу:**

*– Туй қодалары табақлар белән киләләр. Табақларға туй ашларын салара: йақшы камфитлар, җимешләр күмәчләр була табақта. Тары оныннан төче күмәчләр була.*

*Қодалар туйға килгәндә табақ җыйалар, табақ тутырып, табақ белән күчтәнәч алып киләләр. Пар қаз: «Парлы торсоннар».*

**Ашлар белән килү:**

*Туйға ике йақтан да ашлар белән киләләр. Ике күмәч, ике пирук, ике ләwәш салып киләләр ике йактан да.*

*Ике қаз, пар үрдәк тә китерәләр. Табынчы кисеп-кисеп халыққа ашата.* (Иске Ярмәк)

**Никах суwы:**

*– Никах уқыганда табынға су қуйалар иде. Шул суны барысы да қабалар иде никахта.*

*«Никах суwына күктән бер тамчы тамар, никах догасы сеңәр шул суға», – диләр иде. Менә шулай иде безнең заманда.* (Иске Мәчәләй)

**Төрле ашлар. Питрач, хәйер питрачы:**

*– Әпәй салганда хәйер питрачы да салабыз. Ул бәла-казалардан саклый, ди, хәйер питрачы. Җәтим әбиләргә бирә идек. Әбизәтелни сала идек хәйер питрачын икешәрне. Пич куwынында гына пешә иде ул хәйер питрачлары. Хәзер менә аларны белмиләр дә инде.*

**Хәйер питрачына ризык догасы уку:**

*– Питрачны йылы күгә, канар күгә хәйергә бирәбез иде. Инәй әтә иде: «Бар, кызым, Асыл әбигә йогорт питрачны». Салфиткә төреп бирә. Асыл әби ризык догасы уки иде:*

*«Ходай ризык бирсен,*
*Килер җире киң булсын,*
*Исәнлек-саулык,*
*Хәйерле дәүләт бирсен».* (Яңа Мансур)

**Бөкөри:**

*– Бөкөрине сезнең Қазан йағында бөккән дип әйтәләр.*

*– Мунча йаққан көнне дә мунча пичендә таба белән бөкөри пешереп алырлар ыйы. Утын қадерле булған инде.*

*– Бөкөри төрле нәстәдән буладырыйы.* Қузғалақ бөкөрийе – *кузғалақ өлгергәч,* қычытқан бөкөриләре – *йәш қычытқаннан,* җиләк бөкөриләре – *төрле җиләктән,* орлоқ бөкөриләре – *киндер орлоғыннан.* Ит тураған бөкөри, эчәге бөкөрийе *пешердек. Бәрәңге*

*белән суған, ит тураған бөкөри була. Кем мал суйа, эчәге турап бөкөри саладырыйы.*

Қарлыған бөкөрийе, шикәр чөгендере бөкөрийе *пешердек.*

*– Қарлыған шәп буладырыйы урманда. Қарлыґанны табаққа салып төйәбез дә түгәрәкләп-түгәрәкләп қуйып кипетерәбез тақтаға төзеп.*

*Менә қыш көне чөгендерне, шикәр чөгендерен қырғычтан үткәреп, шушы қарлыганны да қушып, бөкөри салып ашыйдырыйық. Бик тәмле буладырыйы. Алар менә хәзер йуқ бит.* (Нугай)

**Кара бит:**

*– Киндерашны сугып, орлогын тевәләр дә кабартма өстенә йагалар.*

*– «Кара бит пешердем», – диләр, чәй эчәргә күршеләрен дә чакыралар. Кап-кара була, үзе бик тәмле була иде кара бит. Хазер менә күрергә дә йуктыр ул кара битләр.*

*– Мошконы (кидернең орлыгын) түwәләр дә кабартма өстенә җәйеп пешерәләр, шуны кара бит дип әтәләр.* (Яңа Мансур)

**Әпәй пешерү:**

*– Кичтән әпәй изәбез.*

*– Әпәй башы камыры калдыру була иде. Шул әпәй башы камырын җылы су белән изеп куйабыз да иртән куwашнада тоз, он салып басабыз, кабартабыз.*

*– Колмак суwы белән дә чүперә йасый идек.*

*– Колмакны пешерәләр суга салып, ул пешә. Суwына он изеп куйалар. Ул эчегәч, тагын он салып, бер йоморы чүперә салып кабарталар, әпәйне басалар, басқач тагын кабарталар.*

*– Арыш әпәйе ул артык әчемәсен. Артык әчесә, әпәй йарыла торган була.*

*– Күпчекләр өстенә җәймә җәйеп, әпәйләрне әwәләп куйабыз. Ул күпчек өстендә түгәрәк кенә, матур гына булып кабара. Әгәр артыграк әчегән булса, ипи көрәгенә куйгач йарылып китә, сәленеп төшә.*

*– Арыш әпәйе өстенә катык сөртәбез, кашык белән ай бизәге йасыйбыз. Кызарып, кабарып пешә әпәйләр.*

*– Бер сагат та ун минутта пешә әпәй. Чиклаwык төше кебек була иде арыш әпәйләрем!* (Яңа Мансур)

**Куйан ипийе** – кырга алып барып, кире өйгә алып кайтылган ипи; кыр күчтәнәче була инде. Бездә аны куйан ипийе дип әтәләр иде.

*– Ындырда арыш, бодай, тары чәчә идек. Умачка, токмачка җитәрлек он була иде.*

*Бодайны чыпчыклар эчә иде. Чыпчык эчә – чыпчык аши инде. Әби урындыгына утырып, шыгырдаwын шыгырдатып чыпчыклар куwа иде.*

*– «Бодайны эчеп бетерәләр чыпчыклар», – дийә иде. Анда ул әзерәк ипи алып менә иде. Кат'а игә дә, әтә: «Менә, сезгә куйан ипи җибәрде, күчтәнәч җибәрде».*

*– «И, әби, да»ай, бир әле, ашыйык әлеw.* (Иске Мәчәләй)

*– Ышана идек шунарга. Куйанның күрәсең пиче дә бар, оны да бар.*

*– «Әби, зурмы куйан?»*

*– «Зур куйан китерде ипине. Урманда аларның пичләре дә, оннары да бар, бөтен нәстәләре дә бар. Менә куйан ипийен ашагыз, сезгә дип җибәрде».*

*– Куйан әтте: «Әбиләрен тыңнасыннар, ату бүтән бирмим ипине», – диде.* (Яңа Мансур)

**Куйан ипийе белән кишер чәйе эчү:**

*– Әби алып кат'кан куйан ипийен кишер чәйе белән эчә идек. Кишерне күп чәчә идек. Шул кишерне тапап, пичтә киптерәләр иде, чәй итеп эчәр өчен. Қып-қызыл чәй чыға иде. Тапаған кишер чәйе ул чөче, тәмле чәй була иде. Шул куйан ипийе белән кишер чәйен рәхәтләнеп эчәбез ийе без балалар.*

*Әбигә рәхмәт, безне, балаларны шулай сүwендергән өчен!* (Яңа Мансур)

**Қабақ канфиты:**

*– Әнкәй қабақны қазанда пешерә дә төйә. Шуңа, он булса, он қуша, қуйыртып қына пешерә дә түгәрәкләп қуйып киптерә. Пич өстендә қуйып киптерә шуларны. Wәт сиңа қабақ камфиты! Без шуларны чәй белән ашап қуйа идек. Шуңа күрә без таза булғамбыз да.* (Яңа Ярмәк)

**Шомыртлы май:**

*– Безнең урманнарда шомырт күп үсә. Элек күп итеп җыйа идек тә киптереп тә қуйа идек. Кипкән шомыртны киледә төйеп, иләп, шомырт оны йасый идек.*

*– Шомыртны йаңа җыйған килеш тә ит тартқычтан чығарабыз.*

*– Үзебез йазған йаңа май, аның йанына шомырт құйабыз бер тәлинкәгә.*

*– Құнақ ашы, тансық аш була ул шомыртлы май.* (Яңа Мәчәләй)

**Киндер орлығы майы:**

*– Киндер орлығын күп чәчәләр ийе элек. Орлығыннан май чығаралар ыйы, бик тәмле май буладырыйы ул. Майы күп чығадырыйы. Бөтен нәстәкәйгә дә җарый ул орлоқ майы.* (Гали)

**Үлән чәйләре, йафрак чәйләре:**

*– Мәтерүшкәдән, сары мәтерүшкәдән, бөтнектән, кишер сабагыннан, алма, чийә карлыган йафракларыннан чәй йасап эчәбез.*

*– Иң тәмлесе –* карлыган йафрагы *чәйе, минем үземә шулай тойыла. Аны җыйабыз да күп кенә итеп, суга салып тиз генә кайнатып алабыз. Сөзеп алабыз да җәйеп киптерәбез. Кап-кара, хуш исле чәй булып чыга ул. Шулай үзебезнең үләннәрдән чәй йасап эчәбез әле дә. Менә кура җиләге йафырагыннан йасаган чәйне эчеп утырабыз сезнең белән.* (Иске Ярмәк)

**Әче бал:**

*– Шикәр чөгендерен тапап салып, чүперә салып, шикәр чөгендере әчетү булды. Шуннан әче бал булды. Шуны туйларға құйарлар ыйы. Қатын-қызға әче бал бирәләр чәйгүнгә салып. Ирләр идәндә, қатын-қызлар сәкедә утырадырыйы.*

*Шулай чөгендердән йасаған әче бал белән туйлар уздырдық. Идәнгә тезелеп утырып, йоморыларга* (чынаякларга) *салып, әче бал эчәләр әз-әз генә салып. Күп йарамый ул, башқа китә, җырлата.*

*Эчик әле балларны,*
*Бал бетерми малларны.*
*Атадин бала йәш қала,*
*Шул бетерә малларны.*

*Дуслар да күп, дуслар да күп*
*Тағы да дуслар булсайде.*
*Йақын күргән, сез дусларым,*
*Айрылмасқа булсайде.*

*Аллар булғанда ғына,*
*Гөлләр булғанда ғына.*
*Күңелләр бит күтәрелә*
*Бергә булғанда ғына.*

*Әче балға чүперә суwын, қолмақ чүперәсе суwын салалар. Бик тәмле итеп әчи ул бал.*

*Бәйрәмнәрдә ашқа дәшешәдерийек бер-беребезне әче бал қуйып.*

*Йырлиғ әле, йырлиғ әле*
*Йырлиғ әле икене.*
*Йырламас идем икене*
*Кодаларым сөйкемле.* (Яңа Ярмәк)

**Өшегән бәрәңгедән пешерелгән ашамлыклар. Бүлмедән күмәч пешерү:**

*– Бүлме дип бәрәңгене әйтәбез.*

*– Менә элек аwыр йыллар булды. Йаз көне ашарға бетә. Бақчаларны қазыганда көздән қалган бүлемәләрне, өшегән бәрәңгеләрне эзләп табып, күмәч итеп пешереп ашадық. Қырға чығып, аннан да ақтарып табабыз бүлмене. Өйгә китереп торабыз, апай чистарта, инәй пешерә тора.*

*Бүлме күмәче белән чәй эчәргә бөтен күршеләр керә торған ыйы.* (Иске Ярмәк)

**Пажалу** – көздән калган, өшегән бәрәңгедән пешергән күмәч.

*– Җирдән казып алабыз көздән күмелеп қалған бүлмеләрне. Тапсақ бик қуwанабыз. Аны қабығын ғына салдырабыз да, тоз салып, булса, әз генә он салып, басабыз да қалайға тезеп пешерәбез түгрәкләп. Шуны пажалу дип әйтәбез ийе. И, тәмле дә инде, төче күмәч инде ул өшегән бүлмедән.*

*– Пажалу пешергәндә, булса әз генә ғомбағыш майы, тоз, сузы салып басабыз. Табаға тезеп, wақ-wақ итеп пешерәбез, кетер-кетер итеп кенә тора.* (Иске Ярмәк)

**Җир-су. Йүкәле тау –** *изгеләр тавы.*

*– Йүкәле тауда элек изгеләр қаберләре булған. Хәзер дә хөрмәтлиләр ул тауны. Йүкәле тауның урта бер җирендә, су буйында ақ қайын үсә. Ул ақ қайын инде қартайған, анда сuғышта үлгән кешеләрнең исемнәрен йазып элгәннәр. Хәзер ул қарт қайын йанына йәш қайын утыртқаннар.*

*Хәзер дә балалар белән бергәләп үзебез дә җырлыйбыз ул җырларны.*

*Йафрақлары йәшел ақ қайынның,*
*Хәтфә җәйгән кебек йақ-йағы.*
*Әйлән-бәйлән уйный йәш балалар,*
*Гөрләп тора тауның һәр йагы.*

*Йәш балалар, бигрәк матур қызлар*
*Ақ қайынны сөйеп мақтыйлар.*
*Йаз башында алар һәр йыл сайын*
*Ақ қайында бәйрәм йасыйлар.*

*Ап-ақ қайын, инде бик қарт қайын,*
*Бизәлә ул йазлар килгәндә.*
*Йәшел йафрак йара һәр йыл сайын*
*Қыйаш җылы нурлар сипкәндә.* (Иске Ярмәк)

*Йүкәле тау – изгеләр тавы. Анда менеп йаңғыр телиләр. Бурасы да бар тау өстендә. Изгеләрнең бурасы. Шунда қорбан чалалар.*

*– Йүкәле тауға изге күңел белән генә менәргә кирәк. Анда начар эш эшләргә йарамый. Сабан туйлары да элек Йүкәле тауда булған. Анда сабан туйы булған көнне қойып йаңғыр йаwа торған ыйы.*

*– Йүкәле тауның итәгендә бик матур ақ қайын бар ыйы. Мәктәптә уқығанда соңғы ызванук көннәрендә уқытучылар шул тауға алып менәләр ийе. Шунда инде «Ақ қайын» җырларын җырлый идек. Андағы ақ қайын бик зур, бик йуwан ыйы. «Йүкәле тау ақ қайыны» дип атақлы қайын ыйы. Хәзер инде ул қарт ақ қайын йанында йәш ақ қайын үсеп утыра.*

*– Йүкәле тауға йәшләр дә менәләр, олылар да менәләр. Анда теләгән теләкләр қабул була, дигәннәр. Теләк урыны ул әле дә.*

*Дога уқығанда да:*

*Үзебезнең Йүкәле тауда йатучы*

*Изгеләр рухына, – дип бағышлыйм мин.* (Яңа Ярмәк)

**Морат бабқай чишмәсе:**

*– Морат бабқай дигән изге баба булған. Ул бабқайның қабере дә бар зиратта, шул зиратқа қаршы ғына шишмә бар, «Морат бабқай шишмәсе» дип атағаннар, исеме онытылмаған. Шул шишмәнең суwын «зәм-зәм суwына тиң» дигәннәр.*

*Шул «Морат бабқай шишмәсеннән» бөтен кеше су ала, йырақлардан да киләләр. Безнең аwылда шул изге баба булғанга бер бер зыйан да, бер афәт тә булғаны йуқ.*

*Қоръән уқығанда да «Морат бабқай рухына» дип бағышлыйбыз.*

*Йаңғыр йаумый торса да шунда барып намазлар уқыйбыз, йаңғыр намазы уқыйбыз.* (Гали)

## МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

**Камышлы районы**
*Балыклы:*
Баһаветдинова Сара (1916 елгы)
Билалова Хәтимә (1942 елгы)
Габделшина Фәһимә (1924 елгы)
Хәлимова Рәйсә (1941 елгы)
*Иске Ярмәк:*
Галиәхмәтова Флюра Шәйхетдин кызы (1937 елгы)
Мәсләхова Роза Мансур кызы
Рәхимова Мәрзия (1919 елгы)
Сафина Раилә (1969 елгы)
Хөсәенова Хәлфия Шәфигулла кызы (68 яшьтә)
Шәйдуллина Заһидә Гыйльметдин кызы (1928 елгы)
*Камышлы (район үзәге)*
Юнысова Рагбәрия Минетдин кызы (1934 елгы)
Минһаҗова Шәмсебәдәр Миннәхмәт кызы (1927 елгы)
Нуретдинова Фәйрүзә Нурмөхәммәт кызы (1929 елгы)
Сәлахова Кәримә Сәгыйдулла кызы (1928 елгы)
Шәйхетдинова Нәкыя Әхмәтша кызы (1940 елгы)
*Яңа Ярмәк:*
Гарифуллина Миннегаян Сәгыйть кызы (1933 елгы)
Гафурова Рузалия (1959 елгы)
Дәүләтшина Гыйльменур Нәгыйм кызы (1938 елгы)
Хамматова Алисә (1982 елгы)

**Келәүле районы**
*Урдалы (Назаровка):*
Афанасьева Матрена (Мәтрүнә түти) (1937 елгы)
Афанасьева Надежда Михайловна (1943 елгы)
Веселова Ульяна Ильинична (1959 елгы)
Данилова Анастасия (1939 елгы)
Егоров Владимир Павлович (гл. поселения)
Иванова Ульяна Степановна (Үлүнә түти) (1940 елгы)
Клевашова Аксинья
Климанова Аксинья Ивановна (Үкчи түти) (1930 елгы)
Климанова Галина (1959 елгы)

**Похвистнево районы**
*Гали:*
Асылгәрәева Әмирә (1931 елгы)
Әхмәдиева Асия Хәмидулла кызы (1958 елгы)
Зарипова Фәһимә Әхмәтшәриф кызы (1957 елгы)
Кәримова Мәдинә (1930 елгы)

Моратова Зөбәйдә (1939 елгы)
Моратханова Наилә Закир кызы (1936 елгы)
Сәгъдиева Халисә Исламгәрәй кызы (1935 елгы)
Сәйфетдинова Рәшидә (1928 елгы)
*Иске Мәчәләй:*
Әмирова Рәйсә Зиннәтулла кызы (1940 елгы)
Булатова Гамбәр (1933 елгы)
Булатова Тәнзилә Әхмәдулла кызы (1940 елгы)
Булатова Шәмшехәят (1930 елгы)
Исмәгыйлова Асия Ильяс кызы (1952 елгы)
Рәхмәтуллина Нәгыймә Сәүбән кызы (1938 елгы)
Рәхмәтуллина Фатыйма (1934 елгы)
Субеева Ракибә (1928 елгы)
Таишева Асия Мирзалим кызы (1963 елгы)
*Кызыл Күпер:*
Вакказов Газинур Мөхәммәт улы (1937 елгы)
Вакказова Хәтимә (1941 елгы)
*Нугай:*
Алтынбаев Гаптелкави Гаптелхак улы (1940 елгы)
Алтынбаева Хәния Галәүтдин кызы (1940 елгы)
Әсәдуллина Асия Мөхәммәдзакир кызы (1949 елгы)
Хәсәншина Халисә Нәбиулла кызы (1946 елгы)
Хисмәтуллина Нәркәс (1952 елгы)
*Яңа Мансур:*
Миназиева Гыйльменур (1922 елгы)
Нурсафина Хәлимә (1930 елгы)
Сафиуллина Гыйльменур (1930 елгы)
Сафиуллина Мәүҗидә Сирай кызы (1951 елгы)
Субеева Әкълимә (1952 елгы)
Хәкимова Әнисә Зәкуан кызы (1927 елгы)
Шиһапова Тәнзилә (1920 елгы)
Якупова Сәлимә (1920 елгы)
*Яңа Мәчәләй:*
Әмирова Асия Әхмәтгали кызы (1956 елгы)
Дәүликамова Вәлимә (1938 елгы)
Субеева Нәбирә (1930 елгы)
Субеева Рәсмия (1937 елгы)
Хәмидуллина Гүзәл
Хөснетдинова Мөстәкыймә (1930 елгы)

## САМАРА ТАТАРЛАРЫНДА ЗАМАН ФОЛЬКЛОРЫ

*Лилия Мөхәммәтҗанова*

Татарлар – һәркайда. Җирдә милләттәшләребез аяк басмаган урын юктыр ул. Тарихчы галим Дамир әфәнде Исхаков әйткәнчә, татарлар кебек сибелеп яшәгән башка халыкны Россиядә табып та булмый. Халкыбызның бай тарихын, мәдәниятен төрле төбәкләрдә гомер итүче милләттәшләребез күп гасырлар буена барысы бергә бар иткән. Шуңа да рухи байлыгыбыз татарны татар итеп саклый торган бергәлектә, бөтенлектә генә бар тулылыгы белән ачыла.

Шушы максатларны тормышка ашыру уе 2014 елның җәендә Институтыбыздан бер төркем галимне Самара өлкәсенә китерде. Самарага юл тотуыбызның хикмәте шунда: бу өлкә – Россиянең «Кая барсаң, шунда – татар» дигән гыйбарәне чын-чынлап аклый торган урыннарыннан берсе. Биредә, Татарстанның татар авылларындагы кебек үк, рәхәтләнеп татарча аралашып була торган, татарча сөйли, татарча уйлый, татарча эш-гамәл кыла, тормыш алып бара торган милләттәшләребез яшәве мәгълүм. Россия куенындагы Самара өлкәсендә милләттәшләребез берничә гасырлардан бирле компактлы рәвештә гомер кичерәләр, зур-зур авыллар корып, менә дигән итеп яшәп яталар.

Үз милләтебез берничә гасыр элек үк тамыр җибәргән төбәк буларак, Самара татарлары галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Әле алтмышынчы елларда ук бу якларга И. Надиров, Х. Мәхмүтов, Ф. Урманчеев, Ф. Әхмәтова, Х. Гатина кебек фольклорчы галимнәр экспедицияләргә чыгып, фактик материаллар туплап алып кайтканнар, аларны академик басмалар төзегәндә кулланганнар, Самара татарларыннан җыелган рухи энҗеләрне милли мирасыбыз

буларак бәяләгәннәр. Ярты гасырга якын вакыт аралыгыннан соң бу төбәкнең фольклорында, телендә-сөйләмендә, халык музыка сәнгатенең яшәешендә, археографик, ташъязма һәм этнографик мирас сакланышында нинди яңалыклар, үсеш-үзгәрешләр, табышлар һәм югалтулар бар соң? Экпедиция әгъзаларының һәркайсы шушы сорауларның үз эшчәнлегенә бәйлесенә җавап эзләде.

Самараның Похвистнево, Келәүле һәм Камышлы районы татар авылларына Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы экспедициядә без барлыгы 8 кеше идек.

Фольклорчы буларак, мин үзем төп игътибарымны, әлбәттә, халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлттем. Халык белән әңгәмә корулар нәтиҗәсендә авыз иҗатына хас кайбер үрнәкләр язып алынды, шушы төбәккә генә хас булган тарихи һәм мифологик риваятьләр, авыл тарихлары, уеннар, җырлар, йола фольклоры, төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән яисә халык китаптан укып сөйләгән хикәятләр, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр архивыбызны баетты. Ачык йөзле, сүзгә оста информантлары, куллары шифалау үзлегенә ия халык табиблары (әйтик, Яңа Мәчәләйдән Асия апа Әмирова), оста гармунчылары, гармун ясаучылары, тәмле сулары, татлы бавырсаклары, исламны хөрмәт итеп яши белә торган халкы белән күңелгә керде бу төбәк.

Һәр мәсьәләгә үз карашы булган тырыш, гаярь, җор телле, зиһенле Самара татарлары асылда милләтебезнең тулылыгын, бөтенлеген тәэмин итеп торучы шактый эре катлам. Биредә очраган һәм язып алынган фольклор әсәрләре исә – татар халык иҗатының бүгенге торышы, халкыбыз яшәешенә, аның бүгенге сулышына тере мисал.

Үзеңнеке һәрвакыт үз була. «Без – татарлар!», – дип горурланып әйтерлек милләттәшең булу һәр кешедә канәгатьлек хисләре тудыра. Самара татарлары белән аралашу, авыллары тарихы, күренекле шәхесләренең эш-гамәлләре, гореф-гадәт, йолалары турында үз авызларыннан ишетү, күңел сандыкларын ачтырып, анда сакланган хәзинәләр белән танышу шушы хиснең кабат яңаруына һәм тагын да ныгуына сәбәп булды. Түбәндә Самара якларыннан язып алып кайткан кайбер фольклор материаллары тәкъдим ителә.

**Гали авылына кем нигез салган?**
**(*тарихи риваять*)**

Гали авылының 400 еллыгын билгеләделәр күптән түгел. Чынлыкта безнең авылга 300 ел тирәсе. Документлар буенча шулай.

Бу якларга өч кеше килә. Берсе урыс – Владимир Подольский, икенчесе чуваш – Эрзи Рысаев, ә өченчесе татар Котлыгыш булган. Котлыгышның кайсы яктан монда күчеп килүе турында төрлечә сөйлиләр. Минемчә, ул монда хәзерге Татарстандагы Буа районыннан бер татар авылыннан килгән булырга тиеш. Арча, Балык бистәсе якларыннан килгән, диючеләр дә бар. Буа районыннан килгән, диләр инде күбрәк.

Боларга мең ярымышар гектар җир тигән. Котлыгыш монда өч улы белән килгән. Уллары Галигә – 27, Солтанга – 19, Якупка 16 яшь була бирегә килгәндә. Солтанны патша хезмәтенә армиягә алалар. Якуп Оренбург далаларына чыгып китә. Ә Гали монда кала. Котлыгыш үзе Похвистневоның бер өлешендә ике тау арасында бер авыл төзеп урнаша. Ул авылның исеме дә Котлыгыш исеме белән аталган. Әткәй әйтә торган ые Сукайга (авыл исеме) кунакка барганда: «Әнә Котлыгыш бабкайның җирләре», – дип. Шәп урыннар. Бер 60–70 еллар элек бетте Котлыгыш авылы.

Котлыгышның уртанчы улы патшага 20 ел хезмәт итеп кайта. Бик яхшы хезмәт иткән өчен алдан кайтаралар Солтанны. Тауга менеп басып, кулын сузып күрсәтә алган кадәр җир алырга рөхсәт итеп кайтара моны патша. Солтан шулай итә. Аңа 2 мең га җир тия. Менә шушы җирдә ул авыл төзи. Солтангол дигән авыл хәзер дә бар. Ул авылга Котлыгышның уртанчы улы Солтан нигез салган булып чыга.

Котлыгышның кече улы Якуп, 40 ел узгач, Оренбург якларыннан кабат монда әйләнеп кайта. Шушы Галидә төпләнә, монда аларның нәселләре бар.

Ә Котлыгышның олы улы Гали шушы Гали авылына нигез сала. Авыл аның исеме белән атала. Атасы-бабасының, үзенең дә туган җиренә кире кайтып китеп, монда кабат җиде гаиләне – туганнарын, якыннарын алып килә. Менә шулар хәзерге зират янында подвал казып, җир астында яши башлаганнар әүвәл. Ул тирәләр күл, сазлык булган. Нутри, андатра, баберлар булган. Килеп урнашып, галиләр башта шуларны тотып, сатып көн иткәннәр.

Тау өсте – коры. Саураш (рус. Савруш) елгасын чыгуга ике сәгать аерма, Оренбург өлкәсе башлана. Галиләр шундагы алпавытларга бодай үстерергә ялланалар. Шуннан үз җирләрендә – Красный мост (поселок) ягына барып (анда корырак), бодай игә башлыйлар. Унар капчыкны, бер йөк итеп, Самарада беренче ачылган хлебзаводка илә торган булганнар. 1670–1680 еллар була бу. Сарык үрчетәләр, йонын саталар. Кемдер тимерче булып китә. Бабер, нутри тиресе саталар, пешереп икмәк саталар. Шулай ныгып китәләр, байыйлар.

Ә Галигә 400 ел дигәне Маняк белән Маняж исемле чувашларга барып тоташа. Старое Ганькинога (Камышлының бу ягы) ике чуваш килә 400 еллар элек. Котлыгыш, Галиләргә кадәр йөз ел элек киләләр болар. Гали авылына йөз ел дигәне әнә шуннан. Ул чувашлар монда килеп мөселманга әйләнгәннәр. Галидә аларның буыны бар. Сез мөселманмы, чувашмы, дигәч, чуваш хатыны әйтә: «Писмилля айтям, аллах турах», – ди. Менә шундый мөселманнар.

Шуннан кушылып үскән инде Гали авылы. Гали исеменә бәйләп караганда, авылга шул өч йөз еллар элек нигез салынган булып чыга. Без – Гали бабкайның сигезенче буыны. Бу авылда һәркем үзен Гали оныгы, аның дәвамчысы дип саный.

*Гали авылында Әхмәдиева (Йосыпова)*
*Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы)*
*язып алынды*

**Борынгы курган**
**(*тарихи риваять*)**

Гали авылы янында биеклеге 70 метрлы курган бар. Аны, Чыңгыз хан явыннан калган курган, диләр. Моннан Чыңгыз хан үзенең гаскәре белән узган. Идел ягыннан килгән бер ише, бер ише – Оренбург ягыннан. Шушы тирәдә Чыңгызның бер атаклы генералы үлеп калган. Аны шунда күмеп, биек курган ясаганнар. Ул курган Гали авылы белән Ырсай авылы чигендә.

*Гали авылында Әхмәдиев Рәфхат*
*Алтынхуҗа улыннан (1957 елгы)*
*язып алынды*

**Морат бабкай чишмәсе**
**(*тарихи риваять*)**

Безнең әбкәй Морат бабкайның нәсел-тумасына кияүгә чыккан. Шулай булгач, без Морат бабкай нәселеннән булабыз. Морат бабкай Гали авылында моннан 210 еллар элек яшәгән. Ул мулла булган, соңынан – авыл старостасы. Аны, каты куллы, кырыс кеше булганга, янсыз (җансыз, кансыз) дигәннәр. Халыкны тәртипкә күндереп, авылны тотып торган.

Патша хөкүмәтеннән арбалы ат белән 18 солдат килә, авылны чукындырырга дип. Тау өсләп киләләр 18 обоз (18 ат йөге) тәреләр төяп. Киләләр болар, хәзерге турбаза янында авылның ике йөзләп ир-аты каршы ала боларны саф-саф булып тезелеп. Кайберәүләр куркып та кала чукындыручылардан. Авылның Дәмин исемле кешесе бабкайга: «Әллә болар киткәнче генә булса да чукынган булып кыланыйк микән?» – ди икән. Морат бабкай әйткән:

– Беркем дә чукынмый! Ничек йөрдек моңа кадәр мөселман булып, шулай калабыз.

Патша солдатлары һавага атарга тотыналар. Сугыш китә. 18 солдатның 11ен үтереп, тау тишегенә күмеп куялар, алып килгән йөкләрен калдырып, калган 7 се кайтып китә. «Барыгыз, кайтып сөйләгез», –дип озаталар аларын. (Алардан калган тәреләрне күрше чуваш авылларына барып, сатып йөрүчеләр дә булган әле.)

Шушы хәлдән соң бу эшне оештырган Морат бабкайны җәзалыйлар. Бабкайның ике күзен чокып чыгаралар да үзен таллыкка ыргыталар. Бабкай өч көн дога кылып, Аллаһыга ялварып шунда ята.

– Әй Аллам, Без бит дин өчен сугыштык. Су бир. Бу урында чишмә тибеп чыкса иде! Үтүчеләр шунда үзләрен чистартып китә алса иде. Бу җирләр ризыклы булсын.

Бабкай әнә шулай теләп ята, өч көннән үлә. Аны шунда җирлиләр. Ул үлгәч, бу урында чишмә бәреп чыга. Чишмә Морат бабкай кабере янында, шуңа күрә бу чишмәне халык, Морат бабкай чишмәсе, дип йөртә башлый. Сазлыкка әйләнеп бетте, дип, чишмәне таш бастырып каплап куйганнар иде Совет заманында. Ташны бәреп ургылып кабат чыкты чишмә. Морат бабкайны халык бик зурлый. Чишмәне авыл байлары карап тора.

**Камбай Фатыйма**

(*кушаматларга бәйле риваять*)

Безнең Гали – зур авыл. Һәркемнең кушаматы бар. Безнеке – Камбай. Аны инәкәемә кушканнар. Безне дә шушы кушамат белән йөртәләр.

1936 ел. Бер көтү кызлар кырга эшкә чыгалар. Лобогрейкалы (ургыч машина) камбайлар (комбайннар) чыккан вакыт бу. Урып бара торган трактор инде. Кызлар аның артыннан көлтә бәйләп бара торган булганнар. Инәкәйнең яшь килен чагы, ул да кырда. Кайнана бик усал, кырдан бер уч бодай булса да алып кайтырга куша торган булган. Ә аны эшләү бик авыр. Инәкәй алып кайтыр өчен бодай яшереп куярга җайлы вакыт чыкканны көтеп йөри икән. Кызлар ял иткән арада алар янына бармыйча, һаман эшли икән, бер уңайдан носки эчләренә, кесәләренә кызу-кызу бодай да тутырган.

Шунда кызлар янына Бояр Мингазиз (колхоз рәисе, фамилиясе – Латыпов) килеп чыга. Чыркылдашып көлешеп ял итеп ята торган кызларны эшкә өндәп, әйтә бу:

– Әнә, Фатыймадан үрнәк алыр идегез. Камбай урынына эшли бит берүзе, – ди икән. Шуннан Камбай сүзе инәкәемә кушамат булып тагылган.

**Тибрә Хәлилулласы**

(*кушаматларга бәйле риваять*)

Инәкәемнең иркәсе (энекәш) Тибрә кушаматлы, Тибрә Хәлилулласы дип йөртәләр. Үскәндә Галидә атаклы тимерчеләр Йосыповларга килеп йөри икән бу, шулай тимер эшенә өйрәнә дә үзе дә бидрә (чиләк), кәчтрүлләр ямый, лобогрейкалар ясый башлый. Бөтен кешегә шулай тимер эше эшләп бирә икән. Чувашлар да килә икән моңа күрше-тирә авыллардан.

– Кая барасың? – дигән сорауга каршы чуваш хатыны:

– Тибре паять иттерергә, – дип җавап бирә икән. «Бидрә» урынына «тибрә» дигән. Шуннан Тибрә Хәлилулласы булып калган инәкәемнең иркәсе.

*Гали авылында Әхмәдиева (Йосыпова)*
*Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы)*
*язып алынды*

**Сабырлык догасы**

*(мөнәҗәт)*

Сабырлык – эшләрнең башы,
Сабырлык – бер Хода эше.
Сабырлык ул – иман нуры,
Сабырлык бирсәнә, Аллаһ!

Илаһым, хәсрәтем авыр,
Ничек итим икән сабыр?
Сабырлык ул – иман нуры,
Сабырлык бирсәнә, Аллаһ!

Ходаем, хәсрәтем бетсен,
Йөрәктин кайгылар китсен,
Яна бәгъңрем уты, сүнсен,
Сабырлык бирсәнә, Аллаһ!

**Әлвидаг**

**(***мөнәҗәт***)**

Лә илаһы илләллаһы,
Карамагыз әзенә.
Лә илаһы илләллаһы –
Мәңге бетмәс хәзинә.

Лә илаһы илләллаһны
Таулар-ташлар басалмас,
Лә илаһы илләллаһу
Лә илаһы илләллаһ.

**Кыз урлау йоласы**

Галидә кыз урлау бар. Әле дә урлыйлар. Минем үземне дә урладылар. Мине күргән дә: «Бу минеке!» – дигән. Алдан план корганнар. Вечерда идем Саимәләрдә, әле 17 ем тулмаган чак. Күтәреп алып чыгып киттеләр дә егет өенә апкайттылар. Анда мулла чакыртылган булган. Мине ризалаттылар инде. Никах укылды. Ник китмәдем? Позор бит. Аннан ул бик чибәр кеше иде, зараза. Дүрт бала үстердек.

**Кемнең җен күргәне бар?**

**(***мифологик хикәят)*

Күп укыган кешегә җен ияләшә, ди. Миңа да ияләште бервакыт. Ахшам укыдым. Караңгы. Дисбе тартып утырам. Карасам, дисбем төймәләре арасыннан ике ялтыр күзле кап-кара нәрсә килеп чыкты. Бәләкәй генә үзе. Кит, дим, «Лә һәүлә вә лә кувәтә»не укып, күзенә төкерәм. Китми дә, күзен дә йоммый. Шуннан кызымны чакырдым. «Инәкәй, әйдә сызыйк», – ди кызым. «Аятелкөрси»не укып, икәүләп пычак белән стенаны сызып чыктык өй эче буйлап. Икенче көнне двухстволка мылтыктан аттырдык, куркытыр өчен. Шуннан бетте теге җен.

*Гали авылынды Моратханова (Галимова)*
*Наилә Закир кызыннан (1936 елгы)*
*язып алынды*

**Җеннәр патшасы**
(*мифологик хикәят*)

Ураган булган көн иде. Каз-чебешләремне, бәрәннәрне яшердем. Шул вакыт һавада ике зур күз миңа карап тора. Җеннәр патшасы ые ул. Пычак алдымда: « Кит, җеннәр патшасы. Балаларыңны суям шушы пычак белән!» – дип куркыттым. Китте.

*Гали авылында Әхмәдиева (Йосыпова)*
*Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы)*
*язып алынды*

**Буш өйгә җен ияләшә**
(*мифологик хикәят*)

Ядманко поселогында бер йорт бар. Сукаевка кырыенда. Иске йорт, без анда барып йөри идек. Кечкенә чагымда сеңелем белән шул өйдә куна калдык бервакыт. Утны сүндердек кенә, әллә нәрсә беләгемне сыйпап уза. Куркып ут яндырдык. Ишек бер ачыла, бер ябыла. Төне буе шулай итте. Җен йөрде төне буе. Буш өйгә ияләшкән булган. Курыктык.

*Гали авылында Саниева Фатыйма*
*Габделфәт кызыннан (1953 елгы)*
*язып алынды*

**Бабкай чишмәсе**
(*дини йола бәйрәме*)

Галидә Морат бабкай чишмәсе бар. Авылны чукындырудан саклап бик каты көрәшкән, шул көрәштә ике күзсез калдырылып, аннары үлеп киткән староста кабере янында тибеп чыккан. Чишмәгә халык йөри. Монда ел саен Чишмә бәйрәме уздырыла. Корбан бәйрәмен һәм кайбер башка дини бәйрәмнәрне бар халык җыелып шул чишмә янында уздыру гадәткә кереп бара. Шул көнне, Чишмә бәйрәме, дибез.

Чишмә бәйрәме – зур бәйрәм. «Син Чишмәгә барасыңмы?», – дип сөрән сала-сала җыела халык бәйрәмгә. Анда әллә кайлардан киләләр. Өчәр мең кеше җыела. Бабкай рухына догалар кылына. Байлар ел саен сәдака итеп сарык суйдыралар. Корбан бәйрәме дә ел саен шушында уза. Бәйрәм көнне тугызар сарык суела. Ир-атлар иртән иртүк барып суялар, эшкәртәләр. Хатыннар барып ит турый.

Зур-зур казаннар асыла. Шунда шулпа пешерәбез. Пешкән итне турап өләшәбез һәр кешегә, шулпа да өләшенә. Берәү дә өлешсез калмый. Килә алганнар бар да килә чишмәгә, килә алмаганнарга алып барып бирәбез. Килүчеләр берсе дә буш килми, ризык алып килә табынга. Намазлар укып, вәгазьләр тыңлап, өстәл тутырып мәҗлес ясыйбыз. Гыйлем кешеләрне, мәдрәсә шәкертләрен тыңлыйбыз.

*Гали авылында Әхмәдиева (Йосыпова)*
*Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы)*
*язып алынды*

**Хат**

(*фольклорда эпистоляр жанр үрнәге*)

Бер ирне солдатка алалар. Башкаларга карамасын, дип, хатынына болай дип хат язып җибәрә бу:

Алтын балдак кадакта
Барысына да кояш булма,
Калырсың бит азакка.

*Гали авылында Зарипова Фәимә*
*Әхмәтшәриф кызыннан (1957 елгы)*
*язып алынды*

**Түгәрәк уен**

(*уен-йола фольклоры*)

Түгәрәккә басасың егетләр, кызлар – барың бергә. Кемдә нинди матур ерлар бар, бары да ерлана шунда. Ерлый-ерлый әйләнәләр. Шунда берәү тәгәрәктән чыга да үзенә пар сайлап ала. Икесе түгәрәк эчендә парлап әйләнәләр. Түгәрәктәгеләр дә әйләнә, түгәрәк эчендәгеләргә атап ер ерлана. Аннары уртадагыларның башта чыкканы кабат түгәрәккә баса, эчтә калганы үзенә икенче пар сайлый. Инде аларга ерлана.

Кашың кара кыйгачтыр,
Син үзең сандугач булгач,
Ярың да сандугачтыр.

Авызың зур, нишләтим?
Авызыңа мич чыгарып,
Общий барак эшләтим.

Алыя, гөлия, гөл арасында чия,
Бер күрдем дә гашыйк булдым.
Яннарым сине сөя.

Алыя, гөлия, гөл арасында чия,
Күз карашлары үзгәргән,
Ахры ятларны сөя.

*Нугай авылында Кәлимуллина Мөхлисә*
*Кәлимулла кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

**Аш җыю тәртибе**
**(***йола фольклоры***)**

Ашка чакыралар. Коръән ашына. Әйтик, үлгән кешенең елына. Башта ирләр килә. Анда мулла була инде. Мулла вәгазьдән башлый. Коръән укыла, ясин, тәбарәк, багышлаулар була, сәдака өләшенә. Ирләр таралгач, хатыннар килә. Хатыннар табынында абыстай башлый. Салават әйтелә, тәхлил чыгалар, Коръән укыла, ирләр ясин чыккан булса, башкасын укый абыстай. Үзара сәдака өләшәләр хатын-кызлар да, багышлаулар була. Ирләр табынында да, хатыннар табынында да хәзрәт әйткән яки абыстай әйткән кеше белгәнен укып күрсәтү бар. Ашта мөнәҗәт әйтелми. Мөнәҗәтләрне Мәүлед кичәсендә әйтәләр.

Аштан соң йорт хуҗасына рәхмәт әйтеп, багышлау укыла, алып килгән күчтәнәчләргә дә дога кылына.

*Нугай авылында Кәлимуллина Мөхлисә*
*Кәлимулла кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

**Йорт анасы**
**(***мифологик хикәят***)**

Йорт анасы бит ул кеше күзенә төрле нәрсә булып күренә. Күренмәскә дә мөмкин. Күренмәсә дә, һәр йортта бар ул. Аның турында күп сөйләргә ярамый бит. Үпкәләткәнне яратмый ул, борчый башлый. Башка йортка күченә калсаң, аңа әйтәсең: «Әйдә, хуҗа, миннән калма, миңа ияр. Сакла мине». Шулай дип әйтергә кирәк.

*Нугай авылында Алтынбаев*
*Габделкави Габделхак улыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

### Йорт анасы нинди эшләр башкара?
(*мифологик хикәят*)

Бәләкәй чакта ишеткәннәрем бар ые. Иртән торуга лапаска чыксаң, мал-туарлар тирләп-пешеп беткән. Йорт анасының эше бу. Ачуы килгән булса, шулай итә. Йорт анасы, яратмаганга, төне буе малларны куып йөрткән, диләр ие. Мунчасына да, йортына да, лапасына да хуҗа ул. Шуны йорт анасы диләр инде. Күченсәң, «Әйдә, калма бездән, ияр», – дип әйтергә кирәк. Йорт анасы үзеңнән калмый күченсә әйбәт. Саклаучы ул. Аллаһ шулай яралткан бит аны. Өйдә орчык эрләгән тавышлар чыгара ул, әле генә кул астындагы әйбереңне яшереп куеп шаяра, аннары кире урынына китереп куя, лапастагы атның ялларын үрә төнлә белән. Нишләп хатын-кыз затыннан? Соң, хатын-кыз бит бөтен нәрсәне күреп, нечкәлекләрен белеп тора йортта. Йорт анасы да шулай.

*Нугай авылында Кәлимуллина Мөхлисә*
*Кәлимулла кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

### Нугай авылы исеменең килеп чыгышы
(1 нче вариант)
(*тарихи-топонимик риваять*)

Монда сплошной урман булган элек. Нагайка – кыска камчы. Байлар шул камчы белән кыйнап, кешеләрне урман кистергәннәр. Шуннан Нагайка дип калган бу авылның исеме. Чын исеме шулай.

*Нугай авылында Алтынбаев*
*Габделкави Габделхак улыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

### Нугай авылы исеменең килеп чыгышы
(2 нче вариант)
(*тарихи-топонимик риваять*)

Татарлар Үзбәкстанга киткәннәр. Анда боларны «нугай» дип йөрткәннәр. Шуннан кайтып, Нугай авылы булып яши башлаганнар. Татарны үзбәкләрнең нугай диюе авылга исем булып киткән.

*Нугай авылында Сафиуллина*
*Рәйсә Шәрип кызыннан (1937 елгы)*
*язып алынды*

**Никах уку тәртибе, туй**
**(***йола фольклоры***)**

Никах бездә гел кыз ягында укылган. Кыз сорала. Әтәй белән инәй риза булганнар менә мине сорарга килгәч. 2–3 ел сөйләшеп йөргән егетем иде.

Никахтан соң аерым өйдә кунасың бит инде. Икенче көнне егет ягына кайтасың. Мунча кертәләр. Шуннан туй үтә егет ягында. Әрчиләр белән киләләр инде. Табак-табак күчтәнәч килә. Рәхмәт әйтеп алып куялар. Элгәре туйлар күңелле була торган иде бик. Конфет сибәләр. Килен пирчәткә ыргыта. Әйткән сүзләре әллә ни юк иде аның. Шулай күңелле була торган иде. Гармуннар белән җырлап үтә иде туйлар.

*Нугай авылында Алтынбаева*
*Хәния Галәветдин кызыннан (1940 елгы)*
*язып алынды*

**Красный мост авылы риваяте**

Авыл Красный мост дип ник аталган? Татар авылы булса да, исеме русча гына йөри. Богорусланга китә торган юлда бер күпер булган. Кызылга буялган күпер. Красный мост авылы әле егерменче еллар ахырында гына барлыкка килгән. Ә күпер Әби патша заманында ук булган. Каторжан юлы узган шул күпер аша. Сәнәк сугышы вакытында аклар күперне яндырган. Ул күпер беткәнгә күптән инде. Авылга исеме генә калган.

*Красный мост авылында Вакказов*
*Газизнур Мөхәммәтнур улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

**Кодагый, хәзер таң ата**
**(***мәзәк***)**

Базарга барган да бер хатын, кайтышлый кодагыена кагылган. Кунарга калган. Кунакны ашарга бик кыстыйсы килми икән хуҗабикәнең.

– Хәзер таң ата, кодагый, хәзер таң ата, – дип, кунагын көттерә икән.

– Атыр, кодагый, атыр, атканчы бер ипине тартыр, – ди икән карыны ачкан кодагые моңа каршы.

**Кемне сөйсә дә барыбер**

**(*мәзәк*)**

Бер килен кияве (ире) белән яхшы тормаган. Муллага килгән киңәш сорарга.

– Татулык юк. Ирем сөйми башлады. Гел талаша. Балаларны ятим итәсем килми. Нишләргә? – ди икән.

– Мин сиңа бер дога язып бирермен. Ачма, укыма. Ирең талаша башласа, шул дога язылган кәгазеңне ал да тышка чыгып тор. Бераздан кер, – дигән моңа мулла, язу язып кулына тоттырган.

Ярар. Кайтып киткән хатын муллага рәхмәт укып, сәдакасын биреп. Өенә кайткач, мулла әйткәнчә эшләгән инде. Яхшы тора башлаган болар. Өйдә татулык икән. «Ничек шулай?», дип, боларның тату яши башлауларының серен беләсе килгән башка хатыннарның. Теге хатын үзенең муллага баруы, аның дога язып бирүе турында сөйләп биргән. Укыйк әле, ни язган икән соң, дип, теге язуны ачып укыганнар.

Аны сөйсәни миңа,
Моны сөйсәни миңа,
Биш тиен акчасын биргәч,
Кемне сөйсәни миңа! –

дип язылган булган, ди, мулла биргән кәгазьдә.

*Красный мост авылында Вакказова (Вәлиева)*
*Хәтимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

**«Кач-кач»**

**(*уен, балалар фольклоры*)**

Йөз чыбык чәчтереп җибәрәсең. Көтүче чәчелгән чыбыкларны җыеп бетергәнче качып бетәргә кирәк. Көтүче, чыбыкларның җыелганнарын берәсе йөгереп килеп чәчмәсен, дип саклый-саклый, йөз чыбыкны да җыеп бетерә. Чәчтерсә, кабат җыя башлый. Җыеп бетергәч, качкан кешеләрне эзләү башлана. Көтүчене болай саный идек:

Әткәмә-сүткәмә,
Әбел-фәбел думина,
Ике-пике раматака,
Зәйнеспис.

Кемгә «Зәйнеспис» сүзе чыга, шул көтүче була.

**Йорт анасы нәрсә ярата?**
(*мифологик хикәят*)

Йорт анасы бар. Сыерларның ялларын үреп куя. Шулай дип сөйлиләр ие. Яңа мал алып кайтсаң, йорт анасын ризалату тиеш. Ипи пешерергә дә, бер зур телем кисеп алып, аның өстенә май ягарга, шуны лапас түбәсенә менгереп куярга кирәк. Шуннан йорт анасына эндәшәсең:

– Йорт анасы, без сине яратбыз. Безнең малыбызга тимә. Без алып кайткан малны син дә ярат. Менә бу ипи – сиңа. Шулай итсәң, йорт анасы малларны ярата.

*Красный мост авылында Йосыпова*
*Рәйсә Гариф кызыннан (1932 елгы) язып алынды*

**Юктан бар итүче Аллаһ**
(*мөнәҗәт*)

Үлем-яшәеш тормышны Аллаһы юктан бар итте,
Җиде кат күк, сигез җәннәтне, Җир йөзен бүләк итте.

Аллаһы – безне ярлыкаучы, яманлыктан саклаучы,
Аллаһ кушканнарны үтик тар гүрләргә ятканчы.

Аллаһыдан иң олуг әҗе, гөнаһлардан сакланыйк,
Җәннәт насыйп итәр безгә гамәл кылсак мактанмый.

Көндәлек кылган эшебез үлчәү мизаннарында,
Игелекле саваплар басар яман эш кылынганда.

Җәһәннәм уты һәвия насыйп итмә һичкемгә.
Сират күперен үткән чакта зинһар, тайдыра күрмә.

Аллаһы хуплар юмартны, хәер-сәдак бирик.
Аллаһ бөек, тәсбих әйтик, өскә бурычлар җыймыйк.

Игелек кылып, тәүбә итсәк, кабуллыкка ирешер,
Кыямәт көнне бар мөселман хисаплашыр, күрешер.

*Гали авылы Морзаханова Саимә*
*Әхмәдулла кызыннан (1947 елгы) язып алынды*

**Күз тигәннән**
(*имләү йоласы*)

Күз тисә иә берәр җирең сырхауласа, имлиләр. Иртәнге якта таң суы алып кайтып, суга Әлхәм, Нас, Аятелкөрсине укып, өрәләр. Шуның белән юындыралар кешене.

– Черегэн бетер, тазасына тимә, тфү-тфү! – дип өшкерәләр.

*Гали авылында Баһаветдинова*
*Әнисә Шәрип кызыннан (1926 елгы) язып алынды*

**Дини риваять**

Рәсүлебез Мөхәммәд с.г.в.гә бер бәндә килеп кергән. Ашарга сораган. Мөхәммәд с.г.в. әйткән:

– Иман китер, ашатырмын, – дигән. Теге бәндә иман китермәгән, борылып чыгып киткән.

Шул хәлдән соң Мөхәммәд пәйгамбәр с.г.в.гә әйтә Раббыбыз:

– И Мөхәммәд, – ди, – мин бөтен дөньяны ризыкландырам. Бер нәрсә сорамыйм. Син, бер бәндәне ашатыр өчен, аның иман китерүен шарт иттең. Кешенең күңеленә иман нурын үзем генә салам, син түгел. Рәнҗешен алма бәндәнең, хәтта ул башка диндә булса да.

Шуннан Мөхәммәд с.г.в. теге бәндәне куып җитеп, өенә алып кайтып ашатып чыгара.

**Кем ул Морат бабкай?**
**(***тарихи риваять***)**

Морат бабкай гаҗәп хикмәт иясе кеше булган. Галинеке. Патшага киткән бервакыт үзенең кучеры белән. Патша аны яхшы каршы алган. Морат бабкай патшага туп-туры барып, гозерен әйткән. Патша аңа җир биреп, күп бүләкләр белән кайтарып җибәргән. Аллаһ тәгалә илһам биргән Морат бабкайга патша белән оста итеп сөйләшергә.

Морат бабкай авырый башлаган. Көз көне икән. Әйткән бер туганына:

– Бар әле тауга. Чия җыеп төш, – дигән.

– Бу вакытта нинди чия?

– Бар әле син, бар. Баргач күрерсең. – ди икән Морат бабкай. Теге барса, Морат бабкай әйткән төштә кып-кызыл чия, ди.

*Гали авылында Арсланов*
*Ильяс Хафиз улыннан (1937 елгы) язып алынды*

**Йорт анасы бармы?**
**(***мифологик хикәят***)**

Йортта савыт-сабаларны шалтырата, йә он иләгән, йә йон эрләгән тавышлар чыгара, диләр инде йорт анасын. Белеп сөйләү түгел. Аллага тапшырырга кирәк.

**Күз тиюдән – миләш ботагы**
**(***ышану-йола***)**

Чәчәк ата башлаган миләш ботагын өченче төн дигәндә чыгып аласы. Алдан карап куясы кайсы ботакны аласыңны. Иң аскы ботактан булырга тиеш. Пычкы тотып чыгасың да агачны ранить итмичә генә бер удар белән выжт итеп кисеп аласың ботакны. Шуны алып кереп куясың өйалдында, кеше күзе төшми торган урынга. Бер ел кибә. Шуннан соң ботакны икешәр см кисеп, күз тимәсен өчен киемгә тагасың. Олы кеше кесә артында йөртә инде аны, баланың баш киеменә – маңгай турына тагасың. Тимун (тилемиле, мәгънәсез сорау бирүче) кеше: «Бу нәрсә?» – дип соравы була, күзе шунда кала, төшми балага. Миләш ботагын үзе белән йөрткән олы кеше, түрәләр катына барганда сорый инде:

– И Илаһым, ярдәм бир! Миләшкәем, сакла мине. Дошманнарның ыркынын (явызлык) җибәрмә.

*Гали авылында Әхмәдиева (Йосыпова)*
*Асия Хәлимулла кызыннан (1958 елгы)*
*язып алынды*

**Яңа Мансур авылы турында**
**(***тарихи риваять***)**

Мансурда халык төрле племялардан. Выты шыңа күрә халык төрлечә сүләшә. Например, кем әйтә, «бүлбе», без әйтәбез «бәрәңге алмасы». Мансур дигән кеше булган. Иске Мансур авылы – шул Мансур килеп утырган авыл. Халыклар килгән Казан ягыннан. Мәннан бабай булган Мансурның әтисе. Ул калган Әмәнәктә. Мәннанның өч улы булган. Яңа Мансур урынында башта мукшылар яшәгән. Мукшы очы хәзер дә бар. Мансур элгәре Иске Мансурга урнаша бит инде, анда Алла белә күпмедер тора. Иске Мансур – мукшы авылы. Татар урамы, диләр алар Мансурлар яшәгән җирне.

Аннары Мансур Яңа Мансур җирләренә күчә. Мукшылар күченә Иске Мансурга. Бер семья гына кала. Монда инде Яңа Мансур дигән авыл төзелә. Башта ферма очына – Түбән очка урнашалар. Яңа Мансурга кабат төрле племялар килеп төпләнә.

*Яңа Мансур авылында Мусина Нәсимә*
*Фәрхетдин кызыннан (1942 елгы)*
*язып алынды*

### Мансур авылы турында риваять

Әмәнәк инеше тамагында Мәннан исемле кеше яшәгән. Аның өч улы булган: Мансур, Абдулла, Исхак. Мәннан тора-бара улы Мансурны хәзерге Иске Мансур авылы урынына күчерә. Икенче улы Абдулла урман аланына өй салып, шунда көн итә башлый, завод төзи. Өченче улы Исхак, Исаково авылы урынында яшәп, тире чималы җитештерү белән шөгыльләнә.

Иске Мансур авылында мордвалар, чувашлар да яшәгән. Татарларга керәшен, чуваш, мукшыдан кыз алу ярамаган. Яңа Мансурга керәшеннәр килгән булган урнашырга, төн эчендә куып чыгарганнар. Киткәннәр. Бу авылда керәшеннәр юк, булганнары да ислам кабул иткәннәр. Бервакыт Мансур татарлары авылның керәшеннәр килеп урнашкан Түбән очына килеп йөрүче попны тотып алганнар да сакалын кырып атканнар. Сакалсыз кеше священник була алмый икән. Шушы хәлдән соң авылда булган керәшеннәр ислам кабул иткән. Тирә-юньдә мукшылар белән катнаш авыллар бар. Мукшылар элегрәк килеп урнашкан булганнар монда. Яңа Мансур 1787 елда төзелгән, дип язылган.

*Яңа Мансур авылында Мусин*
*Дамир Минсаф улыннан (1936 елгы) язып алынды*

### Атын жәлләгән
**(*хикәят*)**

Берәү базардан кайтып бара икән. Ат өстенә бер капчык бәрәңге салган. Мулланың «Хайваннарга мәрхәмәтле булыгыз» дип сөйләгән вәгазе исенә төшкән моның. Туктале, дигән бу, атыма мәрхәмәтле булыйм әле, ди икән. Шуннан бу бәрәңгене аттан төшереп, капчыкны үз аркасына бәйләп куйган да, атка менеп атланган. Юл буе үзенең хайванга рәхимле-шәфкатьле булуына исе китеп кайткан ат өстендә.

### Акыллы хатын
**(*хикәят*)**

Бер бай кеше бер матур җирдә бакча ясаган. Җире фәкыйрә бер хатынныкы булган. Җәберләп, җирен алган булган моның бай кеше. Бер көнне бай бакчада йөргәндә бу хатын бай янына килә дә:

– Шул бакчадан бер капчык туфрак алыймчы, рөхсәт бирсәнә, – дип сорый. Ник бирмәскә, дип, бай риза була. Бай рөхсәте белән

хатын бакчадан бер капчык туфрак тутыра да җилкәсенә күтәреп алып китмәкче була, байга әйтә:

– Шул капчык туфракны җилкәмә күтәртеп кенә җибәрсәнә, – ди. Байның гомерендә дә авыр әйбер күтәргәне булмаган инде. Алай да, мәрхәмәте килеп, күтәртеп җибәрим булмаса, дип, капчыкка тотына. Авыр капчыкны селкетә дә алмый, хәленнән килми.

– Юк, булмый, мин моны күтәрә алмыйм, авыр икән, – ди инде хатынга, нәрсә дисен. Шуннан хатын әйтә моңа:

– Ә-ә, шулаймы? Минем хакым булган шушы бакчадан бер капчык туфракны да күтәрә алмадыңмы? Бу бакчада әллә ничә мең капчык туфрак бардыр. Кыямәт көнендә аларын күтәреп Аллаһ каршына ничек барырсың соң? – ди.

Шулай акыллы итеп аңлаткан теге хатын моңа, байга сабак биргән булып чыга инде. Моны ишеткән бай:

– Мин гаепле, ал бакчаңны, – дигән, гөнаһыннан тәүбә иткән.

*Иске Мәчәләй авылында Булатова*
*Шәмсегаят Миргаз кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

**Мәчәләй**
**(*тарихи риваять*)**

Мәчәләй – каян ул исем – белмим бер дә. Бабайларның аталары Пенза ягыннан килгән. Бабайның әтисе Исмәгыйль килеп урнашкан бирегә. Аның улы Ибраһим булган. Пензадан күпме гаилә килгәнен әйтә алмыйм.

*Иске Мәчәләй авылында Габдрахманов*
*Ибраһим Миргазыйм улыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

**Бала коендырганда**
**(*афористик жанр, теләк-алгышлар*)**

Тәнен пакь кыл!
Иманын нык кыл!
Исәнлек, тәүфыйк-хидаят бир!
Мөселман әһеле булып туган бу баланың каршыңа да мөселман булып баруын насыйп ит!
Ислам динен куәтләүче булсын!

## Кыска җырлар

Агыйделгә төшкән идем,
Камыштан камчы үреп.
Былбыл булып очып йөрсәм,
Сөйләшер идем күреп.

Өй түрендә алмагачым,
Чәчәк ата бөрлегән.
Син бит минем руза гөлем,
Син бит минем бергенәм.

Сандугачым, сизәсеңме,
Кисәләр талларыңны,
Берьялгызым торам гел дә,
Белмисең хәлләремне.

Сандугачым, сизәсеңме,
Кисәләр талларыңны,
Сикереп суларга төшәрсең,
Алсалар ярларыңны.

*Иске Мәчәләй авылында Булатова*
*Шәмсегаять Миргаз кызыннан (1930 елгы)*
*язып алынды*

## Шамилә кыз бәете

Ашыгып-ашыгып эшкә барам
Сменага өлгерергә.
Ашыгуым юкка түгел –
Язмышымны күрергә.

Аклы ситса күлмәгемне
Бер туйганчы кимәдем.
Өйдән чыгып киткән чакта
Сау булыгыз, димәдем.

Иртән торып битем югач,
Көзгелләргә карадым.
Көзгеләргә карап туйгач,
Торасы минутымны санадым.

Иртән торып суга төштем
Әнкәем урынына,
Чәршәмбе көн эшкә киттем
Газиз башым куярга.

Иртән чыгып киттем бүген
Иртән сәгать җидедә.
Аста – бодай, өстә – бодай
Көндезге уникедә.

Аягымны күмде бодай,
Өстемә менде аннан.
Үләмен, алыгыз, диеп,
Кулымны суздым аннан.

Кара карга карылдавын
Нигә дә санамадым.
Бодай күкрәгемә җиткәч,
Кая да баралмадым.

Бодай менде өстемә,
Ни көн килде мескенгә.
Бәхил булыгыз, диялмадым.
Бодай тулды эчемә.

Иртән торып ашым ашап,
Мин сменага бардым.
Яшем унҗидегә җиткәч,
Бодай астында калдым.

Чиләк-көянтәмне алып,
Суга бардым иртә белән.
Бодай астында тилмереп,
Яным чыкты кич белән.

Әти-әни, туганнарым,
Булмадыгыз эш булгәндә.
Ян бирүдән авыр булды
Бодай астында калганда.

Әти-әни, туганнарым,
Янымда булмадыгыз.
Минем хәлемне ишеткәч,
Нинди сулыш суладыгыз?

Хәлсезләнгән әниемнең
Халык килгәнен күрде.
Кая минем балакаем?
Кем соң аны үтерде?

Аягымдагы сандалым
Аягымны кысадыр,
Балам, бәгърем үлде, диеп,
Әнкәй мирне кочадыр.

Көрәк белән эзләгәндә
Яным чыкты шул чакта
Әткәй-әнкәй, кайгырмагыз,
Минем җаным – оҗмахта.

Больницага алып барып,
Салдылар мине кроватька
Бодай ишелде яр булып,
Шамилә кыз күмелде.

Ары килдем, бире килдем,
Әҗәлемне эзләдем.
Зачет зерналарга йөреп,
Үләсемне белмәдем.

**Нурислам бәете**

И, дусларым, сез мине
Көл белән сыйладыгыз,
Бер Наҗияне сөйгән өчен
Дөньяга сыймадыгыз.

Әй уегыз, уегыз,
Нигә кибән куйдыгыз?
Үзегезнең дустыгызны
Кызганмыйча суйдыгыз.

Миннән калган вилосипедка
Сеңелем менеп утырсын.
Әнекәем, шул гозерем:
Атна кичен уздырсын.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Госманым.
Ун ткугыз яшемә җиткәч,
Суйды мине дусларым.

Тухтар бабайлар турында
Легковиклар килгәннәр.
Суеп эшне бетергәчтен,
Үзләре әйтеп биргәннәр.

Тухтар бабай бакчасында
Асыл кошлар сайрыйдыр.
Хафиз, Вазих кулым тоткан,
Салих пычак кайрыйдыр.

Миндин калган костюмымны
Канлы көйгә тотмагыз.
Тар кабергә керде, диеп
Әнкәем, онытмагыз.

Миндин калган костюмымны
Чөйдән чөйгә элегез.
Наҗия дустым килеп кергәч,
Үзем кебек күрегез.

Нурисламның бармагында
Алтын-көмеш балдагы.
Кәримнәргә бармый идем,
Вазыйх дустым алдады.

Минән калган галошымны
Әнкәй киеп туздырсын.
Әнкәемә шул гозерем:
Тулы Коръән тутырсын.

Сеңелемнең көзгесенә
Карадым мин кич белән,
Тухтар бабайлар турында
Ян бирдем мин кич белән.

ММСның кырларында
Күренә җирләрегез.
Хафиз, Вазыйх, Халит, Салих,
Сез мине җирләдегез.

Полный музыйк уйнап тора
Җеназаның артында
Наҗия кыз хакында.

Кулымдагы гармонемне
Уйнап бетерә алмадым,
Чәчәк кебек вакытымны
Уздырып бетерә алмадым.

Кара тышлы фуражкамны
Чөйдән-чөйгә элмәдем.
Салихларга бармый идем,
Үләсемне белмәдем.

Хафиз, Вазыйх һәм Салих
Мине килеп тоттылар,
Кичке сәгат алтыларда
Үләксәмне таптылар.

Гармоньнәрем уйнаганда
Бармакларым талдырам.
Яшьтән сөйгән Наҗияне
Ят кулына калдырам.

*Красный мост авылында Вакказова (Вәлиева)*
*Хәтимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

**Бавырсагың таралмасын!**
**(*туй йоласы*)**

Кыз ягында никах укытыла. Никахтан соң туйгача кияү кеше кыз йортында ята, монда аңа кияү мунчасы ягыла, кияү коймагы пешерелә. Туй көнне килен төшерү була. Туйга кыз бавырсагы пешерәбез. Килен төп йортка төшкәнче, башта бавырсагын алып китәләр, аннары – үзен. Бавырсакны кыз ягындагы туганнары пешерә. Оста чакырып та пешерәләр бавырсакны. Аны пешерүнең үз тәртибе, кагыйдәләре бар. Пешереп, ширбәттә болгатып өеп куйганнан соң, ике сәгать үткәч, бавырсак оешмаса, таралып төшсә, гаилә дә нык булмый. Бавырсак тулысынча таркалып бетсә, бу хәл гаиләнең дә таркалачагына ишарә итә. «Бавырсагы таралган», – диләр аннары.

**Килен каршылаганда**
**(*туй йоласы*)**

Туй көнне йортка килен төшә. Килен каршыларга кайнана ширбәт, май белән чыга.

– Телең ширбәт кебек татлы, күңелең май кебек йомшак булсын! – дип каршылый киленен. Йортка кергәндә киленне мендәргә бастыралар:

– Урының төпле булсын! – диләр. Ә килен кеше төшкәч тә егет ягына алъяпкычлар өләшә. Янәсе, кайнана аның янында йөгереп кенә йөрсен алъяпкыч киеп. Монысы – хәзерге гадәт.

### Каз өмәсендә бәлеш урлау
**(***йола элементы***)**

Каз өмәсеннән соң кызлар йыелыштык. Бәлеш салынган. Егетләр килде. Такмак әйтеп йырлыйлар. Икесе яңа такмак өйрәнгән:

– Пешә төшә, – ди берсе. Аңа каршы икенчесе әйтә:

– Пешә төшсә, бөгелә төш.

– Бөгелә төшсәң, суы чыга.

– Суы чыкса, шу да чык.

Карасак, бәлешне чәлгәннәр. Бәлеш турында әйтешәләр икән болар үзара. Без, такмак әйтәләр, дип, авыз ачып тыңлап торабыз. Ырланган бәлешне кире бирәләр иде. Бәясе – йә түләгез акчагызны, диләр инде, йә йырлаталар.

*Яңа Мәчәләй авылында Әмирова Асия*
*Әхмәтгали кызыннан (1956 елгы)*
*язып алынды*

### Юкәле тау
**(***топонимик риваять***)**

Юкәле тавын Әүлия турысы дип йөртәләр. Ул тау Изгеләр тавы санала. Изге тауда әулия күмелгән, дип сөйлиләр иде, шуңа «изге» диләр ул урыннарны. Тауның итәгендә элек карт ак каен үсеп утыра иде. Хәзер ул каен юк инде, картаеп, корып ауды. Солдатка киткәндә, әле патша вакытында ук, каен кәүсәсен чокып, егетләр исемнәрен язып калдыра торган булганнар. Шундый карт каен иде ул.

Монда элек Ярмөхәммәд исемле кешенең биләмәләре булган. Авылның исемен шуңа Ярмәк атаганнар. 1737 елда авылга рәсми нигез салынган дип барыла. Әмма чынлыкта авыл борынгырак, 500 еллап тирәсе бар аның оешуына.

*Иске Ярмәк авылында Галимуллин Наил*
*Нәбиулла улыннан (1957 елгы)*
*язып алынды*

## Кыска җырлар

Кашларың кара кыйгач,
Нигә кыйгач булмасын соң,
Балталар (*пәкеләр*) белән кыргач.

Әнә килә бер машина,
Төягәннәр тет(ы)рад.
Урман якын, кошлар сайрый,
Сагындыра иф(ы)рат.

Америка калагы,
Берсе озын, берсе кыска
Ыштаныңның балагы.

Әнә килә бер машина,
Төягәннәр капчыклар.
Ике чокыр арасында
Шаяралар карчыклар.

Ярыкларга кыстырам,
Мин уртага чыккач кына
Ерламыйлар ыстырам.

Кашың кара сөрмәле,
Авызың капчык бөрмәле,
Бүген төнлә үләт йөрде,
Ничек сине күрмәде?

*Красный мост авылында Вакказова (Вәлиева)*
*Хәтимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды.*

## Җырлар

Аерылдык, аерылдык,
Дөнья шулай аера.
Безнең түгел, кошларның да
Канатларын каера.

Бакчадагы гөләремне
Сандугачлар таптаган.
Минем бәхет йолдызымны
Кара болыт каплаган.

Бакчаларга керденме?
Мәк чәчәге өзденме?
Мәк чәчәкләрен өзгәндик,
Аерылдык, сизденме?

Әнкәем елый ат җиккәч,
Кайтмыйсың, ди, бер киткәч.
Ир балалар кайта хезмәт иткәч,
Кыз балалар кайтмый бер киткәч.

Иртән торып тышка чыксам,
Машина алларымда.
Балакаем, ян биргәндә
Булмадым яннарында.

Иртән торып тышка чыксам,
Алларымда машина.
Үлеп гүрләргә кергәнчә
Хәсрәт салдың башыма.

Утлар яна учакта,
Заман авыр бу чакта.
Кычкырып елап җибәрәм
Сине сагынган чакта.

Тәрәзәмнең алларында
Үсеп утыра бер нарат.
Хәсрәтләремне сөйлимен
Шул наратыма карап.

Алмагачым алма бирми,
Корыган чыбык кына.
Дивана күкеләр кебек,
Кычкырмыйм чыгып кына.

Йөгерә-йөгерә җиләк җыям
Чиләкләрем тулганчы.
Йотсам да йокылар алмый
Сездән хәбәр алмыйча.

Алларым кебек күрәм,
Гөлләрем кебек күрәм,
Әллә нигә бик яратам,
Яннарым кебек күрәм.

Киртәләргә элеп куйдым
Пуховый шәлләремне.
Кошларга да сөйләр идем,
Кош белми телләремне.

Бакчаларга борчак чәчтем,
Үсә микән борчагым?
Кая гына китте икән
Йөгереп йөргән яшь чагым?

Чәчең озын, чәчең озын,
Чәчең озын биленңнән.
Кемнең дә китәсе килми
Туган-үскән иленнән.

Алмы синең яулыгың?
Гөлме синең яулыгың?
Күзгә-башка күренмисең,
Юкмы әллә саулыгың?

Телеграмм баганасын
Бер санадым – унике.
Бер хәсрәтсез булыр микән
Бу дөньяда минеке?

Олы юлның тузанын
Мин күрмәдем тузганын.
Бер Ходаем гына белә
Гомерем ничек узганын.

*Яңа Мансур авылында Ягудина Әминә*
*Гайфетдин кызыннан (1928 елгы)*
*язып алынды*

**Кичке уен җырлары**

Аллар итә торгандыр,
Гөлләр итә торгандыр,
Алма битең, кич утырып,
Сине көтә торгандыр.

Сары сандугач булаем,
Тәлинкәңә кунаем.
Икегез дә кара кашлы,
Кайсыгызга булаем?

Армиядә егетем.
Егетемә хат язарга
Ике чиләк дегетем.

Агыйделләр ага-ага
Нигә тулмаган икән?
Кошларда – кул, бездә канат
Нигә булмаган икән?

Сабырлык – сары алтын,
Мин сабырлар итә алмыйм,
Эчләрем тулы ялкын.

Кара йөзем өләшәм,
Эх, дусларым, кавышыгыз,
Мин дә теләк теләшәм.

Сары матур сайласаң,
Тавышыңнан таныр идем,
Былбыл булып сайрасаң.

*Яңа Мансур авылында Мусина Нәсимә*
*Фәрхетдин кызыннан (1942 елгы)*
*язып алынды*

**Иске Ярмәктә солдатка озату җырлары**

Сау бул, Ярмәк, сау бул, Ярмәк,
Юкәле тауларың белән.
Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә лә
Калган яшьләрең белән.

Әткәй, әнкәй, сау булыгыз,
Еллар кайтмый улыгыз,
Бу китүдән кайталмасам,
Туганнар, сау булыгыз.

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләр микән көзгә?
Язгы ла Сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә?

Каршыбызда – юкәле тау,
Тагын яшәрер әле.
Ходай гомерләрне бирсә,
Бергә яшәрбез әле.

*Иске Ярмәк авылында Галимуллин*
*Наил Нәбиулла улыннан (1957 елгы)*
*язып алынды*

**Сук буе**
**(***Иске Ярмәк җыры***)**

Сук (елга исеме) буенда ялгызлыкта таллар,
Башын түбән ия тал-тирәк.
Сөйгән ярын югалтудан курка
Яшәү тәмен белгән һәр йөрәк.

Язлар үтсә, ямьле матур җәй ае бар,
Киткән кошлар кайтмый калмыйлар,
Көтәм, син дә кайтырсың әле.

Кар буранлы озын гомер юлын
Бергә үткән дустым ташлармы?
Мәхәббәте көчле булса, кайтыр,
Гөл дә тишеп чыга ташларны.

Язлар үтсә, ямьле матур җәй ае бар,
Киткән кошлар кайтмый калмыйлар,
Көтәм, син дә кайтырсың әле.

**Зурбашлар**
(*нәсел кушаматы*)

Бабалары капка баганасына менеп утырган да кечкенә чагында: «Мин – югары, мин – баш!» – дигән. Шуннан нәселләренә Зурбаш кушаматы тагылган. Иремнең нәселе турында сөйлим. Җырлыйм да:

Кепканың яшелләре.
Тагын берне сөяр идем
Зурбашның нәселләрен.

*Иске Ярмәк авылында Гайфуллина*
*Фәния Фатих кызыннан (1957 елгы)*
*язып алынды*

**Чишмәләр**

Дәүләтколда Иске Симәннән агып чыккан Камышлы елгасына тыкрык буйлап төшкәч тә Изге чишмә ага. Кыйблага таба ага, шуңа изге дигәннәр. Суы шифалы. Ул чишмә янында начар сүз әйтү түгел, начар уй уйларга да ярамый.

Буйдан-буйга сузылган озын тау бар авыл янында, шул таудан агып чыккан чишмәне Озын тау чишмәсе диләр. Ташлары кош канаты шикелле ике якка карап тора чишмәнең. Суы тәмле.

*Дәүләткол авылында Галәлетдинова*
*Тәлига Мәсәллим кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

**Озын көйгә җыр**

Сакмар дулкыннар, курай моңы
Онытылмаслык гомер-гомергә.
Дәүләтколның матур һавалары
Матур болыннары онытылмаслык ла.

Кар сулары акты, ярсулары бетте,
Ташлар тәгәрәми ташкында.
Минем генә йөрәк, кавышуны теләп,
Юрга-й аттай сиңа-й ашкына.

Аерым торып еллар аймыл булды юллар,
Нигә гомер аерым булган соң?
Бар шул инде парың, өзелеп сөйгән ярың,
Кулларыңны-й шуңа сузгансың.

Арта уйлар һаман, тарта сиңа табан,
Кыен миңа ялгыз чакларда.
Сөенечкә, дисәм, көенечкә икән
Күрүем сезне шушы-й якларда.

*Дәүләткол авылында Мөхетдинова*
*Рәйхана Гайнетдин кызыннан (1932 елгы)*
*язып алынды*

**Тизәйткечләр**

1. Кара карганың канатын каерсаң, кара кан күренә.
2. Чукынчык, чынаяк чокырын чыкылдатма!

*Яңа Ярмәк авылында Гафурова*
*Гөлсинур Шәйхрази кызыннан (1953 елгы)*
*язып алынды*

**Ишек – кискән, тәрәзә – тишкән**
(*афористик жанр үрнәге, әзер җавап*)

Халкыбыз бик кунакчыл. Экспедициядә йөргәндә кайсы гына өйгә керсәң дә чәйгә кыстау гадәте бар. Самара өлкәсе авылларының берсендә хуҗабикә кыстый-кыстый табынга утыртты, хәзинәдә барын өстәленә тезде. Үзе туктаусыз сөйли:

– И-и, әйтеп килмәдегез бит менә, әйтеп килмәдегез! Бәлешләр пешереп торган булыр иек. Бәлешкә дигән итләрем дә әзерләп куелган. Тәмле итеп бәлешләр салган булыр ием!

Безне информантларга озата йөрүче җор телле апа әйтә куйды:

– Хәтимә апа, болар әле бездә атна-ун көн буласылар. Иртәгә килик мәллә алай булгач?

Хуҗабикә югалып кала торганнардан түгел:

– Ишек – кискән, тәрәзә – тишкән, килсәгез, – дип, бу темага әңгәмәне ябып куйды. Бу ападан шактый гына җырлар, мәзәкләр, бәетләр язып алып, ачык йөзе, тәмле чәе өчен рәхмәтләребезне әйтеп, юлыбызны дәвам иттек.

*Красный Мост авылында Вакказова*
*Хәтимә Шәяхмәт кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды*

# ТАТАР УЛ КАЙДА ДА БАЛКЫП ЯШИ

**Самара татарлары халык иҗаты үрнәкләре**

*Ильмир Ямалтдинов*

Самара өлкәсе табигатьнең гаять бай һәм бик матур җиренә урнашкан. Безнең ата-бабаларыбыз яшәү урынын сайлый белгәннәр шул, татар авылларының бер ягында кылганнар дулкынын манзара кылучы биек таулар булса, Камышлы белән Похвистнево районнары очрашкан тирәләрдә – авылларның икенче ягында – бик күп серләрне саклаучы, җырларга кереп калган Сук (Сок) елгасы ага:

Сук буенда ялгызлыктан
Башын түбән ия тал-тирәк,
Сөйгән ярын югалтудан курка
Яшәү тәмен белгән һәр йөрәк.

Кушымта:

Язлар үтсә, матур, ямьле җәй ае бар,
Киткән кошлар кайтмый калмыйлар,
Көтәм син дә кайтырсың әле...[1]

дип, озата сыман кешеләрне.

Әлеге өлкә җирлегендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну фольклорчы галимнәр тарафыннан 1960 еллар уртасында башлана. 1965 елда хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татар авылларына халык иҗатын җыю, туплау, өйрәнү өчен 2 төркемнән торган фольклор экспедициясе оештыра. Флора Әхмәтова җитәкләгән беренче төркемдә Халидә Гатина, А. Йосыпов катнаша. Алар Куйбышев

[1] Камышлы районы Иске Ярмәк авылында Гайфуллина Фәния Фатыйх кызыннан (1949 елгы) 2014 елда язып алынды.

(хәзерге Самара) өлкәсе Похвистнево, Келәүле, Шенталы районнарының татар авылларын тикшерәләр. Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган экспедиция материаллары һәм хезмәткәрләрнең хисабы буенча беренче төркем бай халык иҗатын язып алып кайта: 1030 кыска, 94 сюжетлы җыр, 34 уен һәм уен җыры, 2 әкият, 38 мәзәк, 11 бәет, 34 мәкаль, 8 табышмак, 2 балалар фольклорына караган жанр һ.б.[1] Икенчесе галимнәр Илбарис Надиров (җитәкче), Фатыйх Урманчеев һәм Хуҗиәхмәт Мәхмүтов катнашуында Кошки районында (Иске Фәйзулла авылы) барлыгы 582 кыска җыр, 18 лирик җыр, 1 бәет язып алалар[2].

Һәм, биш дистәгә якын еллардан соң, ниһаять, 2014 елның июнь ахыры – июль башында әлеге төбәктәге татар авылларына яңадан комплекслы экспедиция оештырылды.

Фольклорчылар халык авыз иҗаты материалларын – риваятьләр һәм авыл тарихлары, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, йола фольклорына караган үрнәкләр, халык уеннары, мифологик хикәятләр һәм ышанулар, мөнәҗәтләр, мәзәкләр язып алдылар.

Похвистнево, Камышлы, Келәүле районнарында урнашкан ун татар авылында булып, шәхсән мин үзем дә, утыздан артык информанттан ике йөз утызлап берәмлек авыз иҗаты үрнәкләре алып кайттым.

Самара өлкәсендә яшәүче татарлар арасында иң киң таралган жанр – җыр. Йөз иллегә якын җыр язып алынды, алар нигездә, кыска җырлар. Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла. Озын көйләр татар-мишәр авылларында һәм, бигрәк тә, туй җырлары Келәүле районы, Назаровка авылында яшәүче керәшен татарларында нык сакланган. Назаровка авылының борынгы исеме Кече Урдалы икән. Язып алынган риваятьләр моны дәлилләмәсә дә, авыллары турындагы борынгы халык җыры – «Урдалы буе» халык күңелендә саклана:

Урдалы урамы – озын урам
Почтовойлар үтә туктамый

---

[1] Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас. ФФ, колл. 77, п. 1, сак. бер. 1, 3 б.

[2] Шунда ук. ФФ, колл. 77, п. 1, сак. бер. 2, 1 б.

Урдалы буе
Әйдәгез, җырлашыйк әле[1].

Самара өлкәсенең барлык татар авылларында да түбәндәге солдатка, яисә армиягә озату җыры бик киң таралган:

Сызрань күпере сиксән такта,
Ничек санап үтәргә,
Туып үскән авылымны
Ничек ташлап китәргә.

Шулай ук тарихи һәм топонимик риваятьләр язып алынды, авыл тарихларына (Гали, Яңа Мансур, Иске Мәчәләй, Назаровка һ.б.) бәйлеләре шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үз тарихларына битараф булмаганлыкларының ачык мисалы. Самара өлкәсендәге татар авылларында чишмәләр бик күп, аларга бәйле риваятьләр дә бар, бигрәк тә халык күңелен дә, безнекен дә яулап алганнары: Похвистнево районы Гали авылындагы өлешлеләрдән (күрәзәче, изге зат) булган Морат бабкай чишмәсе, Камышлы районы Дәүләткол авылында үзәк өзгеч тавышларын калдырып, Озын тау чишмәсе куенына кереп югалып, ташка әверелгән кыр казлары, Камышлы районы, Иске Балыклы авылындагы тау башында челтерәп аккан Изгеләр чишмәсе. Бүгенге көннәргә хәтле Балыклы авылы кызларына тәрбияви чара булып торган Сыңар каен – ялгыз каен риваяте нык тәэсир калдырды. Ул каен бар, хәтта җыры да:

Тау буенда сыңар каен
Яфрак яра һәр яз саен.
Туганы юк, дуслары юк,
Берүзе яныкаем...[2]

Камышлы районы, бигрәк тә Иске Ярмәк халкының горурлыгы, шулай ук үзенчәлекле бию саналган – вак бию, аның риваяте, һәм шушы авылдан чыккан Зыя Ярмәки олылап язган Ак каен тарихы, каен үскән Юкәле тау – Әүлия турысы риваяте дә бар.

Мифологик хикәятләр – ияләр, җеннәр турындагы хикәятләр халык арасында борынгыдан сөйләнеп, яшәп килгән, халык аларга

[1] Келәүле районы Назаровка (Иске Урдалы) авылында 2014 елда Иванова Ульяна Степановнадан (1940 елгы) язып алынды.

[2] Камышлы районы Иске Балыклы авылында 2014 елда Йосыпова Венера Кәрм кызыннан (1953 елгы) язып алынды.

ышанган, буыннан-буынга тапшырган. Татар халкында аеруча киң таралганы – атның ялын үрүче йорт анасыннан (абзар иясеннән) башлап, мылтык белән атып кына котылып була торган Сәгирә әби, Зәмзәмияләргә ияләшкән шайтаннар турындагылар.

Халык уеннары – нигездә барлык татар халкы өчен хас уеннар язып алынды: түгәрәк уены, «Унике таяк», «Лапталы», «Ал тирәк, күк тирәк». Алар белән беррәттән, аулак өйләрдә традицион уйналып килгән «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар. Камышлы авылында ял көнне (революциягә кадәр җомга, ә соңрак якшәмбе базар көнне) якын-тирә авыллардан кызлар, егетләр, яңа өйләнешкәннәр кырга чыгып, «Мүкле күл»дә «Каршы уен» оештыра торган булганнар, аның тарихы һәм «Каршы уен җыры» көе һәм сүзләре белән язып алынды. Әлеге уен үзенә күрә бер йола ролен үтәгән – күп яшьләр өчен танышу чарасы булган.

Әкиятләр жанры соңгы елларда бөтенләй очрамый башлаган иде һәм, ниһаять, Самара өлкәсендә безгә дүрт әкият һәм ике алдавыч әкият язып алырга насыйп булды – халыкның күңелендә әкиятләр яши икән әле. Дүрт әкиятнең берсе хайваннар турында, без аны Кәҗә белән Аю бабай дип атадык, өчесе мифологик һәм тылсымлы әкиятләр. Шуларның берсе 1973 елда Татарстанның Апас районы, Урта Балтай авылында Әлфинур Хисамовадан фольклорчы Л. Җамалетдинов язып алган, китапта басылган «Бет тиресе»[1] әкиятенең варианты, ләкин бу юлы язылып алынганына мифология элементлары килеп керә. 1965 елгы экспедиция вакытында Самара өлкәсе Келәүле районы, Балыклы авылында Х. Гатина тарафыннан ике әкият язып алынган булган һәм берсе басылып та чыккан[2].

Бу юлы мөнәҗәтләр бик аз булды. Алар арасында татар халкында еш очрый торган «Раббым Алла, диде Муса», «Сабак уку», мөнәҗәте, «Бүз егет» дастаныннан бер өзек язып алынды (мәнәҗәте белән). Әйтик, гомере буена «бисмилла»сы булган «Сабырлык» мөнәҗәте (әбисе Фатыймадан өйрәнгән) Яңа Ярмәк авылында Гафурова Гөлсинур Шәйхрази кызыннан язып алынды.

---

[1] *Җамалетдинов Л.* Әкиятчәләр төбәге // Милли-мәдәни мирасыбыз: Апас. Казан, 2011. Б. 320–322.

[2] Мөгезле патша // ТХИ. Әкиятләр. Икенче китап: Татар. кит. нәшр., 1978. Б. 330–331.

Похвистнево районындагы Иске һәм Яңа Мәчәләй авылларында, Мансурда яшәүче татар-мишәрләрдә Раштуага бәйле ышанулар, Курку куу, кан басымын төшерүгә бәйле ырымнар да бар. Бәетләр бөтенләй очрамады.

Самара өлкәсенең Похвистнево, Камышлы, Keләүле районнарындагы татар авыллары җирлегендә язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә) тәкъдим итәбез.

**Авыллар тарихыннан**

(*риваятьләр-легендалар*)

**Красный мост авылы.** Шушында күпер булган, аны буяганнар кызылга. Шуңардан Красный мост язганнар. Аны кызыллар ватканнар. Аннан ары икенчене төзеделәр биек иттереп. Монда вич заливать итәдерие. Йолдыз дигән поселка бар. Шуннан көймә белән утырып киләдериек. Хәзер биш ел булганы юк ташуның. Хәзер дүртенче күперне салдылар. Сауруш дигән елга, каядыр бер авыл булган, шуннан чыккан ахрысы. Аны чапайлар заманында яндырганнар, кызыллар белән аклар сугышканда. Минем абзый барие. 1927 елны ул теге авылдан Галидән күчеп килгән. Аныңчы булмаган.

*Красный мост авылында Вакказов*
*Хәлимулла Мөхәммәт улыннан (1927 елгы)*
*язып алынды*

**Гали авылының чукындырылмый калу тарихы.** Әткәйнең сүләгәне хәтердә. Иван Грозный вакытында чукындырып йөргән вакытта безнең бабайның атасы Габделатыйф исемле бабай бик таза кеше иде. Мин генә инәйгә охшап бик бәләкәй. Пләмә (*племя*) дә зур бит, Латыйповлар инде безнең. Шушында: җәмагать, җаным шәһитләрдән китсен, мин боларны дип әйтте дә, ди, чалам хәзер. Атка утырган чукындырып йөрүчеләр монда. Хәзер чалгы-пычак, ди, зур, ясалган пычак, ди. Акыра, ди, бабай суям дип әйтеп, тегеләр тәрәзәдән чыгып качалар.

Тегеләр:

– Ни дип әйтә соң ул?

– Сезне суярга барам, дип әйтә, ди.

Шушыннан болар атларына утырып чыгып качалар. Менә шушыннан Гали авылы котылып кала шушы чукындыручылардан.

Менә безнең бабай безнең историягә дә кергән. Минем бабай Габдерәүф аны Миңнекәй дип йөрттеләр, аның атасы Габделатыйф бабай, аныкы Миңнегаис булырга тиеш. Шушылар Аллаһының бер әмере беләндер инде шушылай чалгы-пычак белән куып, тегеләр чыгып кача авылдан.

**Морат бабкай чишмәсе**. Тау буеннан кайткан вакытта шушында килеп көрәк беләнме нитә шушыннан чишмә бәреп чыга. Морат бабкай өлешлеләрдән була ул. Аллаһның әмере белән алдагы киләсен дә белә. Ул бит менә Ислам динен бик нык кысрыклаган вакытларга туры килә. Син, диләр, бабай, диләр, нигә болай иттереп йөрисең кешеләрне бутап, тегендә төпкә чакырталар, тегеләрдән допрос ала башлыйлар. Морат бабкай бер стакан су сорый. Тегеңә су салып бирәләр. Бу бабай эчә, дип уйлыйлар ахрысы. Ә ул ала да өстәл астына түгә. Нигә түктең, диләр?

– Ана, шушында янәшәдә авыл шунда пожар, сүндердем – ди.

Чыннан да хәбәр килә тегендә пожар дип. Менә Аллаһның әмере, өлешлеләрдән була. Нинди изге кеше булган шушы Морат бабкай.

– Алай булгач, бабай, бар кайт, – диләр тегеләр дә.

Халык борынгы Морат бабкай чишмәсенә барып йөрмәсен дип, икенчерәк җирдән чокытканнар иде чишмәне.

Шушы бабкай чишмәсенә без яшь вакытта ата-абзыйларым, бер аксак бар иде, җыелдык та атлар белән кайтарып, бура бурадык: 5,5×5 метрга икешәрләп, тимер рәшәткәләр утыртып бораулар белән борып утырттык. Моңа бер 50–55 еллар бар инде. Шушыннан соң мондагы халык Бабкай чишмәсе – изге чишмәдән суын алып кайта, чиста тәмле су. Бездә бер Гилязев Гизаметдин дигән кеше бар иде, мәктәп директоры да булып эшләде ул. Шушы Бабкай чишмәсенең өсте ягына бу хәзер безнең тимер рәшәткәләрне алдырды. Менә әле Бабкай чишмәсенең өске ягына чишмә казытты, моны изге чишмә дип әйтмәсеннәр, дип. Шушы өстәге чишмә сасып торды, бусы чип-чиста ага. Тегесе томаланып бетте. Хәзер инде теге өйне минем агай-энем тиешле Багаутдиновлар ясатты.

Чишмәбез зәм-зәм суыннан аз гына калыша, шундый чиста. Без апкайтып куябыз бер ел торсын – тәме дә үзгәрми.

*Гали авылында Латыйпов Госман*
*Габдрәшит улыннан (1943 елгы) язып алынды*

**Яңа Мансур авылы.** 1787 елгы мәчет клуб каршында. Манараны төшермәделәр. Аны Аллаһы Тәгалә саклап торган – изге мәчет. Авылның тарихын мәчет төзелү вакыты белән алырга мөмкин, диделәр. Теге астагы урам иске йортлар дип атала хәзергесе көндә. Анда ниндидер кавем килеп яши башлаган. Аннан алар каядыр киткән, дип сүлиләр иде. Аннан мукшылар килә, теге очта. Иске Мансур дигән авыл бар, ул бетте инде хәзер, анда аз гына калды. Анда татарлар да булган. Булган удмуртлар. Безнең авылда шуннан калган бер потомство бар. Бухари кавеме – Бухарметовлар. Ул минем җәмәгатемнең әтәсе дә шунда туган булган. Мәдрәсәгә безнең авылга җөрегәннәр. Аннан ул мукшылар 1930–1932 елларда моннан 10 чакрым ераклыктагы Ильгиновка поселкасына күчәләр. Бер мукшы да калмый. Ул поселка 1968 елдан алып 1970 елга хәтле ликвидировать ителә. Безнең авыл зураеп китә.

*Яңа Мансур авылында Шияпов*
*Исхак Хәсән улыннан (1932 елгы) язып алынды*

**Яңа Мансур авылы.** Без торган урамны, мукшы урамы, диләр. Авылда ике мәчет бар. Элек безнең әтиләр заманында дүрт булган авыл башындагы мәчетнең манарасын кискәннәр, аны клубка әйләндергәннәр иде. Хәзер кая мәктәп күргәнсездер, анда тагы бер мәчет булган. Клуб буендагы (хәзерге) мәчет торган, аңа тимәгәннәр. Шул бер мәчет калган. Мәктәп янындагы мәчетне мәктәпкә әйләндергәннәр. Ике Мансур авылы бар. Берсе – Иске Мансур. Анда мукшы халкы тора. Ә бусы Яңа Мансур. Яңа Мансурда татарлар яши. Безнең очка «мукшы» дигәннәр. Минем әби Иске Мансурда туып үскән, аның яртысы татарлар, яртысы мукшылар булган. Минем әтием шул мукшы малайлары белән бергә үскән. Бик дус яшәгәннәр, авыл гына елдан ел сүнә барган. Аннан Иске Мансурда мукшылар калган, Яңа Мансурда – татарлар. Ә беренче Иске Мансурга Мансур дигән кеше, ә безнең авылга аның браты килеп караган, урыны ошаган, монда урнашкан. Икенче потомство яшибез без мукшыдан соң. Без бала вакытта Гайсаровларның кайда таулары, анда аларның каберлекләре бар иде. Без бала вакытта шунда аз гына җирне казып акбур ала идек, өйләрне буярга.

Монда иске йортларга каяндыр башкортлар килеп урнашкан. Никтер, авыл халкы аларны өнәмәгән. Елганың теге ягында

керәшеннәр дә булган. Хәзер авылда Ильясовлар, Казаковлар, Губеевлар шулардан калган нәсел. Ә бу башкортларны кыерсытканнар, үзара сугышканнар. Алар бер көн төялешкәннәр дә атларга, качканнар. Ә керәшеннәрнең нәселләре һаман да бар. Хәзер алар мөселман, дине кире кайткан. Мукшылар белән никахлар сирәк булган.

Авылыбызда өч чишмә бар. Берсе Петро чишмәсе. Аны Петр дигән кеше ясаган. Артта Ком чишмәсе. Күпме генә казысаң да һаман ком чыга. Ә урмандагы кечкенә чишмәдән су килгән, анда Николай дигән кеше буа буган. Аны Николай буасы диләр. Әле дә бар ул. Яшьләр шунда су коенып йөриләр. Мукшылардан исемнәре кушылган, һаман да шулай атала. Әдек чишмәсен татар ясаган. Әдек дигән борынгы исемле кеше.

*Яңа Мансур авылында Вагыйзова*
*Рафика Сәлим кызыннан (1933 елгы) язып алынды*

**Пәриле тау.** Ул менә шундый круто, аннан тигез бара, аннан тагы менә шундый круторак. Пәриле тау, диләр. Гел шуннан төшкәндә атлар белә арбаның тәгәрмәченә пүлән тыкканнар, шул пүләннәр сынып чыккан шул тауны төшкәндә. Пәриләр сындыра икән имеш. Тыгалар тормоз булсын өчен, ат дулап китмәсен, тәгәрмәчләр шуып кына төшсен, дип, ике тәгәрмәч арасына озын кура куялар. Шул кураны пәриләр сындырырга булышканнар.

**Саксар болыннары.** Анда элеккеге көтү көткәннәр. Саксар болыннары, дип атаганнар. Саксар – ерак дигәнне аңлата.

*Яңа Мансур авылында Фәхретдинов*
*Мөдәррис Миңнеәхмәт улыннан (1952 елгы) язып алынды*

**Назаровка.** Бу авылга Назар бабай нигез салган. Федотовкага – Федот, ул тегендә кырык чакрым ара – керәшен авылы. Назар бабай белән Федот икесе чыкканнар алар. Татарстанның Наратлы ягыннан. Федоты киткән Федотовкага, ә Назар бабай монда утырып калган. Безнең авылга пример 300 ел. не больше. Теге башта урыслар булган, иң башта чувашлар һәм монда керәшенәр, хәзер унбиш төрле халыктыр. Килгән кеше китәлми инде. Кызлар йә укытырга, йә эшкә киләләр дә кияүгә чыгып калалар.

**Үеләр чишмәсе** дип йөртәбез. Шуның суы инешкә – Урдалкага агып төшә. Урманның теге ягында Урдалы авылы бар, җә шун-

нандыр инде ул. Анда татарлар яши. Безнең су урыслар ягыннан килә. Петровкалардан әйләнеп Урдалыга бара. Түбән як буенда чишмә чыга иде, урталыкта. Хәзер, колонкага алданып, карамагач, бетте алар.

*Назаровка авылында Данилова*
*Анастасия Григорьевнадан (1939 елгы) язып алынды*

**Мулла елгасы** – бабалар цыгып намаз укыганнар, яңгыр яумаганда теләккә цыкканнар. Инеш инде ул. Менә иделәр теләк теләүгә. Сарык суя иделәр.

**Цалпан тавы.** Сәүбән исемле бабай бар иде. Гомере буе сөт җыйды. Алар шул тау төбендә яши иде.

*Иске Мәчәләй авылында Булатова*
*Шәмсыгаять Миргаз кызыннан (1930 елгы) язып алынды*

**Иске Мәчәләй.** Бу авылга 1857 елда нигез салганнар. Пенза ягыннан күчеп килгәннәр. Авыл мәцете манарасын дүрт көн кистеләр. Халык җыелды, елый. 2 урыс, 2 безнең авыл кешесе татар, картаеп үлделәр. Иң беренче Габделхәер бабай килә бер кеше белән. Аннан Габделгаббас улы. Монда бөтен җир урман булган.

*Иске Мәчәләй авылында Субеева*
*Рәкыйбә Локман кызыннан (1926 елгы) язып алынды*

**Яңа Мәчәләй.** Яфим чокыры, Бахау чишмәсе бар. Безнең Яңа Мәчәләй Иске Мәчәләйдән чыккан. 1905 елны күчеп килгәннәр. Җир сатып алганнар. Безнең бабай мельник булган. Монда җир сатып алган. Күчеп килгән Ногман бабай, Шакир бабай, Каюм бабай. Минем бабай Фатхулла.

*Яңа Мәчәләй авылында Фатхуллина*
*Разия Вашигулла кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

**Вак бию** риваяте. Рекрутка яшь егетләрне алып киткән чакта, аларның әзерлекләрен шулай тикшергәннәр: чыбыркы белән әйләндереп басып торганнар кругта. Егет, чыбыркы кире әйләнеп килгәнче, вакны бәреп өлгерергә тиеш булган.

**Юкәле тау** – изгеләр тавы. Анда каенга исемнәр язылган иде. Изге тау, дип әйтәбез, чөнки сабантуй үткәннән соң берәр начар

хәл була, шуңа күрә үзара уйлашып сабантуйны анда үткәрмәскә булдылар.

Юкәле тауны әүлия турысы дибез. Итәгендә бар иде ак каен. Ул картаеп ауды инде. Аңа сугышка киткәндә патша вакытында ук инде, солдатка киткәндә никрутлар шунда үзләренең исемнәрен язып калдыра торган булганнар, чокып, пәке белән. Менә шундый гадәт булган. Безнең заманда корыган. Мин 1974 елда мәктәпне бетердем, шунда чыга торган идек. Бөтен мәктәп тәмамлаучылар шунда чыга торган иде. Әүлия кабере, диләр. Нинди әүлия булган билгеле түгел. Кабере башта имәннән бура иде. Аннары соң инде тимер рәшәткә ясап куелды. Безнең мулла инциативасы белән Кәркәледән ташлар апкайтып утыртылды анда. Без үскәндә Юкәле тауга гел чыга идек. 1975 елда армиягә киттем. Анда язырлык урын юк иде. Корыган иде. Кайтканда ауган иде, аккан иде. Сукка төшереп җибәргәннәр дә ул агып киткән. Ул бик борынгы каен.

*Иске Ярмәк авылында Галимуллин Наил*
*Нәбиулла улыннан (1957 елгы) язып алынды*

**Җир-сулар.** Аю коесы. Бер 20 ел барган юк. Элек мин егерь булган идем.

Ярмәк белән ике арада Хәлил коесы бар. Ул трактор бригадиры булып эшләгән. Су ерагырак, ул казыткан кое. Сугыш вакытында. Тауның исеме бар. Ләкин аны бер кайда да белмиләр. Мин беләм: бусы Кәҗә тавы, Камышлыга кергәндә. Аннары Алтын тау диләр, анда кемдер алтын яшергәнме, чыкканмы. Сук елгасы. Суык су ул, северный районы, Оренбур өлкәсе. Шуннан башлана. Камышлинка, Боз баш суы. Авылдагы чишмә. Берсе Кара төп. Варлан чишмәсе – Варлан бабай казыткан. Салкын чишмә Дәүләтколга барганда.

Кырлар: Кыязлы, Туң каен, Түгәрәк туң каен, Гали кулы чокыры, астарак Зиратлы чагыл – тау исеме. Зиратлы чагылда каеннар северный якта. Шунда җирләгәннәр солдатларны. Аннан Чапаев та үткән булса кирәк. Чагыл – тауларны шулай атаганнар.

Көймә тау – читтән карасаң, каплаган көймә төсле тора. Зиратлы чагылга кем күмелгәнен белмим, кызыллармы, аклармы.

Боз баш авылы, өскә менәсең – Кара тал тавы – тау. Урман белән капланган. Кара тал матур була. Шуның кайрысыннан бабай

туннарны кызгылт төскә буйый идее. Байтуган авылынннан өстә Каравыл тауы. Аклар белән кызыллар сугышканда безнекеләр сакта торганнар шунда.

*Камышлы авылында Шәкүров Мөхәммәд*
*Зыя улыннан (1936 елгы) язып алынды.*

**Изгеләр чишмәсе.** Тау башында челтерәп ага. Таш белән ясалып куелган. Улак кебек тора. Кругом яшеллек. Матур каен үсеп утыра. Бер көннәрне малаем кайтты да бардык. Яңгыр яумады. «Ходаем, шушында килдек изгеләр чишмәсенә, эчтек, юындык, бир әле яңгырларны», – дип теләдек. Икенче көнне яңгыр яуды. Олылар барып шунда яңгыр тели торган булганнар, яңгыр ашы пешерәләр. Аннан тотынабыз чиләкләр белән, тәрәзәләрне ачып берәр чиләк сибәбез.

*Иске Балыклы авылында Билалова Хәтимә*
*Галим кызыннан (1942 елгы) язып алынды*

**Сыңар каен – ялгыз каен.** Бер Балыклы авылы кызы руска кияүгә чыга, поп малаена. Авырга калган, бәби тапкан вакытта үлгән. Аны авыл зиратына күмдермәгәннәр. Аны Сидякова белән Балыклы арасына күмгәннәр. Ул каен бар, сыңар каен, җыр да бар:

Тау буенда сыңар каен
Яфрак яра һәр яз саен.
Туган юк, дуслар юк –
Бер үзе яныкаем.

Ялгыз каен, ярлы каен,
Моңлы каен, зарлы каен.
Сиңа киләм сагышым белән
Илемә кайткан саен.

Синдә иске танышларым,
Бодайларым, арышларым.
Миләшләрем, баланнарым,
Хуш исле аланнарым.

Урманыңда сайрый кошлар,
Урамыңда җырлый кызлар.
Кичләрендә зәңгәр күктә
Кабына алтын йолдызлар.

*Иске Балыклы авылында Йосыпова Венера*
*Кәрәм кызыннан (1953 елгы) язып алынды*

**Риваять.** Дәүләткол авылының Озын тау чишмәсе. Бу чишмәнең үзенә күрә бер үзенчәлеге бар. Анда кошка охшаган ташлар бар. Кайчандыр чишмә буена ел саен кыр казлары туган якларыннан киткәндә дә, кабат кайтканда да туктаганнар. Бервакыт шулай хәлдән таеп кайткан кошларның әйдәп баручысын бер кеше атып төшергән. Ярга куна алмыйча озак әйләнеп очкан кошлар.

Инде тәмам азапланып, үзәге өзгеч тавышны калдырып, шушы чишмә куенына кереп югалганнар һәм ташка әверелгәннәр. Чишмә төбендә кошларга охшаган ташлар күп.

*Дәүләткол авылында Галиханова Зөлфия*
*Сәйфулла кызыннан (1959 елгы) язып алынды*

## Әкиятләр, дастаннар

### Бүз егет

Бер малай төннә төш күрә. Төшендә бер кызга гашыйк була, аны дусты Кәмән белән эзләп чыгып китәләр. Кызны табалар, хәзер никах укытырга, ди. Ярар, ди. Но безнең диндәге кеше булмый. Никах укыталар, туй вакытында җыелалар. Хәйлә кора кызның атасы: «Теге харам ризыкны бирәбез дә, исертәбез дә боларны, юк итәбез», – ди. Монда шушы Бүз егетнең Кәмән дигән дусы ишетеп тора. Туй барган вакытта теге Бүз егеткә шигырь белән әйтә:

«Боларның уйлары,
Язган уй, дусым,
Чык».

Шушы вакытта «чык» дип шигырь белән әйтеп бирә, тегендә иярләнгән атлар була, шушы иярләнгән атларның өзәнгеләрен Кәмән дусты кисеп чыга, ике атныкын гына калдыра. Сикереп атлана да малай китә. Моны куып китәләр хәзер, үтерергә дип. Куып киткән вакытта арттан берәү килә, ук ата. Кәмән ук ата да ташка барып керә, теге арттагы кеше дә ата ташка, керми. Башына суга: «Моның куәте минекеннән күбрәк икән аны җиңәрлек көчем юк», – ди, и китеп бара. Бу ук белән ата атылып яраланып беткән булла. Барып хәлсез бер бакчага егыла да су кебек агып ята. Шушыннан соң ничек төзәтергә инде бу раннарны, тота да бер баканы яралы җиргә куя. Бер бөҗәк килә дә шушыны лечить итә үзенең селәгәе белән. Күпмедер вакыт үткәч чыга, караван үтеп бара. Караван Шамга кайта, ди, бу үзе дә Шам ягыннан була. Боларга ата-анасыннан мөнәҗәт белән әйтеп җибәрә сәламнәр:

Исән-аман кайткайсыз,
Атам-анам күргәйсез,

Бездән сәлам әйткәйсез,
дип утыра иде әткәй.

*Гали авылында Латыйпов*
*Госман Габдрәшит улыннан (1943 елгы) язып алынды*

**«Үз кызым» әкияте**

Борын-борын заманда бер бабайның бер кызы булган, ди. Бабайның карчыгы үлгән. Кызы белән генә калган. Икәү гомер иткәннәр, кыз үсеп җиткән, җиткән кыз булган. Эте булган, ишәге булган. Ә бабай инде бик эшчән дә булмаган, бурычка бик күп кергән күршеләргә дә, авыл советына да. Ә кыз артык сабыр, акыллы, бик чибәр булган. Күз төшмәгән кеше булмаган моңа. Хәзер бер көнне авыл советы башлыгы, күрәсең, яшь булган:

– Бабай бурычларың да бар икән, бурычларыңны барын да каплыйм, кызыңны миңа бирәсең инде.

Ничек инде бирмисең администрация башлыгына.

– Бирәм-бирәм. Әле инде җиткән кыз хәзер. Мин хәзер үлеп китәрмен, бала да анасыз үсте инде, атасыз да калып, җәтим калмасын. Үзем исән вакытта башкарырмын, ризалыгым бар, – ди бабай.

Кызның чибәрлеген ишеткән дә район администрациясе килгән.

– Бабай, дигән, синдә бик чибәр кыз бар икән.

– Ә мин бит инде аны, дигән, авыл администрациясенә ышандырдым.

– Попробуй, дигән, миңа бирмичә, аңарга бирергә. Әле дә бурычларыңны, әллә нинди гаепләр табып, үзеңне әллә кая сөргенгә озатырмын.

Аннан инде сүз китә ди, областной администрациягә хәтле бу кызның матурлыгы, чибәрлеге барган. Ансы килгән.

– Эй, улым, дигән, ышандырган идем бит инде район администрациясен.

– Попробуй, дигән, миңа бирмичә районнныкына бирергә.

Ә үзе атна кичкә барысына да сүз биргән. Ни була, шул була дигән. Аллаһы Тәгаләдән сорармын инде, шәт аралар үземне.

Иртәнге намазны укыган да атна кич. Инде белгәннәрне сорапсорап Ходайдан, кыйблага карап ялынып-ялынып сораган «Коткар инде бу бәладән дигән. Болай да гомерем ялгыз үтте, җәтим бала үстердем, рәхәт күрмәдем, коткар инде». Обедка таба ишәген дә,

этен дә, кызын да япкан да куйган келәтенә. Хәзер берсе килгән авылныкы. Эй, Раббым, дигән, нишлим, кертеп бирәм, тегеләр үтерсә үтерер, ди. Ходай җәлләгән моны. Өчесе дә кызлар, ди, өчесе дә бер төсле, ди, бертөсле киенгән, буйлары да бер. Бабай үзе дә аермый икән кайсысы үз кызы икәнлеген. Тоткан да берсен биреп җибәргән авылныкына. Аннан обедтан соң бер-ике сәгатьтән соң килгән районныкы, ансына да биреп җибәргән. Областной кичкырын килгән, аңарга да биреп җибәргән. Хәзер бабай ялгыз калган: «Эй, Раббым, хәзер кайсында балам, хәзер белмим инде» – дигән. Киткән бабай хәл белергә. Хәзер областнойга барган.

– Улым, дигән, ничек хәлләр, ризамы син кызым белән, ошыймы сиңа, кайсы яклары ошый, кайсы яклары ошамый? Мин инде ана булмагач, җиренә җиткереп тәрбияләмәгәнмендер инде.

– Бабай, эшли, чибәрлеге дә матур, мона килешеп тора үземә, ләкин лау-лау, син моны болай эшләдең, нигә аны алай эшләдең, аны болай кирәк булган... Шаулый да йөри.

Әхә, бу көчектән узган икән. Хәзер ни, районныкына барган.

– Улым, – дигән, – ну ничек кызым (бабай аңа кайсы кызы эләккәнен беләсе килә).

Бабай, кызың рәттән эшли, ә берәр кая йомышка җибәрсәң, эзләп алып кайтмыйча, кайтмый, – дигән.

Анысы ишәк.

Авылныкына барган.

– Ну, улым, ничек кызым?

– Мона килмәгән җире юк инде, – дигән. – Ничек кенә бу хәтле тәрбияли белдең. Йөрүеме, киңәшеме, ничек бәяләргә дә белмим, – дигән.

Ә, бусы үз кызым икән, дигән бабай.

Өч төрле категориядән хатын-кыз яралган: бер төрлесе «Әх!» (бөтен яктан да килгән, бик шәп мәгънәсендә), бер төрлесе чыгып китеп кайта белми, бер төрлесе лау-лау өрә дә тора, ди.

**Бет тиресе**

Борын-борын заманда Патша булган, ди. Патшаның хатыны булган, кызы булган. Кызы бик чибәр булган инде. Хәйран калмаслык кеше булмаган. Аның йөрегән, яраткан бер егете булган. Ә патша кеше шул кызына бүләк биргән. Кызының өч аты булган. Берсе –

чирләшкә, корчаңгы, бөтенләй иелеп беткән, икенчесе – уртача хәлдә, ә өченчесе инде, ах, ярсып йөри торган ат булган. Ә ярсып йөри торган аты кеше сөйләшкәнендә аңлаган икән. Гел киңәшә икән, мона шуңардан нишлим икән, менә шулай эшлә, болай эшлә, дип киңәш бирә икән. Кызның йөрегән егетенең дә ак аты булган. Инде бик тату йөргәннәр болар. Мона өйләнешергә йөриләр икән. Атасы әйткән беркөнне: «Шундый сорау кузгатырмын, шуны кем белер, шуңа кызымны бирермен».

Хәзер беркөнне патша йоклап ята икән. Йоклап торуына аркасы кычып киткән. Уянып китсә, артында бер бәләкәй куян баласы хәтле бет, ди. Хәзер моны алган да, куян хәтле булгач, тиресен тунаган да, тыгып куйган. «Кем, – дигән – шул тирене таный, нәрсә тиресе икәнлеген шуңа бирәм». Белдерү язганнар инде. Анда аксагы да, бер күзлесе дә, әх дигәне дә килә, акыллысы да килә, акылсызы да килә. Белмиләр, бет тиресен кем белә инде.

Хәзер бу кыз күпер аша чишмәгә суга, бара икән. Күпер өстеннән чыкканда сөйләнә икән:

– Эх, нинди егетләр килә, кайсыларына үзем дә күз төшерәм, үз егетемнән дә әйбәт егетләр бар.

Борылып китәләр, белмиләр шул, бет тиресен каян белсеннәр инде. Ә күпер астында икән пәриләрнең оялары. Шундый зур тишек, тишектән кереп киткәч анда пәри шәһәре булган. Ә пәри патшаларының малае өйләнергә йөри икән. Бәләкәй генә күзле, кәкре аяклы, ди. Теге кыз:

– Карале, киләләр, китәләр, берсе бер белмиләр, бет тиресе бит белмиләр. Эх әйтеп булмый бит, кайсыларына кызыгам карап торып, – дип үзенә үзе сөйләнә икән.

Теге пәри малае ишетә дә чакш-покш китә таягына таянып, берсе – култык таягы, берсе – мондый таяк.

– Ә мин, дигән, беләм нәрсә тиресе икәнлеген, бет тиресе, дигән.

Ә патша:

– Минем әйткән сүзем дигән, хет әллә кем булсын, хет елан-аждаһа булсын, әйттем беттем, бирәм дигән.

Пәри малае патшаны «уп» иткән, өч көн, өч төн аңсыз яткан патша. Акылына килгән дә:

– Төшемме булды, чыннан да көндезме булды, чыннан да пәри малае белдеме?

– Белде.

– Ну, вәгъдә. Бирәм инде кызны.

Сүз куешканнар кайсы көнне килергә. Пәриләрнең патшасы – малайның атасы килгән.

– Вәгъдәдә тора торган кеше, диләр Сезне, нәрсә эшлисең?

– Авырсынам да, бирәм инде, нәрсә эшлисең.

– Кайсы көнгә ясыйбыз?

Сөйләшкәннәр. Монда килгәннәр туй ясаганнар. Пәриләр – бер бүлмәдә, кешеләр икенче бүлмәдә утырганнар. Бер көнне киленне төшерергә хәзер үзләре төсле ямьсез арбалар, иске себеркеләр белән, кызны алырга килгәннәр. Теге кызның өч аты бар бит. Берсе – кешечә сөйләшә торган. Кыз барган да:

– Нәрсә эшлим? Үземне үзем юк итимме, сугамы төшеп үлим микән? Ничек барырга кирәк? дигән.

– Ризалан, – дигән аты. – Атаңа да бер сүз дә әйтмә. Җайларбыз.

Хәзер кызны алырга килгәннәр, очы-кырые да юк, ди, пәриләр килгәннәр кыз төшерергә. Хәзер күпер төбенә килгәннәр дә:

– Син бит кеше баласы, сине алдан кертергә кирәк, – диләр икән.

Аты әйтә икән:

– Син алдан кермә, артка кал. Бар да кереп бетсеннәр. Аннан мин сиңа әйтермен нәрсә эшләргә.

Хәзер тулганнар-тулганнар тишеккә. Әллә кая эчкә кереп китәләр икән. Кияү белән кыз гына калганнар. Кияү әтә ди:

– Син кер.

Ат кызга әкрен генә әйткән:

– Син алдан кермә.

Кыз әтә, ди, кияүгә:

– Син кер. Синнән алдан керсәм, ирне санга сукмаган кебек булам, – дигән.

Хәзер кияү алдан кергән. Ат типкән дә теге чирле атны, тишеккә кереп киткән чирле ат. Шайтаннар монда чыга алмыйлар, ә кыз бу якта калды. Тишек – кызның икенче атының гәүдәсе белән капланды. Кыз сөйләшә торган атына атланган да, киткәннәр далага. Чапканнар, чапканнар, чапканнар. Ат та арыган, кыз да арыган. Әзрәк ял итеп алыйк, дигән. Болын, җиләкләр. Ат та ашап алган, кыз да капкалап алган, су эчкәннәр, ятып йоклаганнар, хәзер уянганнар да:

– Безнең арттан килмиләрме икән? – дигән ат. – Син тыңлап карале.

Ятып тыңлаганнар. Кыз әткән:

– Бер тавыш та ишетелми, ахыры эзләргә чыкмадылар.

Ат тыңлаган да:

– Киләләр, – дигән. – Атлан, давай киттек. Ә юлга киткән вакытта өч әйбер ал: тарак, су, таш.

Бара торгач, ат кызга тиз генә суны ташларга кушкан. Сипкәннәр, бөтен дөньяны су баскан. Шайтаннар бар да йөзә белмиләр икән, ди. Кайсы чума, кайсы егыла. Башлыраклары калган күрәсең, ә күбесе батып үлгән суга. Тегеләр чапканнар, чапканнар, чапканнар. Тагын ятып йоклаганнар. Хәзер уянганнар, ат әйткән:

– Тыңла әле, килмиләрме?

Кыз тыңлаган, «Тавыш ишетелми», – дигән. Ат: «Үзем тыңлап карыйм, – дигән. – Күп түгел, киләләр, байтак киләләр. Хәзер син тарагыңны ташла». Кыз таракны ташлаган да урман барлыкка килгән. Шул хәтле тыгыз-тыгыз үскәннәр икән, араларын узып йөрерлек түгел. Пәриләр чыгалмый, кайсылары өстән үрмәләп-үрмәләп чыга икән, пәринең көчлесе дә бар бит аның. Кайберләре кысылып башы калган, кайсының аягы кысылып калган, күбесе калганнар шунда. Тагы чапканнар, чапканнар, чапканнар. Тагы ятып йоклаганнар. Уянганнар, кыз тыңлап караган, тавыш ишетелми, ди. Ә ат тыңлаган: «Киләләр, – дигән, – күп түгел, киләләр. Хәзер ташла ташыңны». Таш стена барлыкка килгән. Пәриләр менәләрменәләр икән, тәгәрәп төшәләр. Бүтән барырга юл калмаган. Хәзер барып чыкканнар бер ачыклыкка. Бик матур урын, зур аланга, сәхрәгә чыкканнар.

– Хәзер син мине суй инде – дигән ат.

Кыз җатып җыларга тотынган:

– Бөтен таянычым син, – дигән. – Атам юк, анам юк, егетем юк, каядыр адашып калдылар бар да. Сине дә суйсам нинди кызыгы кала дөньяда?

– Ә син суй, эчемне ю да тапа, күпме хәлеңнән килә, шул хәтле ераклыкка тарат, – дигән. – Ә үзең, минем тушкама кереп җат та йокла, гәүдәмә – эчкә.

Кыз елаган-елаган да, суйган. Эчәкләрен юып, таралткан күпме хәленнән килгән хәтле, Ходайдан сораган инде:

– Каян миңа тагын ярдәм булыр икән, иң якын дустым – атым да юк хәзер.

Аннан тушканың эченә кереп ятып йоклаган. Күпме йоклаганын үзе дә белми, арыган инде. Атнамы йоклаган, аймы йоклаган. Берзаман күзе йомык, йоклап ята икән, әтәч, кеше тавышлары, атасы белән инәсе тавышлары ишетелә. Хәзер күзен ачып җибәрсә, койкада ята икән. Анасы өстәл әзерләп йөри, ә атасы белән теге ак атлы кияве сөйләшеп утыралар, ди.

– Вот кызым, без дә күп күрдек, сине югалттык, күп хәсрәтләр кичердек.

– Мин дә, – дигән кыз, – зур хәсрәтләр кичердем, яраткан атымнан да калдым. Ходай шулай кушкандыр.

Шәһәр икән, сарай, атасы шунда, анасы шунда, кияү килгән сорарга. Атасы ат әзерләгән, икесе дә пар ак атлар белән. Атлары чыгып киткән дә һаман да торалар, ди. Өй тулы балалары, оныклар, ди.

*Яңа Мансур авылында Вагыйзова*
*Рафика Сәлим кызыннан (1933 елгы) язып алынды*

**Әкият**

Борын-борын заманда бер кеше яшәгән, ди. Көннәрдән бер көнне ул өйләнә икән. Хатыны ире нәрсә сүли, шуны кирегә сүли. Бу ир ялыккан хәзер. Урманда була бер тирән кое, шуның өстенә чыбык-чабык ыргыткан да кайтып әйткән хатынына:

– Карчык, – дигән, – анда барма, анда тирән кое бар.

– Син инде шулай йөрерсең. Барам да төшәм – дип әтә, ди.

Бара да гөмберт коега.

Бу куанып кайта икән:

– Ну, – дигән, – заразы, минем синнән котылуым.

Бер атна узмый, бер бай кеше белдерү яза: «Кем минем кызны коткара шуңа бик күп алтын, бик күп акча бирәмен».

Тегендә, коеда, бер елан булган, чыдый алмаган теге хатынга, чыккан да бай кызының бүнә (*муенына*) уралган, ә ашаганда икән теге кыз нәрсә ашый бу да – змей дә шуны ашый икән.

Бу кеше барган да:

– Теге коедан чыккан хатын сине эзләп йөри, ычкын, ату анаңны өшкерә дип әйтә, ди, еланга.

Елан сүтенеп бу бай кызының бүеннән диңгезгә чумган: бултых! Теге кеше акчаны алып кайтып киткән.

*Яңа Мансур авылында Карилов Рәхимҗан*
*Сәлимгәрәй улыннан (1935 елгы) язып алынды*

**Кәҗә белән аю бабай**

Борын-борын заманда бер кәҗә булган. Аның ике баласы булган. Ике баласын имезгән дә киткән үзенә азык эзләргә, эткән кәҗә балаларына:

– Бер кая да китмәгез, изән үзәгенә, ишек төбен элегез, үдә генә утырыгыз.

Әле аю бабай килә дә (ерлап):

Кырдан кырга йөрдем,
Кыр емеше китердем.
Ачыгыз, балалар, ишекегезне.

Болар ачмыйлар. Берсе диван артына утыра, берсе пиш (*пич*) бас өстенә менеп утыра. Болар ацмыйлар. Аю бабай алай да тәрәзәдәнме килә дә керә дә, боларны ашый, бу балаларны ашый. Ашап бетмәгән берсе генә кала. Кәҗә азык эзләп катя, катца бер баласын ашаган аю, берсенең нәрсәләре генә калган. Кәҗә утырып елый.

Аннары аю бабайны барыбер ашка чакыра:

– Адя, мина цәй эчәргә.

Моннан идәннең такталарын ала, палас яя дә аска ут яга кәҗә. Аю бабай килгәч:

– Аю бабай, айдя түргә уз.

Аю бабай түргә уза да, базга төшә дә китә:

– Алла-ла-ла, башым пеште, башым.

– Ә, минем балаларның башын ашаганда яхшы иде, – ди кәҗә.

– Алла-ла-ла, аякларым пешә.

Шулай итеп аю бабайны яндырып үтерә кәҗә.

*Иске Мәчәләй авылында Исхакова*
*Миннехәят Әхмәдулла кызыннан (1929 елгы)*
*язып алынды*

**Мифологик хикәятләр, ырымнар, ияләр, җеннәр турында**

**Йорт анасы** бар кем ат тота. Атлар алып кайталар иде калымга баралар да чувашларда эшлиләр дә. Чуваш атларын татарга бирә дә ебәрә инде хак куеп. Безнең бабай алып кайткан атларны, берничәне. Чәч үргән кебек үрде. Яратканга үрә, – дия иде бабай.

Йорт анасы малны яратмаса, ул мал иртән чыгып карасаң өстеннән шабыр тир ага дия иде.

*Яңа Мансур авылында Карилов Рәхимҗан Сәлимгәрәй улыннан (1935 елгы) язып алынды*

Безнең авылда **җен** алмаштырган, дип әтәләр иде. Чирле бала туган. Үсә башлый – безнеке тегел. Ул исән тегелләрне икене тапкан. Ул эткән, җен алмаштырган, дип.

*Иске Мәчәләй авылында Бахтеева Разия Әхмәдулла кызыннан (1946 елгы) язып алынды*

Элегрәк бик күп сүлиләр иде: «Бу эшне эшләргә йорт анасы риза булырмы? Сыер сатып аласың, если ошатмый йорт анасы, мәсәлән, төсен, кызыл кирәк бу йортка, ә син китерәсең караны. Иртән чыгып карыйсың: әгәр өсте тирләгән, значит, йорт анасы аны кыйнаган. Әтиләр бу йорт анасына ошамаган, дип, суялар йә саталар. Мәсәлән безгә агы да, карасы да булмасын, кызыл сыер гына бара. Гел кызыл сыер гына алдык та.

**Җеннәр** бар. Оланнарны элек ала торган булганнар. Корсаклы хатыннарны. Әниләр сөйли иде: төшәләр икән бәкегә, керләр цайкарга. Кышын. Шайтан килә дә таптыра. Хатыннар кайта өйләренә корсаксыз.

**Ире диеп, шайтанны ашаткан.** Сәгирә әбинең ирен военный алып китәләр. Ул башка еңеләя инде. Алар тугыз олан була. Бу постоянно безнең этигә этә: кемгә дә братыма әтмә, езнәң катып йөри, аранда, Сәгирә әби постоянно аран башына ташый.

Әти минем:

– Езни сугышта калды, үлде. Бу нинди езни инде. Бу шайтан, – дигән.

Кеше күрмәгәндә менә аран башына, аннан ашата төшә. Әтием карап тора, ул аның апасы була.

Сәгирә әби әтә икән:

– Ул аран башында әтмәгез военныйларга, ранин кайтты, дип.

Бер кат сыный, икенче кат, өченчесендә мылтык белән төшә. Әти мылтык белән аткан.

Сәгирә:

– Ах, езнәңнең аягына тидердең.

Тагын аткан.

Сәгирә:

– Үтердең, дошманым булырсың, – дигән.

Сәгирә әбинең ире булып күзенә күренгән. Шулай итеп, Сәгирә әби, езнәгез кайтты сугыштан, кемгә дә әтмәгез, дип, шайтанны ашаткан.

**Шайтан иядәште.** Зәмзәмия әби чакырды, сүли: аяк асты утырган ир кеше, мине каядыр чакыра, ди, үтерергә чакыра, ди. Зинхар син аны ку, ди. Наилем белән бара идем дә, әт Наиленә, ят сүз белән сүксен, сүксәң китә, ди, теге малай минем алдында ояла сүгенергә. Аннан безнең әти кереп атты мылтык белән.

Әти:

– Кая, кая? – ди.

Зәмзәмия әби күрсәтә:

– Менә, угылда.

И доңгырт, әти атты. Тозмы, нәрсәме куялар да, чтобы тавышы чыксын. Шайтан курыкты.

**Ырым. Кан басымын төшерү.** Әгызү билләхи......рахим. Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы. Яулыкны боруын борам да, аннан бирерсең инде матур яулыкны. Бу әллә каян килгән күцтәнәцләр инде, әстәгафируллах, личить итәм инде. Шулайга борып куямын (яулыкның бер ягын) давлениең бетсен, ярабби, Ходаем исәнлегеңне бирсен! Амин, ди авыру.

*Иске Мәчәләй авылында Исмәгыйлова Асия*
*Ильяс кызыннан (1957 елгы) язып алынды*

Ул бит, Зәмзәмия әби Кыямнан куркып шулай булды, теге исерек кергән дә куркыткан. Элеккеге әбиләр курку коя, дип әтәләр иде.

**Курку кою.** Савытка салалар су, аннан соң жирный мал эченнән чыга май, Шул туң майны салалар да, кешенең исемен әтәләр, Бервакытны шул суга салдылар туң майны да, шул күршедәге Кыям булып, рәсеме чыкты. Ул аны куркыткан булган. Шул мужикны китереп, әбине өшкерттеләр. Гырмай әби (Асия апаның әбисе) куркуын койды Зәмзәмия әбинең. Суга туң май салды да, шул суына-суына Кыямның рәсеме килеп чыкты. Бер стакан туң май кирәк. Шуны кайнатасың, туң май килеш түгел. Аннан салкын суга саласың кипяток майны. Рәсем чыга.

Балаларыгыз курыкса, башына утыртасың, бусагага утыртырга кирәк андый кешене. Баш өстенә савыт куясың и саласың башка тимәскә тиеш.

– Бу балага ни булган?

– Курку булган.

– Кемнән курыккан?

– Фәлән кешедән курыккан, – дип исемен әйтәсең.

Вот шундый **ырымнар** бар. Шайтан әби утырта иде башны. Күздән корымнар сөртә иде, боргалый. Әле давление. Әле шул әби безне утырта да, кайнамны бик нитә иде. Кайнатам әтә иде: «Әй, хирургыңа киттең инде, бар, лечить ител. Кайнам бара да, Шайтан әби башына болай урый, тегеләй урый. Дүрт якка корым сөртә: биткә-биткә, чигәгә-чигәгә. Яулыкны бора (скручивает). Карый: кайсы якка ауган, тигезли, бу якка, бу якны тота да, бора-бора да и яткыра. Корым сөртелгәч, яулык бәйләгәч күренә: кайсы якка ауган – аны корым күрсәтә. Ауган якны борып-борып яткыралар. Шуннан терелә давлениедән. Әле ул бетте. Хәзер таблетка эчәбез.

*Иске Мәчәләй авылында Исхакова Миннихәят Әхмәдулла кызыннан (1929 елгы) язып алынды*

### Ышанулар, йолалар, гореф-гадәтләр

**Карга боткасы.** Карга боткасы ясыйбыз. Күптәннән килә. Самоварлар белән чәй куябыз, каргаларга улаклар куябыз да. Үзебез ботканы ашыйбыз, аннары калганнарын каргаларга салабыз, каргалар урожай китерсен инде канатлары белән, дип. Ботканы клуб артында пешерәбез. Карга боткасы көнне ризыкларны оланнар җыя. Кайсы ярма бирә, кайсы нәрсә, шигырь әтәләр:

Әби, зинһар, чыгар кукай,
Син уңган түтәй.
Ашлыклар уңсын кырда...

*Яңа Мансур авылында Фәхретдинов Мөдәррис Миңнеәхмәт улыннан (1952 елгы) язып алынды*

**Зәңки бабаларга**, нәнем, садакалар бирәбез. Зәңки баба – хайваннарныкы. Җиде анабыз, җиде атабыз дип ашта телгә алалар. Көтү чыккан көнне кукай алып төшәләр идее. Кем дүртне, кем

бишне. Көтүчегә. Садака итеп. Элгәре ашлык чәчкән вакытта ку-кай алып чыкканнар, җиргә тәгәрәткәннәр, ашлык уңсын, дип. Көтүченең чиләге була иде.

**Хозур Ильяс** – юл хуҗаларыбыз, әлхәмделилләһ, шөкер аларны истән калдырмыйбыз Корьән укыганда. Хозур Ильясны бик әйтергә сезгә дә, юл йөрисез, безгә дә ул кирәк, балаларга да кирәк. Семьяңда балаң берәр кая китәсе булса «Әлхәм»не, «Аятелкөрси»не укырга кирәк. Аннан теләк телисең: Ходай Тәгалә, тәвәкәлләдем сиңа, дип әни әтә иде.

*Яңа Мансур авылында Карилов Рәхимҗан*
*Сәлимгәрәй улыннан (1935 елгы) язып алынды*

**Аулак өй.** Йолдыз санаталар җиң аша су салып биткә. «Яшерен сер»гә чыгаралар. Наказ бирәләр. «Чык, – ди, – син кемне чакырасың. Егет чыга да кызын чакыра. Алар анда сүләшәләр. Әгәр берсе беләң берсе сүләшеп йөри торган булсалар, анда рәхәтләнеп кочаклашып сөйләшеп торалар. Кайсының (кызның) чыгасы килмәсә, китәләр ул вакытта, егетнең кулына сугалар.

Яхшымы торасың, дип сорыйлар иде...

**«Йөзек салыш».** Аннан мәсәлән йөзек салып чыгалар да егет кемдә икәнен белмәсә, наказ бирәләр: «Алма җый!» (егеткә). Монда инде кызлар утырган, егет тотына алма җыярга – битләреннән үбеп йөри.

**«Арка сугыш».** Ята да ике кулын аркага куя, кемдер килеп суга. Капланып яткан күрми.

– Кем сукты?

Әгәр белмәсә, тагын кыйныйлар.

**«Дүли»** уйный идек. Берсе уртага чыга да, тегесе анда, аннан бүтәнне алалар. Бер йыр йырлыйсың да. Круг тезелгәннәр, уртада бер кеше. Әгәр например мин дә бер егет белән йөрим, теге дә ул егет белән сүләшкән икән, моңа терәп-терәп йырлыйлар:

Сиңа дигән җарлар түгел,
Син алданасың гына.

Шул арада җыр бетә дә, бу мине, мин аны чыгабыз да, шулай уртада берсе әйләнә дә, алда чыкканы гына хәзер тагы бер йыр йырлыйлар. Бу кыз икенче кыз йә егет белән әйләнә, теге уртада

кала. Бер укытучы, Ярмәкнеке, минем мужик белән чималгалаган булган, мин уртага чыксам, например, җырлый:

Сиңа дигән җарлар түгел,
Син алданасың гына.

Например, бу юлы мин әйләнәм сезнең белән, аннан мин чыгам кругка, аннан сез бүтәнне аласыз, әләнәсез, теге чыга кругка.

Алларым гөлләр ата,
Гөлләрем гөлләр ата.
Сине уйлап ята-ята
Сызылып таңнар ата.

Берсе бик әрләшкән, егете бүтән кызга караган, ерлый:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Зәкия.
Уф, дигән тыннарым белән
Алгы чәчләрем көя.

Кәккүк баскан оясына,
Ватмас микән күкәен?
Кәккүк тә бит минем кебек
Бәхетсез мескенкәем.

*Яңа Мансур авылында Бигеева Рәшидә*
*Касыйм кызыннан (1931 елгы) язып алынды*

**Раштуа вакытында ышанулар**. 1. Сук елгасы, анда бәке бар, имеш, барабыз да су алабыз. Аннан кайткач, шырпыны бура бураган кебек шулай ябештереп чыгабыз. Шунда кияүгә барасы кешең ат эчерергә килә икән коега, хәзер барганда да дәшмәскә, кайтканда да бер-береңә дәшмәскә су алып кайтканда. Төнгелеккә әзерлибез. Суны апкайткач бәкедән, ятабыз, йоклыйбыз. Иртән сорашабыз бер-беребездән, кемне күрдең, дип. Обычно күрми идек инде. Кемнең дә, имеш, ат эчерергә егет килә. «Шул егет килсә ярар идее», – диләр иде. Төшендә, имеш, күргән берсе: «Килде бит, атын эчерде, янымда басып торды».

2. Бер өчәү утларны сүндерергә, идән базына төшергә. Анда караңгы, утлар сүнгән. Көзге тотып өч кыз карап торабыз, өч егет килергә тиеш. Әгәр сразу тактаны бүлмәсәң, өчеңне дә үтерә. Мин базга төшкән җирдән читкәрәк басам, тегеләр эчтәрәк. «Килә», –

диям дә, үзем чабам да тактаны ябам. Тегеләр базда калалар, кая барырга белмиләр. Килмәгәнне юри генә «килә» диям куркытырга.

3. Безнең монда ферма бар иде бит. Сарыклар иде шунда. Сарык тотарга бара идек. Тотабыз да, кайсын муенынына бәйлисең, карт сарыкмы эләккән, яшь сарыкмы – нинди егеткә барасың: карткамы, яшькәме. Безнең әниләр шулай эшләгәннәр. Анда сарыклар да, кәҗәләр дә – бар да булган инде. Шундый вак маллар, сыерлар булмаган. Хәзер утларны сүндерәләр. Караңгыда киләләр дә берне тоталар, аннан кабызалар шәм, лампа, фонарь. Әнием, миңа эләкте карт сарык, ди (әтием әнигә хәтле өйләнгән булган, аерылган). Ә Фәткысорур түтәй кәҗә тоткан, ә кәҗә тотканга сукыр йә бер күзле туры килә. Бер күзле Сырка баба туры килә. Әбигә кәҗә эләгә. Аның да бер мөгезе төшкән булган. Әй кылый иде, торды бит шуның белән. Хәзер бик бармыйлар.

4. Чишмәнең олагын чукый идек балта белән. Шуны баш очына куеп ятабыз, кем керә төшеңә. Егет ат эчерергә киләме.

5. Итек алып чыгалар да, күзне йома да, круг әйләнә-әйләнә дә аннан еббәрә, аннан карый: итекнең башы кайсы якка таба караган. Болайга караган булса, ә бу артымнан йөри, күрәсең, бу як егете мине ала. Итекнең очы кайсы якка карый. Ятса да, утырса да итек башы кайсы якка таба карый.

6. Мунча кендегеннән тыгалар. Йонны кулмы нитә, йонсыз кулмы тыгыла. Кәшифә, Сәгъдә абзыйның Кәшифәсе килде. Безнең мунчага килгән дә тендеккә тыгылган. Анда Рәйсә апай белән Локман абзый йөри иде. Локман абзый булган мунчада Рәйсә апай белән. Теге тыгылган да кулыннан эләктереп алганнар. Теге разбой кычкыра. Кара мунчаның тишеген кендек (*төнлек*) диләр. Мунча әзер булгач, аны чүпрәк белән тыгалар, җылы чыкмасын өчен. Кулы җонны туры килсә – бай була.

*Яңа Мансур авылында Вәгыйзова Рафика*
*Сәлим кызыннан (1933 елгы) язып алынды*

**Яңгыр боткасы**. Бездә бар андый җола. Менә җаңгыр җаумаса после Троицадан соң бер атна үткәч, ботка пешерәләр төрле ярмалардан җыелып. Кайсы май алып бара, кайсы сөт алып бара. Бу йола сөйләшеп эшләнә. 2010 елны булмады яңгыр, шул җылны пешердек. Быел пешерергә-пешерергә, дип торганда гына җаңгыр

килеп җауды. Өч казан асканнар иде. Мин пешерергә калмадым, урам буйлап менә ике яктан ике кеше: теге урамга – бер кеше, бу урамга – бер кеше, ике яктан ике кеше су сибеп барабыз; кем йоклап ята – постеленә, кемнең постеле тышта – постеленә. Чиләк белән су алып барабыз. Теге очта ук чишмә бар. Шунда пешергәннәр иде. Ботка пешкәч, ашыйбыз. Кем киләлгән килә, бала-чага инде анда. Кем суга чума, суга батырышалар. Ботканы ашагач Алладан телибез инде. Яңгыр теләп инде. Бер җылны поп та килгән иде. Ходайдан ялварып сорыйбыз:

– Ходаем, яңгыр бир. Бала-чага, телсез-аңсыз хайваннар өчен, сабыйлар өчен яңгыр бир. Игеннәр кырлар өчен яңгыр бир.

Үлеләр чишмәсе, дип йөртәбез. Шуның суы инешкә – Урдалкага агып төшә. Безнең авылның теге ягында урманның теге ягында Урдалы авылы бар җә шуннандыр инде ул. Анда татарлар яши. Безнең су урыслар ягыннан килә. Петровкалардан әйләнеп Урдалыга бара. Түбән як буенда чишмә чыга иде, урталыкта. Хәзер колонкага алданып, карамагач бетте алар. Чиркәү дә юк бездә. Соңгы юлга бер-ике карчык укый инде шунда, иман әйтә. Кырыгында укыйлар. Ураза булмаганда теләсә нәрсә пешерәләр, ураза булганда ит пешермиләр. Пасха вакытында. Пасха алдында Троица алдында родитель день – күп халык бара зыяратка. Пасха алдыннан үлеләр өчен мунча ягу бар. Четверг җагабыз, воскресенье Пасха була, уразаның соңгы атнасында. Мунча ягам, савыт куям, сабын, полотенце куям да, савытка су салам. Менә шунда кайтыгыз да җуыныгыз, дим.

Троицага каен чыбыгы бәйлиләр иде. Дугалар белән. Полотенцелар асалар ие атларга безнең заманда, хәзер юк инде ул.

Суган утыртканда ипигә май ягып, түтәл башына күмеп калдыралар.

Ишеткәнем бар, мунча ягарга барганда, ипигә май ягып барганнар. Ул ипине кая куйганнар? Иман урынынадыр инде ут куйганда.

Чәчәүник бар иде без үскәндә. Эчереп бетте инде. Хәзерге вакытта бер крест кенә утыртып куйдылар. Өй генә бар инде, ясап куйдылар.

Кыз белән егет йөри башласа, сукмак салалар ие. Кызның өеннән җегетнең өенә кадәр опилка салалар иде.

*Назаровка авылында Данилова Анастасия Григорьевнадан (1939 елгы) язып алынды*

**Раштуада.** Кемгә барабыз – тотынабыз гадать итәргә, әле итекләрне ташлыйбыз койма башыннан, кайсы якка карый – шуңа чыгабыз имеш.

Киттек тавыклар тотарга. Күршедә утырмада үзебез. Тавыкларны караңгыда тоттык, идәнгә куйдык, анда ризык бодай да салдык, күмер дә салдык, кәгазъ дә куйдык, көзге дә – барын да куйдык та, тавыкларны светка кертеп куйдык та тавыклар мич башына менеп киттеләр ялт иткән утка куркып. Сүндердек, тавыкларны тоттык та идәнгә җибәрдек. Идәнгә җибәргәч, светны кабыздык. Болар күрделәр: монда ашарга да бар, эчәргә дә бар. Карап торабыз инде: кайсыбызның тавыгы нишли, кайсыныкы китте күмер чукый – бу усал булыр, көзгегә карый – бу мактанчык булыр, кәгазъ – укыган булыр, кемнеке ашлык ашый – бай булыр. Ашлык – байлык. Бу гаданиеләрне Раштуада эшли идек, январьнең еделәрендә.

Арабызда дустыбыз бар иде. Тозлы пипиләр пешергән (*вак кына эпәй*). Тозлының ашыйсың да ятасың, кем белән дә сүләшмисең. Җидене ашарга кирәк тозлы пипине.

Иртән торасың да тәрәзәдән карыйсың – кайсы кеше китә. Йокыдан тордык та, Сәлам абзый исән иде, теге очка узып бара. Бөтенебез бер Сәламне күрдек. Шул очныкына кияүгә чыгасың.

Бач астыңа карточка куеп ятсаң, инде шуны төшеңдә күрсәң, кияүгә чыгасың. Сүгәнең булгач карточкасын табасың инде.

*Иске Мәчәләй авылында Бахтеева*
*Разия Әхмәдулла кызыннан (1946 елгы) язып алынды*

**Зәңки бабай**га дога кылу бар. Ул малларга. Сыер бозаулагач уз (*угыз*) уздырабыз. Пешерәбез дә табынга чакырабыз. Абыстай, йә мулла укый. Зәңки бабай да искә алына. Сөте булсын, дип, исән-сау булсын, дип әйтелә. Көтүчегә күкәй бирү бар иде элекке вакытта. Беренче көнне көтүне куабыз. Әниләр әтә иде: «Вот кудың, шул таякны син аранга сарайга кыстыр, чтобы ул үгә кайтсын. Сыерың беркая да китми, үгә кайта».

Цыган йизни бар иде. Ул:

– Балдыз, син сыерыңны керткәндә убыр уты (*шайтан таягы, үлән*) аша (*җиргә ташлап*) кертсәң, күз тими.

– Китердем мәләш агацы, нигезеңә бәләп куй, күз тимәсен. Әле дә шулай эшлибез.

*Иске Мәчәләй авылында Исмәгыйлова*
*Асия Ильяс кызыннан (1957 елгы) язып алынды*

**Раштуа көнендә.** Галушны капка аша бәрә идек. Кайсы якка карый – шунда кияүгә чыгасың. Сарык тота идек. Карт сарык тотсаң, карт кешегә чыгасың, яшь сарык тотсаң – яшь кешегә.

Коелардан көзге аша карый идек. Коега барабыз да көзге куябыз. Көзгегә карыйбыз, күренә, күренә, дибез. Көзге аша кое төбенә карап.

*Яңа Мәчәләй авылында Фәтхуллина*
*Разия Вашигулла кызыннан (1940 елгы) язып алынды*

**Каз өмәсе** көнне бәлешләрне, ике бәлешне суынырга чыгардык. Бу кич, каз йолкыгач. Егетләр килделәр. Ишек төбендә җырлыйлар:

Ал итә, итә, итә,
Гөл итә, итә, итә.
Сезнең яңга килеп җиттек,
Буксават итә, итә.

Аннары үзара сөйләшәләр бии-бии:

– Пешә-төшә
– Пешә-төшсә, бөгелә төш.
– Бөгелә төшсәм, суы чыга.
– Суы чыкса, шу да чык.

Болар киттеләр, чыксак табада бәлеш юк. Болар билләренә бәлешне бәйләгәннәр. Без белмибез, бергә биибез алар белән. Әтәбез: болар яңа такмаклар өйрәнгәннәр, дип уйлыйбыз. Алар хәйлә белән бәлешне урлаганнар.

**Кияүне каршы алганда** җырлыйлар:

Ишек бавы бер алтын,
Безнең кызыбыз мең алтын.
Түлә, җизнәкәй, акчаңны
Бүген тышта бик салкын.

Аннары ишек ачылып китә. Ул акча сибә дә, кызны алып чыгып китә.

*Яңа Мәчәләй авылында Әмирова*
*Асия Әхмәтгали кызыннан (1956 елгы) язып алынды*

## Җырлар

### Авыл көе

Сыгыла-бөгелә шаун килә,
Бөгелә юлларindин.
Әллә алып кайтыйм микән
Җитәкләп кулларindин.

Одеял микән, юрган микән
Минем ябынганнарым.
Сезгә генә мәгълүм микән
Минем сагынганнарым.

Килә күрәселәрем,
Сагынганда догалар җибәргә
Юк бит адресларың.

*Красный мост авылында Ваккaзов*
*Хәлимулла Мөхәммәт улыннан (1927 елгы) язып алынды*

### Тибрәлә җыр күңелләрдә

Фабрикаларым булса,
Шәлләр бәйләмәс идем.
Әгәр булса ике ярым,
Берсен жәлләмәс идем.

Иркәм-иркәм, дип әйтәсең,
Үзең иркәләмисең.
Үзең иркәләмәгәчтен дә
Мин дә иркәләмимен.

* * *

Лампочкалары горит
Германия бүләк иткән
Унбиш кызга бер гарип
Аллар итәлә итә
Аллар итәлә итә дә
Сагынса килеп китә.

* * *

Алъяулыгым төшеп калган
Кесәмнән көзгем белән.
Үтә гомер, димәс идем
Яшәсәм сезнең белән.

Алтын балдак кечкенә ул
Зур аның вазыйфасы
Яшьләргә иң кирәге
Әти-әни фатихасы.

*Гали авылында Кәлимуллина Нәсимә*
*Мидхәт кызыннан (1963 елгы) язып алынды*

Армиягә киткәндә ат белән урам әйләнү бар ие бит яулыклар белән, грузовойга утырдык та җырлап киттек:

Исемнәре, исемнәре
Исемнәре Гәл(и) авыл
Гел исемдә, гел исемдә
Гел исемдә генә ул.

Төрттереп ерлыйдырыек:

Кашларың кара кыйгач,
Кашларың кара кыйгач.
Нигә кыйгач булмасын соң
Балталар белән кыргач.

Кыр тавыгы күкәй сала
Төрән араларына.
Дошман булсам булам инде,
Керәм араларына.

Исмәле җил, тукта әле җил,
Өзмә гөлләр сачәген.
Алга килми белеп булмый
Башың ни күрәчәген.

Алтын алкаларым сынды,
Алкалар алырсың микән?
Үземә булырсың микән,
Ятка калырсың микән?

*Гали авылында Латыйпов Госман*
*Габдрәшит улыннан (1943 елгы) язып алынды*

## Инәйнең йыры

Тәрәз ачып бодай сиптем –
Килде күгәрченнәрем.
Мин сезне шуңа чакырдым,
Килде күрәселәрем.

Зәңгәр чәчкә матур була
Сөрми калган җирләрдә.
Минем дә торасым килми
Сез булмаган җирләрдә.

Бәйлим-сүтәм, бәйлим-сүтәм
Бәйләгән шәлләремне.
Бәйләгәннәр кебек торам,
Белмисез хәлләремне.

*Гали авылында Ганиева Хәтимә*
*Вәли кызыннан (1931 елгы) язып алынды*

Армиягә киткәндә җырлыйлар иде:

Кыр капкасын чыккан чакта
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый
Сау булыгыз, туганнар.

Хатыннар җырлый иде:

Агыйделнең аръягыннан
Атлар килә адымлап.
Кара күлмәкләрем булса,
Юар идем сабынлап.

Аклы ситса күлмәгемне
Юсам каралмас микән?
Искән җилгә сәлам әйтсәм,
Алып баралыр микән?

*Яңа Мансур авылында Бигеева Рәшидә*
*Касыйм кызыннан (1931 елгы) язып алынды*

Армиягә солдат озатканда җырлана:

Таулар биек, таулар биек,
Таулар биек менәргә.
Баскычлар юк, баскычлар юк
Шул тауларга менәргә.

Болындагы үләннәрне
Таптамам, дигән идем.
Туып үскән авылымны
Ташламам, дигән идем.

Болындагы үләннәрне
Таптарга туры килде
Туып үскән авылымны
Ташларга туры килде.

Сызрань күпере сиксән такта
Ничек санап үтәрсең.
Туып-үскән авылымны
Ничек ташлап китәрсең.

Бишмәтемнең биш төймәсен
Нигә төймәләмисең?
Аралар да ерак түгел
Нигә килгәләмисең?

Бишмәтемнең биш төймәсе,
Алтынчысы – каптырма.
Бар ерларны ерлап үттем,
Юк ерларны таптырма.

Эх, дускаем, синме әллә,
Ат эчерәсеңме әллә?
Кулларыңа чәчкә тотып,
Мине көтәсеңме әллә?

## Язмышлар, мәхәббәт турында

Кайтырмын, дидем, кайта алмадым,
Биргән вәгъдәне, таптап үтмәдем.
Барыбер көт мине, вакыт үтмәгән,
Без очрашасы, язлар җитмәгән.

Минем күңелем, гел сине уйлый,
Нишлим соң инде, онытып булмый.
Язмышлар безне, көчләп аерган,
Хатларын укыйм, өзелеп сагынгач.

* * *

Язмыш диеп сиңа табындым да,
Ялгышымны соңлап аңладым.
Йөрәгемдә сөю алып килдем,
Бәхтең бүләк итә алмадым.

Яралы кош булып бер тартынып
Җылы эзли җаннар нур көтә.
Бер-береңә бәхет бүләк итеп
Яшәүгә дөньяда ни җитә.

Иңнәреңә башкаеңны салып,
Күз яшьләрен түгеп еладым.
Сабырлыгым сынды, инде нишлим,
Бәхтең бүләк итә алмадым.

Сине, дустым, кайтыр-кайтыр, диеп,
Кичер, җаннарымда калмады.
Бер җыелып кайтыйк әле, җаныем,
Бәхет бүләк итә алмадым.

* * *

Урманнарда йөргән чакта
Адашты юлларыбыз.
Күңелем йомшак, еләрмын, дип
Бирмәдем кулларымны.

Сикердем читәннәремә.
Йөгердем җитә алмадым.
Ни булды икән телләремә?
Са убул, дип әйтә алмадым

Өй артындагы талыңны,
Яратмасаң, кисәрсең.
Мин сагынсам тәрәз ачам,
Син җил булып исәрсең.

* * *

Бер ел гомер, гомер китабында
Яфрак булып өзелде тагын да
Еллар уза диеп һич кайгырма
Мин барында әле яныңда.

Туган көнең, бәгърем, синең бүген,
Ниләр бүләк итим, ниләр бирим?
Сиңа дигән гөлләр кочагында
Мин бәхетле син янымда чагыңда.
Әйләнәбез еллар кочагында,
Мин бәхетле син янымда чагыңда.

Бүләк итеп караңгы төнне дә
Азат итәм кояшның нурларын.
Онытма, дип, синең өчен янган
Сине өзлеп сөйгәнем бар, диеп.

Бүләк итеп җылы карашыңны
Меңнәр арасыннан табарсыңмы?
Бүләк итеп шатлык-сагышларда
Гомерем буе озатып торасыңмы?

Мин гаепле түгел, мин гаепле түгел,
Хыянәтче, диеп уйлама.
Нигә сине көттем, уйламый үз иттем,
Башлагансың икән, ташлама.

* * *

Караңгы төннәрдә, караңгы көннәрдә
Яратамын, диеп әйттең син.
Төннәрдә саф һава, төннә йолдыз яна,
Кабат әйтүеңне көттем мин.

Елама, елама, тилмереп карама,
Яраларны вакыт дәвалый.
Түзәргә барсына, сабыр ит, ярсыма,
Өзмә җанны, алай ярамый.

Таңнарда уянам,таңнарда уйланам
Сөйгәнем күренә күземә
Сөю нурларында, кызның уйларында
Янар хисләр таша, түз генә.

*Яңа Мансур авылында Садриев Миргазыян*
*Фәссәхетдин улыннан (1958 елгы) язып алынды*

Йөрәгемне синңа бирер идем,
Мин йөрәксез ничек торырмын?
Юлларыңа гөлләр булыр идем,
Син өзәрсең, ә мин корырмын.

* * *

Аерылабыз, дигән шомлы уйлар
Килмәсеннәр синең башыңа.
Эх, бәгырем, алсу гөлләр тотып
Мин чыгармын синең каршыңа.

* * *

Шәл бәйлимен, шәл бәйлимен
Пуховый булмаса да.
Сезгә озын гомер телим,
Үземә булмаса да.

* * *

Иртән торып тышка чыксам,
Сезнең якларда томан.
Шул томаннар арасыннан
Килеп чыгарсың сыман

*Яңа Мансур авылында Карилов Рәхимҗан*
*Сәлимгәрәй улыннан (1935 елгы) язып алынды*

Кодаларга барып кергәч болай җырлыйбыз инде:

Өстәл өсләренә бик килешә,
Күтәреп үк суккан ашъяулык.
Ашагызчы, кодалар, калҗаларын,
Сезнең өчен пешкән ашамлык.

Алар безгә каршы җырлый:

Агыйделкәйләргә басмалар салдым,
Вак кына, вак таш белән.
Безне кодагыйлар көтеп тә торган
Тәмнеләрдән тәмне аш белән.

Кодагыйлар табак белән ашамлык алып киләләр. Кода ипие, диләр: конфетлар да, пирог та, эчемлек әйбере дә була, ит тә: казмы, үрдәкме. Ике хатын күтәреп торалар өстәл башында шуны, болай җырлыйлар:

Киемчеләр кием кискәндә
Калмый булмый аның пычкагы (кисентесе).
Аягыгыз арыса, кулыгыз талса,
Әнә сезгә өстәл почмагы.

Ай-гай, балаларым, сезгә әйтәм
Бергә ашыек ашларны.
Бергә ашасак ашларны
Хур итмәбез башларны.

Иртәләрдә торып тышка чыксам.
Тәгәрәп үк килә бер алма.
Ай сезләрне безгә, безне сезгә
Сөеп кушсын иде бер Алла.

Куярга куша табакны. Шуннан кияү җегете алып, кияү күчтәнәче, дип, шуны саталар кешеләргә – акча җыялар. Кашыкны өстәмә тезәләр дә кашыктан да акча җыялар. Керәшен туе бик кызык инде ул. Менә минем внучканы биргәндә керәшен туе ясаган идек. Хәзер 12 ел шуннан соң керәшен туе күргән юк.

Солдатка озатканда инде болай җырлыйбыз:

Солдат итеп алсалар да,
Будырма билләреңне.
Ун елга дип алсалар да,
Онытма илләреңне.

Аклы алъяпкыч билләрдә,
Җилферди ул җилләрдә.
Бер минут торасым килми,
Сез булмаган җирләрдә.

Болар түгәрәк уенда әйтелә торган җырлар:

Иртән торып тышка чыксам,
Поезд бара дегеткә.
Бик исебез китми әле
Өйләнмәгән егеткә.

Кара костюмыңны кисәң,
Кысып тора билләрең.
Сине кем соң сөймәсен,
Юк килмәгән җирләрең.

**Үз туган айларым**

Сандугач булып сайрыйым,
Өй артында яшел сад булса
Үз туган айларым.
Җаннарымны җарып бирер ием,
Сезнең сөюегез хак булса
Үз туган айларым.

*Назаровка авылында Данилова Анастасия*
*Григорьевнадан (1939 елгы) язып алынды*

Без икәү уйнар идек,
Күлләргә чумар идек.
Кайбер кичләрне кайтмыйча
Ындырда кунар идек.

**Назаровка**

Назаровкабыз урнашкан
Биек тау итәгенә.
Анда яшәгән халык
Тора бик иртә генә.

Назаровка, туган авылым
Торган җирем гөлбакча.
Сокланып карап торамын
Сайраган сандугачка.

Назаровка чишмәләре
Көмеш чыгып агалар.
Шул суларны эчеп үсә
Безнең бала-чагалар.

### Гайнижамал

Биек тауларны да шул
Өй башында, Гайнижамал.
Күрчик аллар микән нә шул,
Эй дусларым, эй кагынган

Очкылыгың тотса ла шул
Тот исеңдә, Гайнижамал,
Мин булырмын сезне дә шул
Эй дусларым, эй сагынган

*Назаровка (Кече Урдалы) авылында*
*Тазов Михаил Егоровичтан (1939 елгы)*
*язып алынды*

### Арышлар жыры

Ай-һай, арышларның, ай уңуы,
Уңуыннан бигрәк, уруы, эй әле уруы.
Сез, туганнар, белән бер күрешкәч,
Ай-һай күңелләрем лә булуы, эй әле булуы.

Быел арышлар да бигрәк уңган,
Аның камылларын ла кем урган, эй әле кем урган.
Ташлашмыйк туганнар, ташлашмыйк,
Туганнарын ташлап кем уңган, эй әле кем уңган.

Арышлар да урдым, ай, учмалап,
Чүмәләләр куйдым ла миргәләп,
Әле дә йөрербез бергә-бергә,
Тагда йөрсәк иде лә бергәләп, эй әле бергәләп.

### Туй жыры

Капка төпләренә көртләр өйгән,
Җирән атлар җигеп кем килгән.
Никләр дә жырламабыз берләр жыру
Сөйгән кодаларыбыз килгән.

Ай-гай табаларда ниләр дә пешә,
Эй, урамнарга чыккан исләре.
Ашап кына, эчеп лә җөриек,
Эй, китсен дә адәмнәрнең исләре.

Җөрегән чакларда, без җөредек,
Эй, талгынайдан басмалар салдырып.
Йөресәк йөрибез лә уйнап көлеп,
Без җөрмибез хәтер калдырып.

**Урдалы буе**

Иртән торгач,
Алтын тәңкә тактым.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашыйк әле.

Алтын тәңкәбез зур мал түгел,
Бер күрешүләре әллә ни.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашыйк әле.

Урдалы урамы – озын урам
Почтовойлар үтә, туктамый.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашиыйк әле.

Сез туган айларым килә, дигәч
Чыктым төн җокымны җокламый.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашик әле.

Төемнәр, дисәгез, мине озатыйым
Басу капкаларын чыкканчы.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашыйк әле.

Кояшлары баер, ае калкыр,
Без аерылышып киткәнче.
Урдалы буе,
Әйдәгез, җырлашыйк әле.

*Назаровка авылында Иванова Ульяна*
*Степановнадан (1940 елгы) язып алынды*

**Натукай**

Җырлыйк әле, җырлыйк әле, Натукай,
Җырлап ачыла күңел, сандугач баласы.

Җырлап ачылмаган күңел, Натукай
Мәңге ачылачак түгел, сандугач баласы.

Яшь гомерләр ике килми, Натукай,
Сулар үргә акса да, сандугач баласы.

Иртән торып тәпти салдым, Натукай,
Ашадым майлап кына, сандугач баласы.

Аванс алгач, получка алгач, Натукай
Килегез җайлап кына, сандугач баласы.

Ал да булырбыз әле, Натукай.
Гөл дә булырбыз әле, сандугач баласы.

Арага дошман кермәсә, Натукай,
Бергә булырбыз әле, сандугач баласы.

* * *

Эй, дусларым, җырлар башлыйм,
Күтәреп җибәрегез.
Авыр сүзләр ишетсәгез,
Үткәреп җибәрегез.
Кушымта:
Ай, зур Зария, бай зур Дария,
Таш ташыйлар, ком ташыйлар
Машина юлларына.
Алулары кыен булыр
Бирмәгән кулларына.

Урталарда торган чакта
Әйләнмиме башларың?
Яза торган каләм кебек
Синең кара кашларың.
Кушымта:
Ай, зур Зария, бай зур Дария,
Төнге сәгать уникедә
Поезд бара дегеткә.
Бигерәк тә гарьлек инде
Кыз тапмаган җегеткә.

Урталарга чыккансың,
Боргалатып баскансың.
Син анадан тумагансың,
Чәчәк булып аткансың.
Кушымта:
Ай, зур Зария, бай зур Дария,
Кара костюмыңны кисәң.
Кысып тора билләрең.
Сине кемнәр сөймәсен соң
Җук килмәгән җирләрең.

Эй дусларым җырлыйк әле,
Барыбез бергә чакта.
Озакламый таралырбыз,
Төрлебез төрле якка.
Кушымта:
Ай, зур Зария, бай зур Дария,
Таш ташыйлар, ком ташыйлар
Машина юлларына.
Алулары кыен булыр
Бирмәгән кулларына.

**Туй җыры**

Талдан гына талларга, җепәкләр элдем,
Тарта гына, тарта талыктым.
Җылның тәүлеккәе озын икән
Көтә генә көтә зарыктым.

Талдан гына талдан чаңгы җуындым,
Таудан гына тауга җөрергә.
Безгә генә Ходай шулай язган
Туйдан гына туйга җөрергә.

Менә китәлми калган (кияүгә) мин, например, бер яраткан җегет уртага чыкса җырлыйм:

Аллар булгансың икән,
Гөлләр булгансың икән,
Үзәгемне өзәр өчен
Жәлләр булгансың икән.

Аллар буласым калган,
Гөлләр буласым калган.
Аерылмый, диләр, былбыллар
Былбыл буласым калган.

Чәчләреңне көдерәләт
Майлар кирәк, димәсәң,
Әйләндермә башкаемны
Чын күңелдән сөймәсәң.

**Тручин көе**

Каен артыннан баралар кояш чыгышына. Ике егет бара, каен апкайталар. Ул каеннарга аннары урам буенча төшәләр яулык бәйләп һәрбер йорттан, аннан, җырлап, авыл очына хәтле озаталар, каенны суга салалар, яулыкларны, сүтеп алып, кызлар бәйлиләр.

Каенны суга салганда җырлана торган җыр:

Урманның буенда баллылар усак,
Балталарым чапса, бал тама.
Сез туганнар белән бер сөйләшсәм,
Җанга йөрәккәем хәл таба.

Эй, бәйлибез инде, эй, бәйлибез,
Французский яшел яулыкны.
Безләргә Ходайдан телибез,
Исәнлекләр белән саулыкны.

И, атларыбызны бәйләпләр куйдым,
Яшел яфыраклы имәнгә.
Безләргә шушылай җөрергә
Җыллар китсен ие имингә.

*Назаровка авылында Афанасьева Надежда*
*Михайловнадан (1971 елгы) язып алынды*

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәлиулла
Булса булсын сөйгән ярың
Йә гармонист, йә мулла.
Су буйлары, су буйлары
Су буйлары гел нарат
Суларга барсам, утырып уйлыйм
Агым суларга карап.

Гармуныңны тартып уйна
Без йырлаган көйләргә
Без йырлаган, сез уйнаган
Калсын сагынып сөйләргә.

Солдатка озатканда җырлый идек:

Солдат ята тар куйкыда
Тар шинелен ябынып.
Аягүрә төшләр күрә
Туган илен сагынып

Сау бул, Богыруслан каласы,
Каршы тауларың белән
Сау бул, минем туган авылым
Сөйгән ярларың белән

*Иске Мәчәләй авылында Сапуков Хәлиулла*
*Абдулла улыннан (1946 елгы) язып алынды*

Тау башында Акбүз атым
Үлән тапмый, су капмый
Үлән тапмый, сулар капмый,
Синсез күңелем ямь тапмый.

* * *

Мин әнкәемне төшемдә күрдем,
Каз бәбкәләрен күлгә төшерде.
Каз бәбкәседәй сабый чагымны
Әнкәем кабат исемә төшерде.

Мин әнкәемне төшемдә күрдем,
Нидер әйтте дә шунда юк булды.
Сагынгансыңдыр беләм, әнкәем,
Кайта алмадым күп еллар узды.

*Иске Мәчәләй авылында Бәхтиева Разия*
*Әхмәдулла кызыннан (1946 елгы) язып алынды*

Күк күгәрчен күкләрдә
Төшкән бодай чүпләргә
Юк әнием, юк әтием
Әткән сүзләр юпләргә.

Аклы ыштан, буй-буй ыштан
Ничек чыдарбыз кыштан.
Кыш чыгуы берни түгел,
Аерылмыек туганнан.

Советский ак самовар
Кайный күмерсез генә.
Әллә сездән аерылганга,
Йөрим күңелсез генә.

Сары, сары, сап-сары
Сары сишәк саплары
Без саргаймый, кем саргайсын
Килми сәләм хатлары.

Хатлар язам утырып,
Ак кәгазне тутырып.
Хатым китте, үзем калдым,
Диваннарга утырып.

Алларым аллар ата,
Гөлләрем гөлләр ата.
Сине уйлап ята-ята
Озын төннәр таң ата.

Өстәл өстендә гөлем бар,
Гөл өстемдә сөлгем бар.
Эх, дускаем, уйлап кара,
Синнән башка кемем бар.

Тау башында тимер кабак (*капка*)
Ачыла да ябыла.
Төннә йөргән егетләргә
Матур кызлар табыла.

*Иске Мәчәләй авылында Исхакова Миннехәят*
*Әхмәдулла кызыннан (1929 елгы) язып алынды*

Аллар булганда гына,
Гөлләр булганда гына.
Күтәрелде күңелләрем
Сез, туганнар, булганга гына.

Их, уф Алла, уф Алла,
Нигә уф Алла икән?
Минем сабыр күңелләрем
Нигә уфтана икән?

Ал да булырбыз әле,
Гөлдә булырбыз әле.
Бүген, әле, иртәгә дә
Бергә булырбыз әле.

Агыйдел кичтеңме әллә,
Суларын эчтеңме әллә?
Ел тармакларына басып
Тибрәнеп үстеңме әллә?

Аккош микән, былбыл микән
Балаларын сайрата?
Хәсрәт микән, нужа микән
Нурлы йөзен саргайта?

*Иске Мәчәләй авылында Таишева Зәкия*
*Миргаз кызыннан (1924 елгы) язып алынды*

Каенсарның башларында
Калды баскан эзләрем.
Шул эзләремнән
Яшьлегемне чыгып эзләдем.

Атларыңны бәләп куй,
Ебәрмә бакчаларга.
Яшь гомерне сатып
Алып булмыйдыр акчаларга.

Уйсу җиргә су җыела,
Шунда казлар коена
Яшь вакыт та бер вакыт
Чәчәк булып коела.

Решотка белән урыйлар
Комсомол каберләрен.
Яшьли гомер ике килми,
Белегез кадерләрен.

Биек тауның башларында
Школ тәрәзәләре.
Сиксән градуска җитә
Сагыну дәрәҗәләре.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәрен беләсең.
Былбыл булып, җиргә кунып,
Төшләремә керәсең.

Бөдәрләнеп чәчәк атсын
Мәхәббәт гөлләребез.
Ике тармак гөл шикелле
Гел янәшә яшәгез.

Их икегез, икегез,
Икегезнең битегез.
Икегездә пар килгәнсез
Тигез гомер итегез.

Атландым атның биленә
Киттем Герман җиренә.
Герман җире яшел үлән,
Йә кайтамын, йә үләм.

Без авылдан чыккан чакта
Күтәрелде бураннар.
Бу китүдән кайта алмасак,
Сау булыгыз, туганнар.

Гитлер кигән кызыл ыштан
Киләцагы арыштан.
Ашарына булмагачтын,
СССРга ябышкан.

*Иске Мәчәләй авылында Субеева Рәкыйбә*
*Локман кызыннан (1926 елгы) язып алынды*

Аулак өйләр була иде. Апамнарны карап тора идем. Җырлыйлар иде, бииләр иде:

Алай да безгә нужа
Болай да безгә нужа.
Әтәч тә бездән бәхетле
Кырык тавыкка хуҗа.

*Яңа Мәчәләй авылында Бәхтиева Фатыйма Сафиулла кызыннан (1941 елгы) язып алынды*

Сау бул, Ярмәк, сау бул Ярмәк,
Юкәле тауларың белән.
Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә,
Калган яшьләрең белән, –

дип, башлап җырлый идек армиягә киткәндә. Урамны иңнәп ике рәт тезелеп, уртада – гармунчы. Яшьләр ул вакытта күп иде. Ярмәк көен ерлап бөтен авылны әйләнә идек армиягә киткәндә:

Әткәем-әнкәем, сау булыгыз,
Еллар кайтмый улыгыз.
Бу китүдән кайта алмасам,
Туганнарым, сау булыгыз.

Сандугачлар килгән безгә
Китәрләрме икән көзгә?
Язгы сабантуйларына
Кайтырбыз микән без дә?..

Каршыбызда Юкәле тау,
Тагын яшәрер әле.
Ходай гомерләрне бирсә,
Бергә яшәрбез әле.

*Иске Ярмәк авылында Галимуллин Наил Нәбиулла улыннан (1957 елгы) язып алынды*

Җырла, җырла, дип әйтәсез,
Җыр чәчмәдем бакчама.
Җыр чәчмәсәм дә бакчама
Сатып алмыйм акчага.

Әби, тый әле кызыңны,
Харап итеп китәрләр.
Капка астыннан башын тыкса,
Үзен үбеп китәрләр.

Бүген киямен әле
Кипкенең яшелләрен.
Тагын берне сөям әле
Зур баш (*кушамат*)ның
нәселләрен.

Утта янмый, суда батмый
Без Ярмәк әбиләре.
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп
Гөрләтеп яшик әле.

Кибетчегез бигрәк матур,
Елмаерга ярата.
Менә, малай, мин сиңа әйтим,
Бик үтемле товарларны
Астан гына тарата.

Чибәр кызлар, сыер сава,
Беләкләре талмасын.
Менә, малай, мин сина әйтим,
Сыерларны савып киткәч,
Савытта сөт калмасын.

Кибетчегез бигрәк матур
Күзләре дә сөрмәле.
Менә, малай, мин сиңа әйтим,
Бала акчаларым юк, дип,
Сдачаны бирмәде.

Сызлып таңнар атса да,
Сызлып таңнар атса да,
Бу минутлар кире кайтмас,
Сулар үргә акса да.

Салкын чишмә буйларында
Атлар эчерсәм иде,
Туган-үскән Ярмәгемдә
Гомер кичерсәм иде.

Ай югары, ай югары,
Ай югары, без түбән.
Утырган урыныгыз белән
Алып китәрдәй булам.

Аягыңдагы итегең
Африканский икән.
Сикереп-сикереп биюләрең
Саесканский икән.

Төлке тамагы мыни,
Төлке тамагы мыни.
Бөккәләнә, сыккалана,
Кишер сабагы мени.

Каян кайтып киләсең,
Каян кайтып киләсең?
Арыш башаклары кебек
Шылдыр-былдыр киләсең.

Озын буйлы кешегә:

Арыш башын кистеңме,
Арыш башын кистеңме?
Инәңә токмач җаяргә
Уклау булып үстеңме?

* * *

И, Раилә, нечкәбил дә
Ничәгә бөгеләсең?
Ниужели ирең өчен
Шулкадәр өзеләсең?

Исеме Кәрәм түгел,
Исеме Кәрәм түгел.
Җырны чәчеп үстермибез,
Җырыбыз әрәм түгел.

Алдырып куй, каптырып куй
Костюмыңның алларын.
Син үзең дә тартып алдың
Сөйгән кеше ярларын.

Алдырырга да була,
Алдырырга да була.
Теләмәсә, ят кулына
Калдырырга да була.

*Иске Ярмәк авылында Гайфуллина Фәния*
*Фатыйх кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

**Каршы уен тарихы.** Революциягә кадәр, аерым хуҗалык вакытта җомга көн эш көне булмаган. Олылар, бабайлар мәчеткә бара торган көн булган, хатын-кызлар өйдә. Ә яшерәк кешеләр: кызлар, егетләр, яңа өйләнешкәннәр җомгадан соң кырга чыгып каршы уен оештыра торган булганнар. Каршы уенда бик оста җырчылар булган. Алар менә шушы каршы уен көен җырлый торган булганнар. Аннан соң шунда танышканнар. Кичкә хәтле менә шулай уйнаганнар. Һәр җомга саен шушындый зур бәйрәм ясый торган булганнар. Җомга бетүгә атларга төялеп китәләр.

Революциядән соң ял көне базар көне булган. Бер 14 км ераклыкта Мүкле күл дигән урын бар. Шунда җыела торган булганнар. Анда Ярмәктән дә килгәннәр, Бакайдан да, Ике Усманнан да, Оренбург өлкәсе Вафайдан да. Бер гармунчы булган. Ике егет, кругта кызлар, егетләр әйләнә, ә болар уртада каршы уен көен җырлый торган булганнар. Аннан соң, парлап-парлап, круг буенча егет белән кыз сөйләшеп, күбесе шунда танышканнар. Моны кругта да, урамда да җырламадылар, каршы уенда гына.

**Каршы уен җыры:**

Кырларга да чыгып кыргый аттым,
Асыл кышлар күреп тагы аттым.
Сез дусларым өчен яннар аттым,
Булмады ла очар канатым.

Кушымта:

Ал кирәкми безгә, гөл булгач,
Яр кирәкми безгә, сез булгач.

Һаваларда очкан аккошларның
Каврыйлары җиргә коелган.
Килмәгән дә булсам, күрмим икән,
Нинди матур дуслар җыелган.

Кушымта:
Асыл егет кура җиләге,
Ябышып чыга кызның зирәге.

*Камышлы авылында Шәкүров Мөхәммәт*
*Зыя улыннан (1936 елгы) язып алынды*

Сәхипкамал әбинең аягы сынгач җырлый иде. Ул (1903 елгы) 103 яшькә хәтле яшәде:

Мин бәхетсез, үлмим дә,
Бәхетлеләр гел бәхетле,
Мин бәхетне белмим дә.
Бәхетлеләр гел бәхетле,
Мин бәхетсез, үлмим дә.

*Иске Балыклы авылында Йосыпова Венера*
*Кәрам кызыннан (1953 елгы) язып алынды*

Үтте дә китте яшьлегем,
Үткәнен дә тоймадым.
Йә, үтмә, дип, йә китмә, дип
Үзем бер дә тыймадым.

Атарга да өлгермәде,
Чәчкәсен койды гөлем.
Ә шулай да чәчкә атты
Таңнарда искән җилем.

Эх, мин гөл чәчәге булсам,
Ал чәчәк атыр идем.
Атлап түгел, яшьлегемә
Йөгереп кайтыр идем.

*Иске Балыклы авылында Гадельшина Фәһимә*
*Хаҗикәбир кызыннан (1923 елгы) язып алынды*

**Мөнәҗәтләр**

Безнең инәйләр вакытында мөнәҗәтләрне бик күп әйтәләр иде. Махсус чакыра идек Мәүледләргә. Хәзер ул юк. Салават әйтәбез дә Коръән укыла.

Мөнәҗәт.

Әгүзе билләһи.........рахим.
Берәү тәһарәт алганда
Укыса иңнәәнзәлне,
Кыю җәннәтне теләсә,
Керер ул бәндә җәннәткә.

Икенче мәртәбә дәхый
Укыса иңнәәнзәлне,
Ти Ибраһим, Муса белән
Бәрабәр булыр ул бәндә.

Өченче мәртәбә дәхый
Укыса иңнәәнзәлне,
Рәсүлулла мәхәлесендә
Булыр ул бәндә мәһшәрдә.

Дүртенче мәртәбә дәхый
Укыса иңнә әнзәлне,
Бер Ходайның бидарына
Улыр ул бәндә мәһшәрдә.

*Гали авылында Ганиева Хәтимә*
*Вәли кызыннан (1931 елгы) язып алынды*

Бу мөнәҗәт – кабергә бару.

Минем әтәемнең апасы бик күп мөнәҗәт белә иде. Язып алмадым, соңыннан, дип, ул әле тора, дип, аннан булмады.

Күңелдән нәрсә өйрәнгән идем шуны өрәндем:

Бу кабернең эче тардыр,
Ничек тын алырбыз инде?
Җавап бирергә торганда
Ничек кузгалырбыз инде?

Бу кабернең эче салкын
Суыктыр инде тәннәрем.
Сорау-соәлләрне кылганда
Ни кыйлыр инде җаннарым?

Бу кабернең эче тардыр
Бик каты сусармын инде?
Әзерләгән суым да юк
Каян су алырмын инде?

Бу кабернең эче тардыр
Түшәк хәзерли алмадым?
Кабердә бүтән кирәк икән
Аны мин аңламадым.

Туганнарым куеп китқәч,
Газиз җаным торыр инде.
Күземне ачып җибәрсәм,
Йөрәгем ярылыр инде.

Гөнаһларым гафу әйлә,
Бер Ходаем, үзең якла!
Кыраеш атлый еландин
Бер Ходаем, үзең сакла!

Тел ачкычларыңны биреп,
Җавап бирәлсәм иде.
Гөнаһларым гафу әйлә,
Тынычлыкта калсам иде.

**Сабак уку**

Гыйлем өйрәнү фарыз
Һәрбер мөэмин кешегә
Ирләргә һәм кызларга
Гыйлем өйрән син, балам.

Гыйлем өйрән һәрвакыт
Шунда җәүһәр һәм якут
Соңра килер һуш вакыт
Гыйлем өйрән син, балам.

*Иске Мәчәләй авылында Бәхтиева Разия*
*Әхмәдулла кызыннан (1946 елгы) язып алынды*

**Муса**

Раббым Алла, диде Муса,
Җәннәт сиңа булырмы икән?
Сиңа җәннәт булыр булса,
Ата-анаң разый булса.

Раббым Алла, диде Муса,
Җәннәт сиңа булырмы икән?
Сиңа җәннәт булыр булса,
Кыз туганнарың разый булса.

*Иске Мәчәләй авылында Исхакова Миннехәят*
*Әхмәдулла кызыннан (1929 елгы) язып алынды*

**Мөнәҗәт**

Картайган – кайда барыйм, картайдым – кемгә ярыйм?
Яшь гомерем үтеп китте, анысын кайдин алыйм?

Эй, син, картлыгым, ник иртә килдең,
Мин картайганны, син каян белдең?

Яшь вакытларым, кая киттегез?
Картайтып мине әрәм иттегез.

Иртә торгачтан кичләрне көтәм,
Үтте яшь гомерем, килмим, ди, бүтән.

Күпме генә эзләсәм, ком кебек киткән икән.
Исәплим дә исем китә, сиксән сигездә җиткән икән.

Авырыйдыр башларым, түгеләдер яшьләрем,
Унбер бала үстергәнгә авырый аякларым

Якуб пәйгәмбәр кебек, унбер бала үстердем.
Төн буена йокламыйча, аяк үрә күп тордым.

Балалар үстергәндә бер ызба, ишек алдысы да юк.
Хәзер инде өч ызба, балалар берсе дә юк.

Хандилә башлыйм ошбу сүзләрем,
Яткарем булсын, йомсам күзләрем.

Хәмет соңында җәмәх алырга
Салават этәм Рәсүлуллага.

Сезгә, балалар, актык сүзләрем:
Догадан куйма, йомсам күзләрем.

Әҗер шарабын бөркен эчәрбез,
Якты дөньядан бер көн китәрбез.

Якты дөньяда йөреп туймадым,
Туймасам да мин мәңге тормамын.

Булса да авыр дөнья көтүе,
Мөшкел хәл икән ташлап китүе.

Күңелем үсмәде, кулым бармады,
Хәсрәтле уйлар миндә калмады.

Ачып карасам, күзләрем тала,
Барча балалар дөньяда кала.

Тәннәрем зәгыйфь, каты юмагыз,
Кире ка(й)тмамын, ашыктырмагыз.

Юып баглага, кәфен салыгыз,
Күрүче булса, күреп калыгыз.

Ерак ерләрдән күрергә килгәннәр,
Күреп калсыннар, кайтмас, дигәннәр.

Йирләшке алмаган йоклаган кеби,
Уянып китсәм, кара төн кеби.

Йирләшке алмаган, түшәк җәймәгән,
Күлмәк тегелгән алтмыш җәймәдән.

Каберемә чардак корып куегыз,
Агач утыртып дога кылыгыз.

Үләннәр үсәр каберем өстенә,
Иманны булсын каберем эченә.

Китаплар ачып, укып карагыз,
Безләргә карап гыйбрәт алыгыз.

Инде ни языйм, бетте каләмем,
Сезләргә булсын актык сәләмем.

Балакайларым, нурлы йөзләрең,
Күреп туймыйдыр сезне күзләрем.

*Иске Мәчәләй авылында Субеева Рәкыйбә*
*Локман кызыннан (1926 елгы) язып алынды*

**Сабырлык (мөнәҗәт)**

Сабырлыктыр эшнең башы
Сабырлыктыр күңел кошы
Сабырлыктыр иман нуры
Сабырлык бир Тәгал Алла

Сабырлар Җәннәткә керер
Аллаһның рәхмәтен күрер
Сабырсызлар Җәһаннәмдә
Сабырлык бир Тәгал Алла

Сабырга – җәннәтем, диде
Сабырга – дәүләтем, диде
Сабврга – рәхмәтем, диде
Сабырлык бир Тәгал Алла

Сабыр иткән бәндәләрне
Изгеләрдән санаганнар
Сабырлыкның савабына
Китаплардан караганнар.

Шушы мөнәҗәт минем «бисмиллам» да шушы, юлда аббара торган талисман кебек. Моны үземне белгәннән бирле әйтәм. Әби өйрәтте. Әбием бик гыйлем ие, Фатима әби: «Авыр вакытларда яшәдек, сабыр булып кына исән калганбыз» – дип шушы мөнәҗәтне әтә ие.

*Яңа Ярмәк авылында Гафурова Гөлсинур*
*Шәйхрази кызыннан (1953) язып алынды*

**Уеннар, аулак өй**

**«Кыек баш».** Туп буладырие. Чокырлар казыйдырыек. Аны тәгәрәтеп шул чокырга кертәсең. Тупны йоннан – ат, сыерныкыннан ясайдырыек.

**«Клюк»**. Таяк кадыйсың, утыртасың, аннан шуны бәрәсең. 5–6 метр ераклыктан.

*Красный мост авылында Ибраһимов*
*Мөдәррис Зәйдулла улыннан (1938 елгы) язып алынды*

**Ал тирәк, күк тирәк.** Ике якта ике команда. Бер як кычкыра:

– Ал тирәк, күк тирәк,
Сезгә бездән кем кирәк?

Икенче як теге як командадагы бер кешенең исемен атый. Теге кеше бара.

Алар барыбер аны алып калалар, ул биеп килә дә аны ике кулыннан тотып алып урнаштыралар.

**Шешә уены.** Шешә кемгә караса, шул бии, йә җырлый, йә тизәйткеч әйтә.

*Гали авылында Кәлимуллина Нәсимә*
*Мидхәт кызыннан (1963 елгы) язып алынды*

**«Шар таяк» (хоккей).** Шарны имәннән йә каеннан ясый идек. Каенны кайната идек тә кисеп май (дизельный май) эчендә. Төсе матурая, ярылмый. Урманнан эзләп таба идек тә кәкре тамырлы агачны, орешник иде в основном. Боз өстендә уйный идек.

**«Клюк»** уйный идек элекке заманнарда. Бәрәсең дә ава теге нәстә. Биш таяк анда, линиядән чыгарырга кирәк 5 шакмакны (кругляшный). Капка ясыйсың да эченә пушка куясың. Шуларны бәреп чыгарырга кирәк бер бәрүдәме, икеме биш таяк белән. Ерактан бер таяк бәрәсең, тимәсә, бер адым якынаеп, икенче таякны алып бәрәсең, бәреп бетергәнче берәр метрга якыная барасың. Иң якын ара – өч метр. Бара-бара таяк алып ыргытасың, тегеләрне чыгарасың сызыктан. Бер сугуда бишесе дә чыгып китсә, син җиңүче буласың. Иң авыры – «письмо»: дүрт шакмак дүрт почмакта сызык эчендә. Бөтенесен бер катта бәреп чыгарып була, ә менә «письмо»ны юк.

Беренчесе «капка» дип атала, икенчесе – «пушка», өченчесе – «офицер», иң соңгысы – «письмо». Специально шакмак сызалар шулай акбур белән, шуның урталарына болар («капка», «пушка», «офицер», «письмо») бөтенесе сызылган шакмак эченә куелалар уртада, «письмо»гына дүрт почмакка куела. «Письмо»ны да бер бәрүдә чыгаручылар бар иде авылда. Таякның (бәрә торган) озынлыгы белән сызылган шакмакның (дүртпочмак) озынлыгы бер булырга тиеш.

**«Таяк»** уйный идек. Бер бүрәнә, бүрәнәгә такта куела, бишалты чыбыкны башына куя да, бөтенесе янтыкка басалар малайлар, хәзер бер малай йөгереп бара да тактага баса да теге чыбыклар очалар. Кем күбрәк җыя – шул җиңүче була.

**«Чижик».** Такта, тоткычы бар инде, кухонный такта кебек, чижик дүрт яклы, балта белән I, II, III, IV дип язылган, дүрт кырлы. Чижикны еббәрәсең дә такта белән сугасың, барып карыйсың,

нинди сан чыккан: № 4 например, номерларны яза барасың, куша барасың, кем күбрәк очко җыя? Чижик, ыргыткач, «фыж» дип оча, башлары очлы, дүрт кырлы, номерлы була, сызгырып оча. Озынлыгы чижикның 12–15 см. Бәрә торган такта пичкә эпәй тыга торган такта кебек.

Ярмәк авылы 1737 елда төзелә башлый. Казан ягыннан хан нәселеннән бер кеше була. Ул кеше сугыш вакытында патшага хезмәт итә – батырлыгын күрсәтә. Шуның өчен аны җир, крестьян белән бүләклиләр. Аның уллары була. Шул улларыннан Ярмөхәммәт исемлесе безнең авылга килеп утыра. Аның җирләре Бөгелмәдән башлап безнең авылга кадәр була. Шул җирләрен улларына бүлеп бирә. Төп управленияләре Сосновкада була, бу авылда утары - маллары, хезмәтчеләре тора торган була.

Безнең авылга төрле урыннардан күчеп утырганнар, төрле милләт кешеләре. Алар Ярмәккә кергәндә ислам динен кабул иткәннәр дә, аларга җир бүлеп биргәннәр. 1908 елга кадәр авылда язып бару регистрация кнәгәсе булмаган. 1892 елга кадәр авылда укыйяза белүче дә булмаган. Шул еллардан соң Чыршылы авылына (Татарстанга) мәдрәсәгә барып укыганнар. Ә хатын-кызлар 1914 елларда гына укый-язарга өйрәнә башлыйлар.

Ярмәккә беренче пузырь (лампа куыгы) 1887 елларны керә, тегү машинасы да шул еларны гына керә.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллина Әнисәдән (1921 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Бәетләр

### Мужик бәете

Мужик бара басуга,
Ашлыклары ташуда.
Аты арык, йөрмәгәч,
Бер кычкыра, бер суга.

Яңгыр ява кар катыш,
Килеп җитә, килә кыш.
Яланда ямь калмагач,
Һич күренми очкан кош.

Мужик суга чыланган,
Кулына чыбык алган.
Ялкау булган сәбәпле
Ашлыгы соңга калган.

Киләдер бик ачуы,
Акрын атның басуы.
Яңгыр явып торганда
Агар икән ташуы.

Тимерсездер арбасы,
Юкә камыт дугасы.
Бер нәрсәсе ватылса,
Туктап яланда ясый.

Бу бичара интегә,
Бер тугара, бер җигә.
Мең төрле бәла илә,
Барып җитте игенгә.

Ашлыгына су үткән,
Батып төбенә җиткән.
Ашлыкның күбесе
Шул җирдә череп беткән.

Мәшәкать чикте озак,
Арбага төяде чак.
Авыр йөк илә йөрергә,
Юл бүген бик пычрак.

Кеше юк тартышырга,
Аптырап атын суга.
Ат тарталмый торганда
Сынды шарт итеп дуга.

Менеп авылга чапты,
Эзләп бер дуга тапты.
Арлы-бирле йөрегәнче
Халык йокыга ятты.

Ат тарталмый ятканда,
Чыгаралмый батканда,
Иртә киткән бичара
Кайтты чак таң атканда.

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Яхина Фатыйма Али кызыннан (1905 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган*

**Мәрьямкай бәете**

Бер көзге көн, караңгы төн
Фабрикадан кайтканда.
Агуланган Мәрьямкайны
Илтәләр больницага.

Илттеләр больницага,
Салдылар караватка.
Ике доктор бер сестрица
Тырыша коткарырга.

Коткармагыз, коткармагыз,
Мин барыбер үләмен.
Бар рәхәтем, бар михнәтем
Каберемдә күрермен.

Беренче көн килде аңа
Әнкәсе хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Мөмкин түгел керергә».

Икенче көн килде аңа
Дуслары хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Мөмкин түгел керергә».

Өченче көн килде аңа
Булаты хәл белергә.
Доктор аңа җавап бирде:
«Гробныйга керергә».

Ачтылар гробныйны,
Күрделәр кара гробны.
Кара гроб эчләрендә
Ята Мәрьямкай үлеп.

Ач, Мәрьямкай, ач, Мәрьямкай,
Ач, Мәрьямкай, күзеңне.
Ачмасаң Мәрьям күзеңне,
Вафат итәм үземне.

Алды Булат кинжалын
Кадады күкрәгенә.
Мәрьямкайның яннарында
Булат та вафат була.

Җилфер-җилфер җил искәндә
Сәгать унике иде.
Булат белән Мәрьямкайны
Күмеп кайталар инде.

Миннән калган киемнәрне
Кемнәр киярләр икән?
Миннән калган Булатымны
Кемнәр сөярләр икән?

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Канюкаева Миңнекамәр Газиз кызыннан (1928 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган*

**Мәүлет бәете**

Мәүлет әтү бик күңелле,
Ничек аннан кайтырга.
Бай хатыннар гына йөри
Бездә мәүлет әтергә.

Мәүлет әтергә барганда
Матур күлмәк киегез.
Бер җырлый да бәлеш ашый
Мәликә әбиегез.

Югары очта Мәликә әби,
Түбән очта Хәдичә.
Чаллыдан кунаклар килә
Күбесе чакырмыйча.

Анда нинди хәсият бар
Турыга акыралар.
Тавышлары җитешмәгәч,
Бикәне чакыралар.

Бикә шунда үз янына
Нәфисәне чакыра.
Аның тавышы бик калын,
Ул турыга акыра.

Җиек-биек юкәләр,
Мәүлет әтә бикәләр.
Әптекидә бетсә бәлеш,
Күрше авылга китәләр.

Үзенең муртасы бар бит,
Ике кашык бал салган.
Гали карчыгы да бар бит,
Ансы онытылып калган.

Бу бәетне Зулкарнеев Һади үзе чыгарган. «Сугыштан соңгы 1945–1946 елларда авылда икмәкләр уңмаган, авыр елларда бер төркем карчыклар, мәүлет әйтәбез дип, өйдән өйгә бәлеш ашап йөриләр. Шуңарга ачу килде дә бәет чыгардым мин ул “святой” карчыклар турында» ди Зулкарнеев.

*Шенталы районы Әптеки авылында*
*Зулкарнеев Һади Минутдин улыннан (1932 елгы)*
*Х. Гатина язып алган*

## Зөфәр мулла бәете

(I вариант)

Бисмиллаһи вә биллаһи,
Житте корбан гаете.
Без әйтәбез, сез тыңлагыз
Зөфәр мулла бәетен.

И Сәлимәм, и Наиләм,
Ачты капканы берсе.
Йөрәкләрем бик курыкты –
Мин үләрмен ахырысы.

Иртә торып тышка чыксам,
Капкаларым шалдырый.
Илемнән китәсемне белгәч,
Тәннәрем калтырый.

И Наиләм, и Сәлимәм,
Китәм инде мин сездән.
Бер дә китәсем дә килми,
Җәл каласыз сез миндин.

Иртә тордым, битем юдым,
Мулла булдым илләрдә.
Шул укыту хакларында
Корбан булдым илләрдә.

Егет булдым, үткен булдым,
Тимәде җиргә аяк.
Бу укыту хакларында
Булдым илләргә маяк.

И мәдрәсәм, сау бул инде,
Китәм инде мин синдин.
Бер дә китәсем дә килми,
Җәл каласың син миндин.

И, мажиклар, белмәдегез
Бу мескеннең кадерен.
Кыямәт көнне бирелсен
Без мескеннең әҗерен.

Әптекине чыккан чакта
Кул болгадым илемә.
Нәселемне дучар итмә
Әптекинең иленә.

Камышлы суы тирән булса да,
Бүтәкәли шәп ага.
Кемнәр шәфкать итәр икән
Бездән калган балага.

Әптекине чыккан чакта
Карадым мин һавага.
Кемнәр шәфкать итәр икән
Без бәхетсез балага.

Денис илен чыккачтан,
Салдырдылар тунымны.
Инде ерак бармыйбыз дип,
Алдылар котымны.

Алар килә ат белән,
Без киләбез дәрт белән.
Мылтык тавышын ишеткәч,
Йөрәк яна ут белән.

И, ходаем, тәкъдир диеп
Тар сулышлар суладым,
Газиз җаным чыга диеп,
Тәкбир әйтеп җыладым.

И, ходаем, ярдәм бир, дип
Бер ходайга сыгындым.
Җанымның ачысы белән
Мылтыгын тартып алдым.

Бәгъзе булган бәндәләргә
Көн дә бәйрәм, көн дә туй.
Бәгъзе булган бәндәләргә
Көн дә хәсрәт, көн дә уй.

*Келәүле районы Әптеки авылында*
*Тимергалеева Заһирадан (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган, 1965 ел*

**Зөфәр мулла бәете**
(II вариант)

Бисмиллаһи вә билләһи,
Җитте корбан гаете.
Без әйтиек, сез тыңлагыз,
Зөфәр мулла бәете.

Алар бара ат белән,
Без барабыз дәрт белән.
Мылтык тавышын ишеткәч,
Яна йөрәк ут белән.

Денис карьясен кергәч тә,
Тараттылар фатирга.
Ике чәшкә чәй эчәлмим,
Чыгаралар атарга.

Денис карьясен кергәч тә,
Тараталар фатирга.
И ходаем, ярдәмең бит
Туган илемә кайтырга.

Егет булдым, үткен булдым,
Күрдем күп калаларны.
Үземә авыр булса да,
Укыттым балалрны.

Мәдрәсәдәге парталар
Казна белән ясалган.
И Әсгадә, елашмагыз,
Мөкаддиргә язылган.

Минем йортым шау нарат,
Яткан җирем карават.
И Сәлимә, и Наилә,
Булдык инде без харап.

Якупов Зөфәр мулла (Камил Якубның әтисе белән бер туган кеше) Чистайда укып кайткач, Тат. Әбдекәйдә мулла булып торган. 1919 елда аклар кергәч, аны ике комбед члены белән бергә кызыллар ягында булуда гаепләп, Денис авылына илтеп аталар. (Аклар штаты шунда була.) Бәет тулысынча түгел. Мәсәлимов Шәриф бабай сөйләвенчә, аны Зөфәр учитель дип йөргәннәр. Денис авылындагы Гилазеттдинов Гариф бабай үзе күргән, күкрәгенә йолдыз формасында 5 мәртәбә чәнечкәннәр. Әбдекәй авылында мәдрәсәдә кырык бер чыбык суктырганнар. Хатыны Әсгадә, кызлары Сәлимә, Наилә булган.

*Шенталы районы Тат. Абдикеево авылында*
*Мотыйгуллина Фатыймадан (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган*

**Сугыш бәете**

Аклы ситса күлмәгеңне
Анда баргач, киденңме.
Башларыңа бомба төшкәч,
«Алла, үләм», диденңме.

Сандугачлар басып сайрый
Гармун каешларына.
Минем картым үлеп калды
Герман сугышларында.

Үтте гомерем искән җилдәй,
Агым сулардай агып,
Бик авырлыклар күрдем,
Җиде бала белән калып...

*Келәүле районы Балыклы авылында*
*Насырова Вәсиләдән (1900 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Гыйльмикамал бәете**
(мөнәҗәт)

Язгы матур көн етте,
Халык күтә корбан гаетен.
Без укыйбыз, сез тыңлагыз,
Гыйльмикамал матур кыз бәетен.

Садретдин җәмәгатен
Урыс килгән алырга,
Садретдин указ алган:
25 тамга булса, үз авылында калырга.

Язгы матур көннәрдә
Яшәрәдер юкәле тауның усагы.
Тамгаларын бирмиләр,
Ай-һай, илнең усалы.

Атлар җиккән китәргә,
Инде ни хәл итәргә.
Илдән тамга булмаса,
Суд ителгән китәргә.

Гыйльмикамал өзелеп елый
Үз илемдә калам дип.
Әнкәсе дә кушылып елый
Безгә тәкъдир шул, балам, дип.

Гыйльмикамал артында
Чылтырыйдер тәнкәсе.
Гыйльмикамал калыр иде,
Калдырмый бит әнкәсе.

Гыйльмикамал әйтәдер:
Сезгә миндин сәлам дип,
Конвой рус камчы селти,
Баш аркылы салам, дип.

Гыйльмикамал куркуыннан
Утыра алмый арбага.
Гыйльмикамал җылап әйтә:
Бу хәлләрне күргәнче, аксам иде дәрьяга.

Гыйльмикамал карап елый
Суга барган юлларын.
Гыйльмикамал китте илдән,
Үзе елый, үзе болгый кулларын.

Бәет Гыйльмикамалның атасы Садретдин Мотаһир улына багышлап чыгарылган. Патшага каршы килгән өчен аны, авылдан куарга дип, хөкем иткәннәр. Әгәр дә 25 тамга җыя алсалар гына аны авылда калдырырга булганнар. Шуңа күрә авыл буенча йөреп тамга җыялар.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллина Әнисәдән (1921 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Бәет** (ди)

Ничә еллар бу бинада
Ялгыз утыра башым.
Бер савыт су, бер телем икмәк
Иде минем ашым.

Күрмәде һич ике күзем
Якты дөнья нурыны.
Әллә бу зиндан эчендә
Чыгачак газиз җаным.

Чыга торган идемауга
Башыма таҗлар киеп.
Инде таҗ урнына калды
Бу озын кара сачем.

Кайда китте яшь вакытым,
Назлы үскән чакларым?
Йөз-мең алтын тора иде
Минем атланган атым.

Алтын илә бизәгән иде
Минем тәхетләрем.
Инде тәхет урнына калды
Ошбу утырган ташым.

*Шынталы районы Денис авылында*
*Ханнанов Шакирҗаннан (1893 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Бөек Ватан сугышы бәете**

Бисмилла дип башладым
Бу бәетнең башларын,
Башымнан үткән эшләрне
Кыскача яза башладым

Бер мең дә тугыз йөз дә
Кырык беренче елда,
Икенче ноябрьдә
Чыгып киттем мин юлга.

Юл дигәнем, сугышка китү аякларны салдырып.
Җиде балам һәм хатыным михнәт эчендә калдырып.

Военкоматта яздылар «рабочий батальон» диеп,
Күңелем белән һаман уйлыйм, сугыштан котылмам, диеп.

Большанкага барып җиткәч, эшли башладык тагын,
Көн дә 4 чакрым барып казыйбыз танкы базы.

Алтынчы июнь аенда чыгып киттек сугышка,
Шундый авыр моментта да дивана булдым сагышка.

Дупларка авылында 14 көн уйнаттылар,
Унбишенче көн дигәндә сугыш коралы астылар.

Уналтысында чыгып киттек сугышка дип походка,
300 чакырым җәяү баргач, гөрләп яна торган утка.

6 нчы юль аенда Дон буена җиттек без,
9 нчы июльләрдә окоп казып кердек без.

Фатыйх ята передовойның 5 чакырым артында,
Риза белән безнең тормыш немец уты астында.

Автоматым аткан чакта чаткылары ялтырый,
Миналар төшкән вакытта җөмлә тәнем калтырый.

Снаряд килеп төшә дә һавага чәчелә газы,
Төшкән урынына карасаң, мисле бәрәңге базы.

Егерме беренче августа наступление башланды,
Гимнастеркадан бүтән кием бар да юлга ташланды.

Өч көн барды каты сугыш мамонның тауларында,
Коточкыч атыш башлана җәй көне таң алларында.

Мине алдылар передовой ротка, иптәш калды икенче ротта,
Дошман кача бер тукатамый эш беләә бара.

Ранний булып родной кайтты взводный да аның белән,
Яңлыш барып эләктем, ди, егерме сигезендә төн белән.

Безне күргәч тотындылар пулеметтан атарга,
Әйләндек без артка таба, мөмкинлек юк качарга.

Өч яктан да чорнаганнар, якынайды аралар,
Үлгәнебез белсеннәр дип, штатка җибәрәбез.

Исәпләмәгәндә булды бер арудия тавышы,
Дошман өстенә килеп төште, тарала башлады күбесе.

Уңдан, суңдан чигенәләр алдагылары кача,
Орудия өсте-өстенә алар өстенә ата.

Алар бездән ерагайды, без дә туктыйбыз атып,
Орудия күп ярдәм итте, алар беттеләр качып.

Алар качты бездән ерак, без таш коймада калдык.
Алар яткан урыннан ике пулемет алдык.

Койма төбендә утырып җидәүләп сөйләшәбез,
Ничек исән калдык, диеп җыйнаулап егълашабыз.

Бераз сөйләшеп утыргач капитан кычкырды миңа:
«Минапов, иди сюда», – ди, – балгардарность, – ди, синңа.

415 нче полк килде ярдәм итәргә,
Безгә дә приказ килде Грековка китәргә.

Грековка әйләнеп кайттык ротабыздан 10 кеше,
Койма төбендә үлгәннәрне алып киттек 14 кеше.

Вакыйгадан соң 14 көн үткәч, рот заполнять иттек без,
Миллеров шәһәрен алгач, бер туктаусыз киттек без.

Лазавойга барып җиткәч, фронт 50 чакырым алда,
Лазаовойда туктаттылар, сез барасыз дип ялда.

24 февральдә җиттек без Лазовойга,
27 февральдә күп кешебез калды анда.

Лазовойдан 10 чакырым авылга барып кундык,
28 ендә урап алды, шунда дивана булдык.

Самолетлар килеп җитте, бөтен һава каралды,
Бомбить итә, пулемет ата – бөтенебез таралды.

Яңгыр кебек бомба ява, халыклар җиргә поса,
Танклары да килеп җиткән, өч яклап безне кыса.

Бер почмакка кыстылар безне, халык та бик аз калды.
Автомат белән аталар, чыгалмый плен калдык.

Безгә «алт» дип кычкыргач, барыбыз торып тезелдек.
Автоматтан залп бирделәр, җидебез дә егылдык.

Торучыбыз булмагачтан, машина китте борылып,
Өч сәгатьләп шунда яттык, икебез калды үлеп.

Машина борылып киткәч тә, бераз вакыттан булды,
Раннарым да бәйләмәгән, итекләр кан берлә тулды.

Халыкны җыеп бетергәч, Лазовойга озаттылар.
Лазовойга барган чакта 5 кешене аттылар.

Ранний белән исәннәрне бер сарайга яптылар.
Никадәр кычкырсак та, барыбер безне таптылар.

Ике кич юлда кундык без сарай эче су булды.
Бер тамчы ризык капмадык, төгәл 3 тәүлек булды.

Дүртенче көн килеп җиткәч, Лазовой станцага,
Тирә-яктан күп җыелган бөтен пленный станцага.

Немец врачлары килгәч, бәйләделәр ранымны,
Әлләниләр белән әрнетеп, туктаттылар канымны.

Апрельнең 4 сенә кадәр Петровскида калдык,
Унберенче көн дигәндә 100 грамм икмәк алдык.

4 нче апрель аенда озаттылар безне еракка,
Смолага барып җиткәч, яптылар салкын баракка.

Шул салкын баракта ятып өшү үзәккә үтте.
Раннарым да төзәлмәгән, янә тиф бәреп екты.

10 мәртәбә операция булды, һаман төзәлми раным.
Чиргә тәмам аптырадым, калмады кашык каным.

Гел больничта 5 ай яткач, әзрәк йөри башладым.
Тагын ниләр күрер икән минем газиз башларым?

5 ай тулган вакытларда зур врачлар карадылар.
Хәзер эшкә ярар диеп, больничтан чыгардылар.

Үлмәс җанга бер сәбәпче була икән адәмгә,
Иптәшләрем белән киттем Кременчук дигән калага.

Кременчукка барып җиткәч, Зиннәт поварым калды.
Минем кеше булуга да Зиннәт сәбәпче булды.

Бу бәетне чынлап язарга булмады яшел кара,
Тәкъдирдә миңа язганны күрмәенчә ни чара.

Бу бәетне тәмам итеп язмыйм кем икәнемне.
Килешмәсә дә мин яздым агырлык күргәнемне.

Минем область Куйбышев, Шынталы районыннан
Сельсоветым, туган илем, Әптеки авылыннан.

Минабетдин баласы мин, исемем Назметдин,
44 яшемә җиткәч, йөрдем яна торган утта.

Немецкий самолетлар очалар биек һавадан,
Кайгы-хәсрәт күрер өчен туган икәнмен анадин.

Ни кадәр күп язсам да, минем дәфтәрем тулмас.
Минем башымнан үткәнне язып бетереп булмас.

Бу бәетне тәмам иттем 9 нчы апрельдә,
Бер мең дә тугыз йөз дә 44 нче елларда, Львов шәһәрендә.

Бу бәетне Низаметдин Минапов үзе чыгарган, пленда калгач.

*Шенталы районы Әптеки авылында*
*Минапов Низаметдин хатының кулъязмасыннан*
*Х. Гатина күчереп алган. 1965 ел*

**Сугыш**

Ничә еллар үтеп китте аерылганга туган илеңдин,
Без көтәбез һәр көн синдин килерме, дип, сугыш хәтерең.

Күп көтсәк тә зарыгып хәсрәт белән, синең яктан хәбәр килмәде,
Киттең дә шул китүдән югалдың син һичбер кеше белмәде.

Күкрәгеңә килеп керде мәллә каршыңдагы дошман уклары?
Әллә сине таптап юк иттеме җир селкетеп килгән туплары?

Әллә калдыңмы син туп актарган туфрак асларында күмелеп,
Актык сулышларың алмыйча үлдең мәллә хәлдән таеп?

Күкрәк киереп каршы торам дип дошманнардан үчеңне алганда,
Син югалдың чит илләрдә, куркыныч, кызганычлы җирләрдә.

Актык сүзләреңне әйтә алмыйча яткансыңдыр шунда тилмереп,
Кая сиңа анда хәлең сорар кеше, нихәл дустым, дип, кул биреп.

Буялгандыр күзең кан-яшь белән гаҗиз булып соңгы минутта,
Син хәбәрсез югалганнан бирле, шатлык бетте безнең тормышта.

Дошманнарның угы килеп кергәч тәннәреңдән каннар аккандыр,
Җәрәхәтле синең шәриф тәнең җирнең йөзләренә яткандыр.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйззәтуллина Камиләдән (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Зинәтулла бәете**

Җәйнең ямьне чакларында
Герман сугыш башлаган;
Әткәйне үтерер өчен
Герман бомба ташлаган.

Карап җылыйм әткәемнең
Пинжәген, чалбарын да;
Рәхәттә үскән идем
Әткәем бар чагында.

Безнең әткәй чыгып китте
Олауларга утырып;
Әткәемне озаттык без
Күзләргә яшь тутырып.

Безнең әткәй киткән чакта
Кара бишмәтен киде;
«Герман пуләсе тимәсә,
Шаять кайтырмын», – диде.

Әткәемә хәбәр килде
Сугышларга китәргә;
Янамын да көямен дә,
Белмим ни хәл итәргә.

Гыйзатуллин Харис язды
Әткәем, үлгәнеңне;
Кулларыма тотып елыйм,
Әткәй, киемнәреңне.

Безнең янда тирән чокыр,
Кодрәт белән казылган;
Әткәемә кыска гомер
Тәкъдиренә язылган.

Әткәй яткан окопларның
Авызлары тар микән;
Дөнья йөзләрендә булып,
Күрешер көннәр бар микән.

Телеграм чыбыгына
Сандугачлар тезелә;
Шул әткәйне төштә күрсәм,
Үзәкләрем өзелә.

Әткәй миңа күлмәк алды,
«Кызым, киярсең, диде, –
Йә кайтырмын, йә кайтмамын
Сагынып сүләрсең», – диде.

Сандугачның тотар идем,
Тоткач кире очмаса;
Мин дә ятим калмас идем,
Герман сугыш ачмаса.

Җилфер-җилфер җил искәндә
Коела имән кабыгы;
Герман кырлары өстендә
Калды әткәй кабере.

Минем әткәй сугышларда
Җәлләмәгән душасын,
Бу бәетләр тәсбих түгел,
Тулган эчем бушасын.

Биек тауның башларында
Йөри герман куйлары;
Минем әткәй күкрәгенә
Кергән герман пулясы.

Герман безгә сугыш ачкан,
Бу германга ни әйтим;
Әткәемне үтерде дә,
Безне калдырды ятим.

Ал юам елгаларда,
Гөл юам елгаларда;
Ятим калудан авыр хәл
Юк икән дөньяларда.

Аклы ситса күлмәгемне
Әткәй кайткач киярмен;
Әгәр әткәем кайтмаса,
Кемгә «әткәй» диярмен.

Әткәемне армиягә
Алып китте машина;
Бер машина, бер падиша
Җитте әткәй башына.

Әткәем винтовка тотып
Германга каршы барды;
Герман пулясы әткәемне
Ерактан каршы алды.

Әткәй, киткәч, 7 көндә
Сугышка барып керде;
Дүрт ай буена исән йөреп
Бишенче айда үлде.

Әткәемне көтәм әле,
Көтәм әле үлсә дә;
Военкомат өстәленә
Публигы килсә дә.

Әткәемнең әрмиядән
Килде публикалары;
Штык кадап үтергәннәр
Герман жуликлары.

Әткәемне төштә күрдем:
Эримене билендә;
Минем әткәй әллә үлгән,
Әллә калган плендә.

Син, әткәйне, төштә күрдем
Ак күлмәк кигәнеңне;
Кайчан ишетербез икән,
«Мин кайттым» дигәнеңне.

Карлар яуса да бетмәде
Синең баскан эзләрең;
Мәңгелеккә калды безгә,
Әткәй, синең сүзләрең.

*Шенталы районы Денис авылында,*
*сугышта үлгән әтисенә багышлап чыгаручы*
*Гыйззәтуллина Фатыймадан (1925 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Мөнәҗәтләр

### Наданлык турында мөнәҗәт

Яшь чагымда ялкау булдым,
Укымый надан калдым.
Ерактагы кардәшемнән
Бервакытны хат алдым.

Үзем аны танымагач,
Укучы эзләп ардым.
Кардәшемә хат язарга
Тагы шуңарга бардым.

Наданлыкның авырлыгын
Күтәреп йөреп талдым.
Бу бәладән котылыр өчен
Улымны мәктәпкә салдым.

### Карт һәм үлем турында мөнәҗәт

Урмандин бер карт килә утын алып,
Бөкерәеп, күтәрелми, арып-талып.
Бераз килгәч, утынына җиргә куеп,
Кыйшаеп ятты мескен, уйга калып.

Мин бичара, үзем бик карт, үзем ярлы.
Асыравы җиңел түгел бер өй җанны.
Картайдым, гайрәтем юк эш эшләргә,
Бирмәдең тотынырга, Ходаем, малны.

Бу ни эш, и Ходаем, яратканым,
Бер картка бер өй җанны караткның.
Җәй өйгә акча кирәк, кайдан алыйм,
Телимен, һич теләгәнем яратмадың.

Телимен, һич теләгем кабул түгел,
Әллә мин кылдым микән явыз гамәл?
Берәү кичә, берәү бүген үлеп бара,
Килмәде, һич булмаса, миңа әҗәл.

Картның сүзен ишетеп әҗәл килде,
«Хуш, мине ник чакырдың?», дип сорау бирде.
Әҗәлне күргәч, картның коты очты,
Каушады һәм болай дип җавап бирде:

«И әҗәл, бәрәкалла, хуш килдең син,
Үзем ач һәм карт булгач, куәтем ким.
Ятамын, бу утынны күтәрә алмыйм,
Күтәреп җибәрергә чакырдым мин».

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Яхина Фатыйма Али кызыннан (1905 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Яңа мөнәҗәт

Элек патша вакытында
Боек иде күңелләр.
Чыра ягып, киндер сугып,
Әрәм үткән гомерләр.

Кайда барсак, шул урында
Безнең юллар уңмады.
Көне-төне эшләсәк тә
Бер дә рәхәт булмады.

Менә хәзер нинди рәхәт,
Ильич утлары яна.
Колхозда рәхәт яшибез
Нужа күрүләр кая.

Яшьләр һәм картларга
Тормыш хәзер рәхәт.
Безгә мул тормыш бирүче
Партиягә зур рәхмәт.

*Камышлы авылында Зәйнуллина Кәримәдән*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Мәзәкләр

Чуваш побыннан сорыйлар:

Батюшка оҗмахка кем керә, татармы, чувашмы?

– Әлбәттә, чуваш, – ди батюшка, – чуваш оҗмахның түрендә утырачак.

– Ә татар? – диләр.

– Татар ишек төбендә торачак.

– Ә, алай булса петте инде, татар ишек төбендә генә калмый ул, – дигәннәр.

* * *

Билгеле инде, чувашлар ат яраталар. Берсенең сарайда айгыры була. Бу айгырны урларга йөрүләрен белеп, агай арба астына кереп ята. Караклар төнлә килеп атны урлап чыгалар. Кайткач бу сөйли икән:

– Йөрәк пар та пар икән үземдә. Яшь чак, кулда пычак, болар капканы ачтылар, атны җиктеләр, алып киттеләр. Һич курыкмадым, карап калдым, – ди икән.

* * *

Камышлыда бер агайга рус танышы керә. Чәй әзерләргә ашыкмыйлар. Шактый торгач, кунак китә башлый. Ишектән чыккач, хуҗа:

– Чай пить надо бы, – ди. Хатыны аны төртеп:

– Кая ашыгасың, капканы чыккачрак әйтерсең, – ди.

* * *

Берәү базарга сарык сатарга бара. Арбасы ава. Бер рус килеп сорый: Почем овца? – ди.

– Ауса, синең ни эшең бар, – ди бу. Базарда сатулаша башлый.

– Рупь сорак дам, – ди берәү.

– Урып-суырып ук алмакчысың, кит моннан, – ди. Икенчесе килеп 80 тиен биргән, шуңа саткан.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбаннан (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Бер мулла шәһәргә бара. Икенче кеше артыннан куып җитә дә, сәдака бирә. Мулла аңа кыска гына дога укый да, китеп бара. Тагын бер кеше килеп сәдака бирә. Анысына озак итеп дога укый.

– Хәзрәт, – ди теге кеше, – нигә син аңа доганы озак укыйсың, минекенә битеңне генә сыпырасың?

– Синекен Хода тәгалә тиз генә алып китте, моныкы күбрәк, авыррак иде, Алла аны бик озак алып китә алмый торды, көчкә озаттым, – ди.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Әһлиулладан (1889 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Бер кызны кияүгә ярәшәләр. Рамазан ае кергән була. Рамазан узмыйча, никах укырга ярамый. Бер көнне суга бара бу кыз. Су буенда бер эт сузылып яткан була. «Бүре кыргыры, рамазан ае кебек сузылып яткан бит», – ди икән теге кыз.

* * *

Бер карчыкның тиле-миле улы булган. Бер көнне әби чормага каз элә дә, улына әйтә:

– Бу – рамазанга, тимәгез, рамазан килгәч, ашарбыз, – ди. Бервакытны үзе өйдә югында боларга бер кеше килә.

– Син ни атлы, ди малай.

– Рамазан, – ди теге.

– Ә, алайса сиңа дип хәзерләгән казыбыз бар безнең, дип, Рамазанга каз ашатып чыгара.

* * *

Бер кияү бикәченә бара. Бабаларының өен тапмый.

– Кая тора иде соң ул? – дип сорыйлар моннан.

– Өе янында кара сыер ята иде, бер кузла тора иде, – дигән бу.

*Шенталы районы Тат. Абдикеево авылында*
*Нуркаева Оркиядан (1916 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган*

* * *

Кәрим бабай чуваш кызын өшкерә:

«Күк югары, җир түбән,

Бетмәең йөзтүбән», – ди.

Кыз татарча аңлаган була.

«Кәрим пабай, зинһар өчен, петмим инде мин» – дигән.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Хәсәншин Хатыйп Җиһанша улыннан (1924 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

* * *

Сугыштан соң ипи юк вакыт. Кәрим абзый бер бай гына чуваштан ипи сорарга бара. Теге бирми. Кәрим абзый ничек тә алырга була.

– Ярый, Алла кайтарыр әле сиңа да, – ди. Чувашның күптән түгел генә улы үлгәнен белеп китә бу.

Бер төнне килеп, чувашның тәрәзәсен шакый.

– Кем анда?

– Бу мин, улың Иван. Теге дөньядан кайттым. Мине анда бик кыйныйлар. Син бер татарның хатынын обижать иткәнсең икән. Шуңа бүген үк ипи илтеп бир, – дип китә бу. Чуваш иртән ат белән үк илтеп бирә ипине. Кәрим абзый:

– Менә бит, Алла үзе китертте синнән, – ди.

* * *

Бер көнне күрәләр: охранник аягына бияләй киеп өенә чаба.

– Ни булды?

– Итекне салдырганнар, – ди имеш.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Нигъматуллин Сәлимҗаннан (1929 елгы)*
*Ф. Әмирханов язып алган. 1965 ел*

Җеннәрдән бик курка торган бер малай иптәшләреннән соңгарак калып, бер әрәмәлеккә ат сакларга куна китә. Ялгыз кунарга ни хәтле генә курыкса да, нишләсен, куна бу. Куркуыннан башын чикмәне белән урап ята, йоклый алмый. Менә бер заманны якынаеп килгән аяк тавышы ишетелә. Моның йөрәге чыгарлык була инде куркуыннан, ул аны шайтан дип белә. «Шайтан» моның баш очына килеп баса да малайның өстендәге чикмәнен ачып ташлый. Малай күзләрен ачып карарга куркып бик озак яткач, күзенең бер кырые белән генә караса, янында үзләренең колыны басып тора икән.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбәннән (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Бер карчык киявенә әйтә икән:

– Әй, кияү, мин инде театрга да, кинога да йөрмим, телевизор алып кайтып бирсәң, ярты гомеремне бирер идем, – дип.

Шул сүзләрне ишеткәч, карчыкның кияве икенче көнне үк ике телевизор алып кайтып куйган, ди.

* * *

Элек бер кеше командировочный справкага кул куйдырырга дип авыл советына барган. Председатель грамотасыз икән. Секретаре «Председатель грамотасыз булган өчен кәтибе бармагын баса», – дип, баш бармагының бите белән подпись урынына тамга ясап җибәрә.

* * *

Мәчеткә җыелганнар да, мулла:

– Җәмәгать, мәчеттә никогда урысча сөйләшергә ярамый, – дигән.

– «Никогда» урыс сүзе ич, – дигәннәр.

– Анысы гына ничево инде аның, – дигән мулла.

* * *

Бер кешенең өч улы булган. Болар өчесе дә гармунда уйнарга өйрәнәселәре килгән. Гармунны сатып алганнар, куярга урын һич таба алмыйлар икән. Болар гармунны мунча пиченә илтеп тыкканнар.

Бер вакытны аталары мунчага барган икән, пичтә нәрсәдер кыдр-кыдр итә. Бу «мунча пичендә җүнле әйбер булмас», дип, таяк алган да төртә икән. Төрткән саен кырр-кырр итә икән. Бу озак кына төрткән дә карчыгына әйткән: «Карчык, мин мунчада пәри үтердем әле» дип. Улы бу сүзне ишеткәч, «И, хәрап иткәнсең икән, 18 лат икмәк урлап кына алган идем», – дигән.

Шуннан соң бу кешеләрне «пәри үтерүчеләр» дип йөртә башлаганнар.

* * *

Әби кызы белән киявен сыйлап утыра икән. «Кызым, аша, аша. Киявем, син дә капкала», – ди икән.

* * *

Бер кияү бабаларына кунакка килгән. Китми икән бу һаман, Бабаларының җибәрәселәре килә икән. Бабасы:

– Кияү, сезнең башта пожар булган. Сезнең өй нишләде икән? – дигән.

– Әй, алай булгач, анда кайтып та торасы юк икән, – дип түргә үк менеп утырган, ди.

* * *

Бер чуваш төшендә кесәл күргән, ашарга кулында кашыгы булмаган. Икенче көнне «кесәл булса, ашармын» дип янына кашык алып яткан икән, төшендә кесәл күренмәгән. «Бу минем кашыктан курыкты инде» дип кычкырып-кычкырып:

«Кесәл-месәл кил инде,
Чупырмала чук кулда», –

дип ята икән.

* * *

Берәү әйткән: «Кырык Алдарны, алдый-алдый, дип әйтәләр, мине алдый алмый ул» дип. «Тукта әле мин аның янына барып килим» дип китә бу. Бу килгәндә Кырык Алдар бер стенаны терәтеп тора икән.

– Сине алдый дип әйтәләр, мине дә алдап кара әле, – дигән.

– Алдар идем дә бит, алдар капчыгым өйдә калган, – ди.

– Соң, бар капчыгыңны алып кил, – ди теге кеше.

– Китәр идем дә, стена ава бит, – ди.

– Бар, барып кил, стенаны үзем терәтеп торам, – ди.

Теге стенаны терәтеп кала, Алдар кайтып китә. Көтә-көтә бу Алдарны – һаман килми дә килми икән.

Менә берзаманны кешеләр базардан кайтып килә икән.

– Нишләп торасың монда, – диләр.

– Менә Кырык Алдарны көтеп торам, алдар капчыгын алырга киткән ие, – дигән.

– Әй, ул әллә кайчан базарда йөри инде, синең белән эше юк аның, – диләр.

Шулай итеп Алдар моны да утыртып киткән, ди.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*китапханә мөдире Әхмәдуллин Сәүбәннән (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Алла утырткан, ди, виноград. Ул бит инде болай гына үсми, сугарырга кирәк. Болар, иң элек, суялар тәкә, шуның каны белән виноградны сугаралар. Виноград шул кадәр үскән, ә чәчәк атмаган. Суйганнар – маймылны. Аның каны белән сугарганнар икән, чәчәк аткан, җимеше булмаган.

Инде суйганнар дуңгыз, аның каны белән сугарганнар икән, виноград чәчәк тә аткан, җимеш тә биргән, җимешеннән аракы да ясаганнар.

Шуннан бирле кешеләр бер стакан вино эчкәч, тәкә шикелле көчле булалар икән, икенче стаканны эчкәч, маймылга әйләнәләр, ә өченче стаканны эчкәч, дуңгыз кебек ауный башлыйлар, ди.

* * *

Бер карт клубта галошын югалта, эзләргә электр уты булмый, караңгы була. Кайтып китә дә шулай. Бераз баргач, урам баганасында ут яна икән, шул багана төбеннән эзли башлый бу. Узып баручы: «Нәрсә эзлисең?» –диюгә, «Галошым югалды, шуны эзлим», – ди. «Соң кайда җуйган иең?» – ди.

– Клубта, – ди.

– Алай булгач, ник клубта эзләмәдең соң? – ди.

– Анда ут юк ие бит, монда ут бар, якты, шуңа эзлим, – ди.

* * *

Оҗмахта бер чуваш часовой булып тора. Бөтен милләттән дә: урыс та, татар да керә инде. Һәммәсенә берәр төрле эш тә табалар шунда. Бер чуваш соңга калган икән, оҗмах ишеген кага бу:

– Ач әле, ач, – ди,

– Кем соң син? – ди часовой.

– Чувашың, – ди.

Часовой начальникка барган, ди,

«Берәү ишек кага, чувашың дип әйтә, кертимме, – ди.

Керт инде үзебезнең кеше булгач, идән-сәке юар шунда, – ди.

*Шынталы районы Денис авылында*
*Нигъмәтуллина Сәлимәдән (1929 елгы)*
*язып алынган. 1965 ел*

Бер укытучы укучыларга: «Балалар тәмәке тартырга, аракы эчәргә ярамый. Тәмәке тартмаган, эчмәгән кешенең гомере озын була, – ди. – Мин сезгә бер кешене күрсәтәм, ул үз гомерендә тәмәке дә тартмаган, аракы да эчмәгән, шуңа күрә 130 яшькә хәтле яшәгән, әле дә таза» – дигән.

Җыелып киткәннәр болар карт янына. Барып керәләр. Сөйләшеп утырганда күрше бүлмәдән тавыш ишетелә.

– Бабай, анда кем бар соң? – ди бер укучы.

– Әй, анда минем абыем тора, – ди. – Аңа хәзер 150 яшь, эчкән дә тавыш куптарган, – ди.

* * *

Бер әби юлга чыга да, кулын күтәреп, бер машинаны туктата да: «Шынталыга барам, утырт әле, улым», – ди. «Утыртам, только 5 тәнкәлек урынга утырасыңмы, 3 тәнкәлеккәме. Алда 5 тәнкә, арттагы урыннар 3 тәнкә», – ди. «Әй, ярар миңа 3 тәнкәлек тә» – дип артка менеп утыра. Машина буш була, карчыкны әле алгы урыннарга, әле артка чөертеп кенә йөртә.

Килеп җиткәч, әбидән сорыйлар:

– Әби, ничек килдең, соң, – дип.

– Әй, шундый рәхәтләнеп килдем, әле 5 тәнкәлек урынга барып утырам, әле 3 тәнкәлеккә, ярты юлымны бушка килдем, – дигән.

*Шынталы районы Денис авылында*
*Нурмөхәммәтов Равилдан (1931 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Сюжетлы җырлар

### Һаваларда очкан аккошлар

Һаваларда очкан аккошларның
Канат очы алтын боҗыра;
Син дә, бәгырькәем, исемә төшсә,
Төнге йокыларны качыра.

Һаваларда очкан аккошларның
Авызлары тулы балавыз;
Язлар да гына үтә, кыш та үтә,
Яшьлектә кавыша алмый калабыз.

Һаваларда очкан кошларның
Канат очкайлары ак аның;
Тавышлары моңлы, йөзе сары
Чит илләрдә йөргән баланың.

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Булатова Шәмсенурдан (1902 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Һаваларда очкан ерткыч кошлар

Һаваларда очкан ерткыч кошлар
Алар китә җылы якларга;
Һәрвакытта сезне уйлап йөрим,
Мөмкин түгел аяк атларга.

Һаваларда очкан ерткыч кошлар
Кереп югалалар болытка;
Һәрвакыт бергә булып булмый,
Аерылгач та безне онытма.

Сандугач очты, күрдегезме,
Һаваларга менеп киткәнен?
Белдегезме, дуслар, сиздегезме
Яшь гомернең узып киткәнен?

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Яхина Фатыйма Али кызыннан (1905 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Илне сагыну җыры

Яшьләремне түгеп еласам да,
Беркем дә карамый кызганып.
Чит илләрдә йөрим мин
Сызланып.
Кайта алмыйм, туган ил, мин сиңа,
Дөнья өзгән безнең лә араны.
Беткән юл.
Туган-үскән ил генәм, исән бул.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Сәләхова Миңнисадан (1912 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Маһисәрвәр, ай сылуым

Биек-биек кенә ызбаларда, Әсмабибекәй,
Чигү чигә кыз бала, Маһисәрвәр, ай сылуым,
Чигү чиккән генә кыз баланы, Әсмабибекәй,
Ходай бездән кызгана, Маһисәрвәр, ай сылуым

Биек тә генә тауның ай башына, Әсмабибекәй
Майлап куйдым өч арба, Маһисәрвәр, ай сылуым.
Бер генә көннәр дә тотмас идем, Әсмабибекәй,
Юк канатым очарга, Маһисәрвәр, ай сылуым.

## Озын җыр

Су буена чыгып мин карасам,
Урал тавы тора күгәреп.
Шул тауларга карап мин җырлыймын,
Уйларымны еракка җибәреп.

Сәхрәләргә чыгып эзләп таптым
Ай яныннан Зөһрә йолдызын.
Төрле авырлыклар килә миңа каршы,
Ләкин җиңә алмас ил кызын.

## Аккошым

Берәмләп-берәмләп йолдызлар калкалар,
Йолдызлар йөрәкне югары тарталар.

Ашкына йөрәгем, кем өчен, ни өчен,
Син генә беләсең, алтыным, көмешем,
Син генә, син генә, шатлыгым, сагышым,
Хәйләсез тигезем, син генә, аккошым.

*Келәүле районы Камышлы авылында*
*Зәйнуллина Кәримәдән (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

**Туганаем, туктале**

Әй ал чәчәк, ал чәчәк,
Ал чәчәк эчләрендә гөл чәчәк.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.

Минем сөюләрем артыграк,
Мыскылларга салып үлчәсәк,
Туганаем, туктале,
Туганаем туктале,
Сайрашыйк әле.

Ятар идем, йоклар идем,
Сандугачлар басмада.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.

Җырлар хәсрәтне тарата
Януны басмаса да.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.

**Әкрен кирәк, ипләп кирәк**

Арыдым да мин утырдым,
Биек тау битләренә шул.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк,
Ишетергәе сандугач сайрауларын.

Без түгел, кошлар моңая
Кайтырга илләренә.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач тавышларын.

Өй артына гөл утырттым
Бәхетемне сынарга.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Сынды гөлем, юк бәхетем,
Агам язгы суларга.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Граммофонның тәлинкәсе
Әйләнеп уйнар инде.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Ай дусларым, күңелләрем.
Гел сезне уйлар инде.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Анна Ивановна (1911 елгы),*
*Тазова Мария Фоминичнадан (1907 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

**Агыла агым су**

Уй уйлата, уй уйлата,
Уй бит ул уелдыра
Агыла агым су,
Каршы йөзәлми,
Күрми түзәлми.

Тормыш бит ул яшь гомернең
Чәчкәсен калдыра.
Агыла агым су,
Каршы йөзәлми,
Күрми түзәлми.

Аякларым талмас микән,
Агыйделне буйласам.
Агыла агымсу,
Каршы йөзәлми,
Күрми түзәлми.

Һушларымнан язмам микән,
Ялан сезне уйласам.
Агыла агым су,
Каршы йөзәлми,
Күрми түзәлми.

**Уйнасак та үтәр, ай бу гомер**

Уйнасак та үтәр, ай бу гомер,
Җырласак та үтәр бу гомер.
Казански Русия дә, Румбирский гөбирна,
Табабыз да бетерәбез, ничу безгә говорить.

Атларымны җигеп юлга чыксам,
Саный-саный барам маякны.
Казански Русия дә, Румбирски гөбирна.
Табабыз да бетерәбез, ничу безгә говорить.

Сез туганайларым искә төшкәч,
Җылый-җылый киенәм аякны.

Казански Русия дә, Румбирски гөбирна,
Табабыз да бетерәбез, ничу безгә говорить.

*Keләүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Анна Васильевнадан (1913 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

**Туганаем, гөлгенәм**

Аллар да булыйк ай без икәү,
Гөлләр дә булыйк ай без икәү.
Туганаем, гөлгенәм,
Чәчәккәй гомерләр
Килә икән бер генә.

Аллар да алышып, гөлләр бирешеп,
Тату гына йөрик без икәү.
И туганаем, гөлгенәм,
Чәчәккәй гомерләр
Килә икән бер генә.

Ап-аккайлар салдым әрҗәгә,
Шәүләләре төште дөньяга.
И туганаем, гөлгенәм,
Чәчәккәй гомерләр
Килә икән бер генә.

Безләр дә ашыйк, безләр эчик.
Үлгәч кайталмамбыз дөньяга.
И туганаем, гөлгенәм,
Чәчәккәй гомерләр
Килә икән бер генә.

**Җырлый да гына җырлый без эчиек**

Җырлый да гына җырлый без эчиек,
Болар бал эчә шул, дисеннәр.
Безләр дә ашыек, без эчиек,
Болар бертуганнар, дисеннәр.

Ай күкебез инде, айлар күкебез,
Күкебездә ике лә шул ай күзебез.
Бер дә беребездән аерылмасак,
Тилмерәдер ике лә ай шул күзебез.

**Атым керми тирән елгага**

Ай? жырлап ла жырлап без карыйк,
Килешер лә микән көебез.
Атым керми тирән елгага,
Риза булам үләргә.

Килешерләр булса көйләребез,
Ялан шулай бергә йөрербез.
(Ник килешмәсен безнең көебез,
Бергә уйнап үстек үзебез).

Бадыяннары чәчәк аткан чакта
Йөрсәк иде елганың буенча.
Атым керми тирән елгага,
Риза булам үләргә.

И жаннарың сөйгән ярың белән
Торсаң иде гомер буена.
Атым керми тирән елгага,
Риза булам үләргә.

**Ап-пакай, алмакай**

Без алай түгел идек,
Без болай түгел идек.
Ап-пакай, алмакай,
Без болай түгел идек.

Жыен иптәш жыелганда
Жырлаша торган идек.
Ап-пакай, алмакай,
Жырлаша торган идек.

Әйттерәләр түгелме,
Сүттерәләр түгелме.
Ап-пакай, алмакай,
Сүттерәләр түгелме.

Әйттерсеннәр, сүттерсеннәр,
Безнең туганнар түгелме.
Ап-пакай, алмакай,
Безнең туганнар түгелме.

**Түтәл генә түтәл мәгем бар**

Түтәл генә түтәл, әй, мәгем бар,
И мәгем араларында, ай, гөлем бар.
Сезгә жырламыйча, кемгә жырлыйм,
Сездән якын минем лә кемем бар.

И ал кирәкми безләргә, и гөл булгач,
Ят кирәкми безләргә, әй, сез булгач,
Быел килде безләргә, әй, авырлык,
Алла бирсен инде лә шул сабырлык.

**Җырлый җырлый уклар юндым**

Җырлый да гына җырлый уклар юндым,
Сырлауларын үзләрең шул, ай, сырларсың.
Шушы җырымны син отып кал,
Мине сагынганда шул, ай, җырларсың.

Ай сөрмәле сырлар, сөрмәле,
Сөрмәләре беткәч, сөт кебек.
Ай синең өчен минем җаным
Өзеләдер нечкә җеп кебек.

**Әлүк, бәлүк итмә, тирбәтмә**

Чушма буенча ла йөргән чакта
Алтын тәңкә таптым, әлләли.
Әлүк, бәлүк итмә, тирбәтмә,
Җаның сөйсә, болай тилмертмә.

Алтын тәңкә зурлар мал түгел.
Бер күрешүләре әллә ни.
Әлүк, бәлүк итмә, тирбәтмә,
Җаның сөйсә, болай тилмертмә.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Устинья Степановнадан (1890 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

**Агым суның башы бормалы**

Туганнарым инде и әлләрем,
Беләмесез минем хәлләрем.
Агым суның башы бормалы,
Кашы кара, күзе сөрмәле.

Белерлек булсагыз ай хәлләрем,
Ярып бирер идем җаннарым.
Агым суның башы бормалы,
Кашы кара, күзе сөрмәле.

Урманнарга барсам, исем китә
Аклангагы кызыл чәчкәгә.
Агым суның башы бормалы,
Кашы кара, күзе сөрмәле.

Туганнарым, сезгә өлеш куям
Алтын саплы көмеш гәрнәгә.
Агым суның башы бормалы,
Кашы кара, күзе сөрмәле.

**Гайниҗамал**

Сандугачлар идем лә шул, мин илемдә, Гайниҗамал.
Сайрый торган идем шул, ай дустым, ай илемдә.
Сандугачлар кебек сайрый, сайрый, Гайниҗамал,
Бик саргаям йөргән, ай дусларым, җирендә.

Ятма Җаекның ук ярларына, Гайниҗамал,
Җаек ярларны, ай дусларым, су алыр.
Кушмыйк башларны шул усалларга, Гайниҗамал,
Газиз башларның ла шул, ай дусларым, югалыр.

**Ай, җем-җем карыйсың**

Урдалы урамы озын урам,
Почтовыйлар уза туктамый,
Ай, җем-җем карыйсың,
Күп серләргә ярыйсың.

Син, җаныкаемны, уйлый-уйлый
Күп төннәрем үтә йокламый.
Ай, җем лә җем карыйсың,
Ай-һай, җем-җем карыйсың,
Күп серләргә ярыйсың.

**Су юлы**

И әлләрем инде әлләрем,
Беләмесез минем хәлләрем.
Ай-һай мәллә су юлы,
Сагындырды бу юлы.

Белер булсаң минем хәлләрем,
Ярып бирәм ярты җаннарым.
Ай-һай мәллә су юлы,
Сагындырды бу юлы.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Архипов Павел Михайловичтан (1908 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Асылъяр, сандугач

Йөгереп үк төштем инеш, дип,
Инеш буйларында җимеш, дип.
Асылъяр, сандугач,
Сагынып килдем, ишек ач.

Урдалы буеннан ярлар сөйдем,
Нәселегез асыл имеш, дип.
Асылъяр, сандугач,
Сагынып килдем, ишек ач.

Ай-һай Урдалының кызлары,
Аклы яулык бәйли үзләре.
Асылъяр, хуш инде,
Аерылулар шушы инде.

Энҗеләрдән үк ак тешләре,
Сайланып ук чыга сүзләре.
Асылъяр, хуш инде,
Аерылулар шушы инде.

### Алма килә яшел яшнектә

Йөредеккәй микән берләр вакыт,
Тал гынадан басма салдырып.
Алма килә яшел яшнектә,
Әйттереп үк калыйк яшьлектә.

Йөрсәк йөрибез чын күңелдән,
Без йөрмиек хәтер калдырып.
Алма килә яшел яшнектә,
Әйттереп үк калыйк яшьлектә.

Киң кырларның кызыл чәчкәсен
Өзеп кайтыр идем өемә.
Алма килә яшел яшнектә,
Әйттереп үк калыйк яшьлектә.

Ай-һай, туганаем, сезгә әйтәм:
Кушылыгыз минем көемә.
Алма килә яшел яшнектә,
Әйттереп үк калыйк яшьлектә.

## Маруся, Маруся

Ындыр артларында туера,
Кискән генә саен куера.
Маруся, Маруся, милая моя.
Шыңгыр-шыңгыр әле су ага.

Карагызчы безнең туганнарга,
Калҗалатин турап туйдыра.
Маруся, Маруся, милая моя,
Шыңгыр-шыңгыр әле су ага.

*Keләүле районы Назаровка авылында*
*Алексеева Вера Васильевнадан (1919 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Каратай

Ай-һай, такыясын талга элеп,
Тал тибрәтә, диләр, кыз бала.
Җирләрен-суларын ташлап киткәч,
Җирсәп елап, диләр, кыз бала.

Ак та Иделләргә аулар кордым,
Мин белмәдем кама барларын.
Ямьле Каратайның буйларыннан
Табалмадым үземә парларын.

Уникедән үргән чәч толымым
Каратай буена тозакка.
Каратай буенда буй үстердем
Килеп китәрләргә кунакка.

*Keләүле районы Назаровка авылында*
*Макарова Анна Васильевнадан (1913 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Иске карурман

Кара да гынай урман, елга тирән,
Елгаларга атлар төшмидер.
Еллар гына озак, юллар ерак,
Дус-иш белән гомер үтмидер.

Ап-ак та гына каен, ап-ак каен
Яфракларын яра ел саен.
Атна да гына димим, ай да димим,
Мин сагынам сине көн саен.

**Ай, дусларым**

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,
Карадым суларның төбенә, ай, дусларым,
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганын күрми чара юк, ай, дусларым.

Биек тә генә тауның, ай, башында
Ак каеннар эзли ак җирне, ай, дусларым.
Тәкъдир каләмнәре бездә булса,
Болай язмас идек тәкъдирне, ай, дусларым.

Нужадыр, дусларым, ай, нужадыр,
Яшьне нужа буйга сузадыр, ай, дусларым.
Нужаны да күрсәң күр яшь чакта,
Яшьлек белән бергә узадыр, ай, дусларым.

Шыбыр да гына шыбыр яңгыр ява,
Ник боекмый боланның баласы, ай, дусларым.
Хәсрәт тә нужалар күрмиенчә,
Һич тә булмас ата баласы, ай, дусларым.

**Кыз елату җырлары**

Кайниш йорты кабыктыр,
Кабык булса да, тәмуктыр,
Атаң йорты саламдыр,
Салам булса да, сарайдыр.

Кизиле дә чаршау, комач бау,
Кор дисәң, кормам, әнкәй.
Атларым җиккән, вәгадәләшкән,
Тор дисәң дә, тормам, әнкәй.

Суда йөзгән балыкмын,
Табадагы коймакмын.
Өндәп алсаң, әнкәй,
Елына бер кунакмын.

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Гафурова Мәсхүдәдән (1937 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Зимагурлар җыры**

Зимагурның киеме
Әләмә дә сәләмә;
Пекарняда калач күрсә,
Күз кабыгы әләнә.

Зимагурлар үгә кайта
Крахмаллы күлмәктән;
Зимагурлар оныткannар
Чәй эчкәнне чүлмәктән.

Зимагурлар брюка кия
Машинада тектереп;
Зимагурлар узел тага,
Нечкә билен бөктереп.

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Ихсанова Ләтифәдән (1900 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Ике килен**

Бу киленең бик уңган,
Сусыз самовар куйган.
Самовары эреп аккан,
Иркенләп яны тынган.

Ике килен икәүләшеп
Чумара пешергәннәр,
Карап торып ашларына
Таракан төшергәннәр.

Әй, эт өрде, эт өрде,
Тышта берәү йөткерде.
Киленемнең кабартмасы
Тамагымны бетерде.

Нигә болай тикшерәсең?
Тикшерүеңне ташла.
Минем ашлар ошамаса,
Үзең пешереп аша.

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Галимуллина Зөләйхадан (1932 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел.*

**Биек тә тауның, әй, башына**

Биек тә тауның, әй, башына
Байлар чәчкән бохарның тарысын.
Сагынмыйсың, дип әйтсез.
Йөземә чыккан сагыну сарысы.
Алай дими, болай булмады,
Ике күзем күреп лә туймады.

Һаваларда очкан, әй, асыл кош,
Авызында сары ла балавыз.
Сагыну хәле бигрәк авыр,
Бик сагынып өзелеп калабыз.
Ары барма, дуслар, кил бире,
Барча эшләр Ходайның тәкъдире.

Зәңгәрле күлмәк, әй, зәңгәрле
Үтәләй ук күренәдер тәннәре.
Озата чыктым, суырып үптем.
Әле дә бетми авыздан тәмнәре.
Өзелә үзәк җиләр үк искәндә,
Бик сагынам исемә төшкәндә.

*Келәүле районы Балыклы авылында*
*Фәтхетдинова Хәйтелвафдан (1887 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Юкәлеләр тавы**

Сайрый ла сандугач баласы,
Сайрый алмый талсыз да далада;
Күгәрчен, үтә гомерләрем лә шул, сизәмсең.
Минем ялгыз яшь гомерем
Үтәр микән шулай заяга;
Күгәрчен, үтә гомерләрем лә шул, сизәмсең.

Сагынам туган-үскән илем,
Әллә кай төшләре илә
Ямьле, ди, сөямен,
Шул илемне уйлыйм да көямен.

Өй артында яшел агач,
Анда сайрый сандугач;
Күгәрчен, үтә гомерләрем лә шул, сизәмсең.

Бу дөньяның ни яме бар,
Читтә тилмереп торгач,
Күгәрчен, үтә гомерләрем лә шул, сизәмсең.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әһлиуллина Гыйльмеруйдан (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Ак бүрек**

Мендем мәчетләрнең миннәр башына
Мәчет манарасын сырларга.
Ак бүрек,
Ак бүрегем кар кебек,
Әйтер сүзем бар кебек.

Җакшы адәмнәр килгән җырлар тыңларга,
Нинди җырлар сезләргә җырларга.
Ак бүрек,
Ак бүрегем кар кебек,
Әйтер сүзем бар кебек.

Бурый гына бурый карлар да җауса
Боекмыйдыр болан баласы.
Ак бүрек,
Ак бүрегем кар кебек,
Әйтер сүзем бар кебек.

Ичбер нужаларны күрмиенче
Ирләр булмый ата баласы.
Ак бүрек,
Ак бүрегем кар кебек,
Әйтер сүзем бар кебек.

Әй, уй башлар инде уй башлар,
Акыллырак атлар жул башлар.
Ак алмай,
Уйнаганны, көлгәнне
Кайтып әйтмә анаңа.

Җакшы аталарның, әй, балалары
Җалан гыйбрәтле сүз башлар.
Ак алмай,
Уйнаганны, көлгәнне
Кайтып әйтмә анаңа.

**Әй, ямьне безләрнең җөргән җир**

Җилләй генә, җилләй лә шул җөргән чакта,
Әй, ямьне безләрнең җөргән җир.
Җилләр дә ачты минем, әй, куйнымны,
Инде генә шөкер лә, дигәннәр чакта ла.
Әй, ямьне безләрнең җөргән җир
Дошманнар кыйды минем лә, әй, муенымны.

Җилбер генә җилбер лә шул, шул, әй, җилбер чук,
Әй, ямьне безләрнең җөргән җир.
Ник җилберди икән лә, әй, җил дә җук,
Әй, җаннарым сөеп лә шул сөйгәннәрем.
Әй, ямьне безләрнең җөргән җир,
Әй, уянып китсәм, шул ла җанда җир.

**Әлләли**

Ямьне лә болытлар, әй, киләдер,
Җаусын ие безнең болынга.
Әлләли,
Сайрашыйк әле дөнҗа калләрен,
Ниләр булганын.

Ашап кына эчеп лә җөрерләргә
Җазсын ие гомер буена.
Әлләли,
Сайрашыйк әле дөнҗа калләрен,
Ниләр булганын.

И атларым инде, атларым,
Атларым арасында чаптарым.
Әлләли,
Сайрашыйк әле дөнҗа калләрен,
Ниләр булганын.

Рәхәт көннәр килеп җиткәч кенә,
Үтеп китте җәшлек чакларым.
Әлләли,
Сайрашыйк әле дөнҗа калләрен,
Ниләр булганын.

**Алма бит**

Хозяйннар сезгә әйтәм
Можно терпеть итәргә.
Ал җаулык, алма бит,
Алма битләр кала бит.

Без килмәдек китәргә,
Килдек фарсит итәргә,
Ал җаулык, алма бит,
Алма битләр кала бит.

Алтын балдагым суга төшсә,
Үрел буең җиткәнче.
Ал җаулык, алма бит,
Алма битләр кала бит.

Җан сөйгәнең җатлар сәүсә,
Даулаш малың беткәнче.
Ал җаулык, алма бит,
Алма битләр кала бит.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Макарова Екатерина Павловнадан (1910 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Аппагым – күгәрчен**

Җөгереп җитә алсам,
Аппагым – күгәрчен;
Тал читәннәр сүтәлсәм,
Асыльяр – гөлгенәм.

Гомерем үтте ,димәс ием,
Аппагым – күгәрчен;
Шул матурны чиртәлсәм,
Асыльяр – гөлгенәм.

Өй түбәсе җәшел такта,
Аппагым – күгәрчен;
Кыек баскан күгәрчен,
Асыльяр – гөлгенәм.

Без дә атаның баласы,
Аппагым – күгәрчен;
Бәкыт юктыр күрәсең,
Асыльяр – гөлгенәм.

Ай туганда тулы була,
Аппагым – күгәрчен;
Беткән чакта кителә,
Асыльяр – гөлгенәм.

Икебез ике илләрдә
Аппагым – күгәрчен;
Аерым гомер итәбез;
Асыльяр – гөлгенәм.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Афанасьев Агафья Наумовнадан (1888 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

### Әй, безнең ил

Җырларга да кушсаң, мин җырларым,
Берне генә түгел икене.
Әй, безнең ил,
Бигрәк асыл җир.

Җырламаслар ием мин икене,
Җырла, дип әйтүең сөйкемле.
Әй, безнең ил,
Бигрәк асыл җир.

Ике генә күке кычкыра
Куш әрәмәне бер итеп.
Әй, безнең ил,
Бигрәк асыл җир.

Килче, кушарлашып җырлыек,
Торсын безнең Урдалы буе гөр итеп.
Әй, безнең ил,
Бигрәк асыл җир.

### Туганаем, туктале

Җырларга кушсаң, мин җырларым,
Җыру сатып алмыйм акчага.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.

Ай, сезнең кевек уңган кеше
Чәчсәк булмый бакчада,
Туганаем, туктале,
Туганаем китмәле,
Сайрашыйк әле.

Аягыңа кигән итегең,
Нәһис путау аның кыегы.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.

Безнең туганнарның чәч очлары
Пандуша кошының койрыгы.
Туганаем, туктале,
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк китмәле,
Сайрашыйк әле.

Алачлар күлмәк, аллар да булмас,
Бер акчалар безгә мал булмас,
Туганаем, туктале...
Туганаем, китмәле,
Сайрашыйк әле.
Бер дә беребезне кадерләшсәк
Газиз башларыбыз кур (*хур*) булмас.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Мария Ивановна (1915 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Ак атым аланчы**

Исле гөлләр күчерәм,
Исләренә исерәм;
Исләремнән чыгармыйча
Уйлап гомер кичерәм.

Ак атым – аланчы,
Күк атым – куянчы;
Тор, туган, уянчы,
Сөйләшиек туйганчы.

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем төрлесен;
Уйлама күңелем төрлесен,
Әллә ниләр күрерсең.

Ак атым – аланчы.
Күк атым – куянчы;
Тор, туган, уянчы,
Бу җырымны атап җырлыйм
Тула баскан кызларга.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйләҗев Сибгатьтән (1880 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Сәрвәридә агач кистем кыйгач,
Эчләреннән чыкты сандугач.
Син сандугач булсаң, мин карлыгач,
Сайрашырбыз бергә кич булгач.

Кашның каралары куш булмас,
Күзнең каралары буш булмас.
Җаннарың сөйсә, теләә Алладан,
Теләгән теләкләрең буш булмас.

Йөгерә-йөгерә генә җыярларга
Юлның буйларында юа юк.
Юалары бар да, җыйганнар юк,
Янган йөрәкләргә дәва юк.

Түтәл генә түтәл мәгем бар,
Мәгем арасында гөлем бар.
Сиңа җырламыйча кемгә җырлыйм,
Синнән якын минем кемем бар.

Сандык кына сандык сары алма
Түбәләмә түгел, сылама.
Биргән бүләкләрең кире кайтмас,
Күз яшьләрең белән җылама.

Түгәрәккәй күзең түгәрәтеп,
Ник карыйсың минем күземә.
Әйтер сүзең булса, әйт үземә,
Мин карамам кеше сүзенә.

Күкеләр кычкыра урманда,
Агач башы безгә ызба, дип.
Миңа җаныкаем шулай кушты:
Миннән башкаларны кысма, дип.

Ай-лай, Урдалының кызлары,
Аклы яулык бәйли үзләре.
Энҗеләрдән үк ак тешләре,
Сайланып ук чыга сүзләре.

*Керәүле районы Назаровка авылында*
*Алексеева Вера Васильевнадан (1919 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Алтыннар да йөзек койдырдым
Атсыз бармагымның атына.
Бу да җырлауларны без җырлыйбыз,
Казан кызларының хакына.

Сүрәкәне чиктем киргесез,
Киереп искәннәргә биргесез.
Син ярымны сөйдем сайламыйча,
Сайлап сөйгәннәргә бирегез.

Ишекләрдән керден айдаен,
Сыгылып сәлам бирдең талдаен.
Син туганайларым килеп кергәч,
Җаным эри сары майдаен.

Йөгереп үк төштем инеше, дип,
Инеш буйларында җимеш, дип.
Урдалы буеннан ярлар сөйдем,
Нәселегез асыл имеш, дип.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Архипов Павел Михайловичтан (1908 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Җирәнчеккәй атның ай ялларын
Кыйблалардан искән җил тарый.
Ай, үз бәхетләрең булмагачтын,
Байга гына эшләп кем ярый.

Җырларга җырлар табарбыз,
Яхшыларга юллар сабарбыз.
Безгә дошманнар каршы килсә,
Җавапларын үзебез табарбыз.

Башмагымның гына башы башка
Басмас кына идем ак башка.
Төшсә төшсен икән хәсрәт ташка,
Төшмәсен иде ул яшь башка.

Ай-һай ла дигән, ай, тавышка
Сусар керә суда камышка.
Чыдаса адәм чыдый икән
Эчләрендә тулы сагышка.

Сары сандугачның балалары
Ике генә булмый, өч була.
Кая гына барсак та, бер кояш
Күбәләк күк җанга көч була.

*Шенталы районы Тат. Абдикеево авылында*
*Гыймадиева Хәлимә Гыймади кызыннан (1865 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Җилбер дә генә җилбер, ай, йөрергә
Тау буйлары кебек җир булмас.
Кашың да гына кара, үзең зифа,
Синең кебек уңган ир булмас.

Агыйдел аша ла, ай, күп йөрдем,
Мәгълүм аның төбе таш кына.
Әллә дә генә яшьлек, әллә дәртлек,
Әллә нигә йөрәгем ашкына.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйләҗетдинов Гарифтан (1878 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Кулымдагы йөзегемнең
Кашын суга ташладым,
Бик сагынсаң, укырсың, дип,
Җырлар яза башладым.

Чылтыр-чылтыр чишмә ага тау башыннан чокырга,
Дустым, сиңа җырлар язам сагынганда укырга.

Пыяла шкаф эчләрендә кара белән каләмем,
Шушы хатым эчләрендә бара минем сәламем.

Чәч үргечем, чәч үргечем билдән түбән шикелле;
Их, дускаем, аерылабыз сак белән сок шикелле.

Әрәмәләр матур була шомырт чәчәк атканда,
Дустым, бигрәк сагынамын сызылып таңнар атканда.

Сиңа хатлар язган чакта ваттым кара шешәсен,
Татлы йокым арасында исләремә төшәсең.

Каз канаты матур була судан чыгып кагынгач,
Уң ягыма, суң ягыма карыйм сине сагынгач.

Куйбышевның урамы, буе озын, иңе тар,
Син дустымның нурлы йөзен бер күрергә интизар.

Ак иделнең агулары тирән ярны тигезли,
Үзем монда, күңелләрем син дускаемны эзли.

Аклы ситсы күлмәгемнең җиң очларыннан туза
5 минутның 3 минуты гел сине уйлап уза.

Ерлар язам, дустым, сиңа, син дә язарсың миңа;
Ерлар язып белдерәмен сагыну сәламем сиңа.

Өстәлләрдә грмафун уйный төрле көйләргә,
Хат эчендә телләр булмый сагыну хәлен сөйләргә.

Хатлар язып утырганда тибрәнде каләмнәрем,
Их, дускаем, сиңа китә ялкынлы сәламнәрем.

Чәйләр ясап эчәр идем, алтын чынаяк эридер,
Күзем йомсам, күз алдыма синең гәүдәң йөридер.

Базарларда сатыла микән зәңгәр тимерле каләм,
Зәңгәр чәчәкләрдән дә күп син дускаема сәлам.

Хатлар язам өстәлдә кичке сәгать 5 ләрдә,
Их, дускаем, хат яза күр исләреңә төшкәндә.

Кашың кара, күзең күк, сиңа сөйләр сүзем күп,
Сөйләр идем сүземне, сирәк күрәм үзеңне.

Җилфер-җилфер җил искәндә бөркән зәңгәр шәлеңне,
Таң җилләре искән чакта сораш минем хәлемне.

Күпер өсте күк томан, бу илләрдә күп тормам;
Күп торсам да, әз торсам да син кайтырсың, мин булмам.

Алмагачның алмасын, өзеп бетер калмасын,
Калса калсын безнең хәтер, сезнең хәтер калмасын.

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Гафурова Мәсхүдәдән (1987 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Аклы ситсы күлмәгемне
Кияргә дә кыймадым,
Хат эчендә барыр идем,
Хат эченә сыймадым.

Каеш камытлар килешә
Карат муеннарыңа;
Узең укы да утка як,
Бирмә ят кулларына.

Кара урманны чыккан чакта
Таптым бер яңгыз курай;
Кеше безне, горбиян, ди,
Безнең формабыз шулай.

Атна саен, почта саен
Хатлар көтәмен инде,
Сагынсам да, саргайсам да,
Сабыр итәмен инде.

Тәрәзәмнең фәрдәләрен
Җыям түгәрәк итеп;
Сагынмасам язмас идем,
Кәгазьләр әрәм итеп.

Тауга менсәм – тау биек,
Юлга төшсәм – юл кыек;
Таулар биек, юллар кыек,
Мәнем күңелем боек.

Киләп салам, киләп салам
Бер бөртеккә калганчы;
Озата чыгып карап калам
Күз керпегем талганчы.

Китәм, дуслар, китәм, дуслар,
Карурман эче беләң;
Бәйләп куялмаслар әле
Ак мамык җебе белән.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Шафиков Шәйхулладан (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Мөгерәп үк килгән тананың,
Сөте булмый, диләр, аларның;
Бер әнкәләрдән аерылгач,
Кадерләре булмый баланың.

Ишеккәйне ачып мин кердем,
Җан сәкеләрең җәшел буяулы;
Ай-һай, туганаем, сиңа әйтәм,
Син утырган җирләр җәмне.

Сатучылар тасма сатадыр,
Бәяләрен үзем түләрем;
Ай, сезләргә әҗәл килгән, дисәләр,
Сезнең өчен үзем үләрмен.

Җырakларда сайрый сандугач,
Якыннарга килгәч, сайрамый;
Сагынасызмы, дип сез сорыйсыз,
Сагынмагач, җөзләр саргаймый.

Ишеккәйдән кердем айдыен,
Сыгылып сәлам бирдем талдыен;
Читләрдән күрсәм дә, җаным эри,
Эреп торган сары майдыен.

Түгәрәккәй күлдә дүрләр үрдәк,
Аның берсе күлләр читендә;
Бүтән туганнарым бар да монда,
Бер туганым җирләр читендә.

Кара урманнарда качкыннар бар,
Кар җаумыйча аяк басмаска;
Безгә әтекәйләр шулай кушты:
Усалларга башлар кушмаска.

Биек тауны менгән чакта
Сызылып киткән юл булыр,
Җан сөйгәнең үзеңә булса,
Бәхетең башы шул булыр.

Сандугачның балалары
Ике була, өч була;
Сөйгәнен көтүчеләр
Авылларда әз була.

Урманнарга барсаң, бар сызгырып,
Урман күкрәкләре үкерсен;
Әй, җәрләрне сәүсәң, сәү сөйгәнен,
Сәүми калганнары үкенсен.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Мариядан (1907 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Чиләк кенә чиләк җирләр җиләк,
Ашый алмый калдым туксынып;
Бу да гомеремне мин уздырам
Сез туганнарымны җуксынып.

Кызыл гына кытат җиләнеңне
Караңгыда кисәң танырым;
Караңгылар ди бүк керми үтмә,
Каршы гына чыгып алырмын.

Җиләй генә җиләй җөргән чакта
Җилләр ачты минем куйнымны;
Инде генә шөкер дигән чакта,
Дошман кисте минем муйнымны.

Ындырларым тулы наратым,
Сарайларым тулы сары атым;
Җыгылганнар чакта таянырга
Сез булдыгыз минем канатым.

Җирән атым җитез булса,
Җикмә туры атыңны;
Белер-белмәс кеше артыннан
Җөртмә сәлам хатыңны.

Бер беләзеккәем беләктә,
Бер беләзегем келәттә;
Бирмәгәчтен, Алла бирми икән
Көнен генә, төнен теләп тә.

Күкләр дә күкри, җәшен җәшни,
Бардыр бер Кодайның пәлваны;
Алар да булмаса, бүтән бардыр,
Бер Кодайның җазганы.

Атларга утырсаң, ныклар чапма,
Кыл дилбегәләреңне нык какма;
Безне генә дисәң, безне сөйсәң,
Җокыларга китеп күп җатма.

Җиләккәйләр җыйдым җиңемә,
Очраса ием тиңемә;
Очрыйлар куйсам тиңнәремә,
Җөрер ием байлар җирендә.

Кыйгак кына кыйгак каз кычкыра,
Балаларын җуйган каздыр ул;
Үзе генә җырлый, күзе җылый
Ирексезләп биргән кыздыр ул.

Урам буе ызбада
Чигү чигә кыз бала,
Чигү чиккән кыз баланы
Алла бездән кызгана.

Җиделе лампа, җиделе лампа
Җана бүлмә уртасында;
Җиде уянып җиде торам,
Җиде төн уртасында.

Кара урманнарны әрчегез,
Әрчеп бодайлар да чәчегез;
Без дә болай булмас иек,
Бәйләнгәндер чәчебез.

*Келәүле районы Назаровка (Урдалы) авылында*
*Афанасьева Агафья Наумовнадан (1888 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Урдалы буенда без икебез
Чын гәрәбәләрне тезүче;
Шушы дөньяларда син генә бит
Безнең үзәгебезне өзүче.

Быел гына көннәр аяз килде,
Салкын чишмәләрдә коендым;
Сез туганнар килеп кергәч,
Җирем, күгем белән сөендем.

Биеккәй тауның башында
Алтын үлчи, диләр, бер җегет;
Алтын үлчәсә дә гадел үлчи,
Бардыр ул җегеткә бер өмет.

Урманнарга барсам, исем китә
Акландагы кызыл чәчкәгә;
Син туганаема өлеш куйдым
Алтын саплы көмеш чәркәгә.

Быелгы елның кызулыгы –
Тауның бит кенәе карала;
Сез туганнар белән күрешкәчтен,
Җыелган касрәтем тарала.

Очыгыз, казлар, очыгыз,
Безнең басуларга төшегез;
Безнең басу шау бодай,
Минем ышанганым бер Кодай.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Симуллина Анна Михайловнадан (1870 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Агыйделдән пароход килә, пароход күрми калабыз;
Яшь гомерләр үтеп бара, рәхәт күрми калабыз.

Биек тауның башында кычкырадыр бер бәрән,
Әллә бәрән, әллә адәм, үтә гомерләр әрәм.

Сандугачның, мескенкәйнең, канаты каерылган;
Бер без генә түгел инде иленнән аерылган.

Сандугачның баласы ике булмый өч була,
Җыен туган арасында атасызга көч була.

Сандугачның баласы ишле булса, биш була;
Сезнең кебек бай кешеләр кайчан безгә иш була.

Уйла күңелем, уйла күңелем, уйла күңелем төрлесен;
Уйлама күңелем төрлесен, Хак язганны күрерсең.

Урамда агач шартлыйдыр, куян вак-вак атлыйдыр;
Безне дошман ашар иде, бер Ходаем саклыйдыр.

Агыйделнең саендин басма салдым каендин;
Аккош күрсәң, миңа охшат, шулай булдым кайгыдин.

Аклы яулык башта тормый брошка кадамасаң;
Мин синеке, син минеке ятларга карамасаң.

Аклы алъяпкыч тектердем, бавы Казан бүзләре;
Ташлары түгел үзләре, керә дошман сүзләре.

Аклы яулык – затлы яулык, яраткан яулыккаем,
Яратмасам, сөймәс идем, яратам, җаныкаем.

Стенадагы сәгатьнең күтәреп куй герләрен;
Үлсәм дә сине эзләрем, тар булмаса гүрләрем.

Җилфер-җилфер җил селкетә, сахра җиле каенны,
Нинди шатлыклар булса да, баса алмый кайгымны.

Аклы ситса күлмәгемнең җиңе тар беләксәли,
Ал итәрбез, гөл итәрбез безнең кулга эләксәли.

Безнең турыдан казлар киткән түгәрәк күл кипкәнгә;
Сез дә шулай үкенәсезме яшь гомерләр үткәнгә?

Йөрәгемнең януына кирәк ефәк гөлләре;
Кирәкми ефәк гөлләре, яна торган көннәре.

Йөрәгемнең януына кирәк ефәк атласы;
Кирәкми ефәк атласы, яна торган атнасы.

Җанымны бер күргәндә күлмәге көрән иде,
Көрән күлмәк җаныемны күрмичә үләм инде.

Җаныемны бер күргәндә күзләре зәңгәр иде,
Күзләре дә зәңгәр иде, үзе дә зәһәр иде.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйззәтуллина Камиләдән (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

Атлар җигеп китәбез,
Атка зәвык итәбез;
Туган илне, нечкәй билне
Ташлап гомер итәбез.

Кышлар үтәр, җәйләр җитәр,
Яфрак ярыр җимешләр;
Кайтсын, диеп теләсеннәр
Безне белгән дус-ишләр.

Күкеле сәгать өсләрендә
Тора көмеш беләзек;
Кысып суырып үбәр идем,
Кызганам, биле нәзек.

Ай-һай, дуслар, сез кемнәр,
Калдыгыз бит, мескеннәр;
Ара ерак, китәм елап,
Кавыша алмабыз тиз көннәр.

Кара булды кошларым,
Күпне күрде башларым;
Уйсу җирдә түгәрәк күл
Минем түккән яшьләрем.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гарифуллин Шәйхулладан (1891 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Уеннар һәм уен җырлары

### Тычкан салыш

Тезелеп утыралар. Берәү кулына-учына әйбер йомарлап, йөзек салган шикелле учларга «салып» йөри, икенче кеше кырыйга китеп тора. «Салып» бетеркәч, утырганнар янына килеп «Рузалиядә» ди. Әйбер салынган кешене дөрес әйтсә, аның урынына әйберле кеше чыга, дөрес булмаса, яңадан кырыйга китеп тора, әйберне яңадан салганда икенче кешегә салалар. Шулай итеп ул кеше әйберне тапканчы «эзләүче» була.

### Мәче белән тычкан

Түгәрәккә тезеләләр. Песи түгәрәк тышында, тычкан эчендә була. Песи тычканны куа.

### Күз бәйләш

Түгәрәккә тезеләләр, ике кеше уртада кала, күзе бәйләнгәне тегене тотарга тели. Тотса, тегенең күзе бәйләнә.

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Гафурова Розалиядән (1951 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

### Чабата уены

Уртага бер казып кагып йеп бәйлиләр. Казык төбенә иске чабаталар өяләр. Уртадагы кеше шул йепнең очына тотынып түгәрәк әйләнеп йөри, уртага кешене китерми, ә кырыйдагылар, ул икенче якка борылган арада, чабаталарны алырга тырышалар.

### Алырмын кош

Бер-бер артлы күлмәк итәгеннән тотынып басалар, берәү аерым кала.

– Алырым кош.
– Бирмәм кош, –

дип тарткалашалар, бөтен балаларны арттан берәм-берәм ала бара.

### Көр йөгереш

Болында уйнала торган уен. Кара-каршы сафка тезеләләр. Кырыйдан берәү, мәсәлән, кыз, каршы рәткә таба йөгерә. Аның ар-

тыннан бер егет куа китә. Каршы якка барып җиткәнче тота алса, кыздан яулык ала да кире үз урынына алып кайта. Тота алмыйча каршы якта калса, бер егет янына, үзе теләгән булса кирәк, баса. Ул егет куучы егеткә «атың булса, нык тот иең» дип кала. Бу уенда кызларны гына куалар.

**Һаваларданиләр бар?**

– Бер-бер артлы итәктән тотынып басалар, алда берәү кала. Ул:
– Һаваларда ниләр бар? – ди.
– Төрле-төрле кошлар бар, – ди.
– Сандыгыңда ниләр бар?
– Балым белән шикәр бар.
– Алырмын кош, – ди аерым торган.
– Бирмәм кош, – ди.

Тотынганнарның башлыгы кошларны бирмәскә тырыша. «Кошлар»ны арттан чүпләп бетергәнче уен бара.

**Күкәй уены**

Ике башта сызык, уртада утыртып куйган таяклар. Берәү бер баштагы сызыкка аягын терәп, озын таяк белән таякларга бәрә. Таякны аударып, каршы сызыктан чыгарып җибәрсә, икенче, өченче (аударганчы) бәрә ала. Йыга алмаса яки йыгып та сызыктан чыгара алмаса, икенче кеше суга.

**Дыгырдык уены**

Җиргә кечерәк кенә круг сызыла, круг уртасына кечерәк кенә чокыр казыла. Круг уртасындагы кеше чокырга аркылы яткан кечкенә таякны озын таякка эләктереп ыргыта. Икенче кеше бу таякны круг эченә ыргыта. Кругка кертсә, уртадагы кеше белән урыннарын алмашалар да үзе ыргытучы була, кертә алмаса, керткәнче ыргыта. Ыргыту нормасы була. Мәсәлән, 15. Шушы ике кешенең кайсы нормасын алда үти, шул җиңүче була, тутыра алмаган җиңелүче була. Җиңелүче кеше 15 мәртәбә (алынган норма кадәр), кругтан чыгып, бер яклап сикереп килә (круг уртасыннан таяк ыргытыла торган урынга кадәр).

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбән Гатиятулла улыннан (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Бию такмагы**

Ядер гуа, гуа, гуа,
Гыймади буа буа,
Гыймади буа буганда
Сәлимә умач ува.

## Түгәрәк уен

Түгәрәккә басалар, җыр җырлыйлар:

Күпер генә башы күтәрмә,
Суның күбекләрен күтәрә.
Килләр дә уйныек, кил көлиек
Уен-көлке күңел күтәрә.

Агыйделкәйләргә җәймә җәйдек,
Җәймәләрем булды питәлә,
Исәпләми торсам, жук исемдә,
Исәпләсәм, исем китә лә.

## Аталыш уены

Ике сафка кара каршы басалар. Бер баштагы ике егет ике кызны алып китеп каршы сафта калдыралар, алар урынына икенче кызларны алып кайталар (кулга-кул тотынышып). Җырлары

Әй, егетсең, егетсең,
Суда йөзә торган сөлек син.
Әй, кашларың кар, буең зифа,
Кызлар сөя торган җегет син.

Чакырым җарымнан күренә
Зидәнчә атларның кашкасы.
Сагынганнар саен күрер ием
Ай-хай авылларның башкасы.

## Тәкә-тәкә уены

Парлап тезеләләр, алда берәү кала. Парлылар ике якка китеп йөгерәләр, алдагы кеше тотып калырга торыша, тота алмаган алда – «күтәргә» кала.

## Җулдан чыгыш

Пар-пар тезеләләр, алда берәү кала. Бер пар йөгерә (ике якта аерылып йөгерәләр дә сызыкта очрашырга тиешләр). Сызып куйган җулдан чыгып өлгерсәләр, икәү калалар; алдагы кеше тагын көтә, әгәр берәрсен тота алса, тоткан кешесе белән парлана.

## Нардуган

Яңа елга каршы төрле киемнәргә киенеп (картлар, карчыклар...) һәр өйгә кереп биеп йөриләр, алар белән скрипкачы да була. Һәр өйгә кергәч, «йөзек салырга кертмисезме» дип сорыйлар. Шул өйдә (ризалык бирелгән) өстәлгә сулы чиләк утырталар. Суны инештән 2–3 кеше чиләккә бистәр (*тастымал*) каплап алып менәләр. Чиләккә бөтен кеше үзенең йөзеген сала. Йөзек хуҗалары һәммәсе дә ниятлиләр. Бер кеше өләшче булып астына мендәр салып утыра. Һәр йөзекне чыгарганда җыр җырлыйлар. Өләшче йөзекләрне болгатып ала. «Бу кемнеке, җырчы кемдә» – ди. «Миндә», – ди, ниятләгән кеше. Бу җырны ел буена сыныйлар. Уен вакытында җыр җырлыйлар:

Уң бармагында уң йөзек,
Суң бармагымда суң йөзек;
Син туганаемны бик сагынгач,
Барып керердәй булам су йөзеп.

Җырдан соң йөзек иясе җыелган кешеләрнең олыларыннан сорый: «Бу җыр әйбәт булыр микән?» дип. Моңа төрле җавап була (үзләренчә «яхшыга юрыйлар» инде).

### Тройцын вакытындагы уен җырлары

Ай урынына айлар туса иде,
Җыл урынына җыллар туса иде;
Җыл урынына җыллар туса иде,
Җылгынае имин килсә иде.

Җауса иде җаңгыр, җауса иде,
Култыксадан тамчы тамса иде;
Ямьле Урдалының буйларына
Җаңгыр булып дәүләт җауса иде.

Ай туган инде, ай туган,
Айлар белән кояш тиң булган;
Айлар белән кояш кебек,
Без үзебез бертуган.

Шушы 3 җырдан соң урмандагы каен агачыннан чыбыкны кисеп, ике егет ике (2 чыбык) ягыннан (чыбыкның җуан башыннан) тотып авылга алып кайталар. Кайтканда авыл буенча 3–4 төштә биергә туктыйлар да, аннан тегермән алдына – буага (дәү суга) илтеп ташлыйлар – озаталар. Шуннан соң кире авылга кереп «тройцын» көенә «**Эчке зәр**» уенын уйныйлар. Зәрнең ике башыннан ике кеше тотып тора, башкалар астан чыгып торалар. Шушы вакытта җырлар җырлана:

Аклы гына җаулык алдырдым,
Җәйли бәйләүләрең калдырдым;
Иптәш кенә булып күп уйнадым,
Нинди көтерең‌не калдырдым.

Шулай уйный-уйный авылның бер башына барып җитәләр. Анда «**Җаулык алыш**» уенын уйныйлар. Озын бер рәткә пар-пар булып тезеләләр. Кырыйдагы бер парның берсенең кулында җаулык була. Ул җаулыкны кулдан кулга күчереп җөртәләр – җырлыйлар.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбән Гатиятулла улыннан (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

**Зария уены**

Таш ташыйлар, ком ташыйлар
Машина юлларына;
Алулары кыен булыр,
Бирмә ят кулларына.

Ай, зур-зария,
Вай, зур-зария

**Ай зар-зария**

Без үзебез казаннныкы
Бишбалта да өебез;
Җыен дуслар җыелышкач,
Җырлый торган көебез.

Ай зар-зария,
Төнге сәгать 12 дә
Килеп китәрмен әле,
Эчемдәге серләремне
Сөйләп китәрмен әле.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Егоров Павел Григорьевичтан (1932 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Кәҗә баш уены

Өч почмак ясап, өч баланы бастырып куялар. Шулар тирәсеннән зиг-заг ясап әйләнеп йөриләр.

Җырлары:

Быел җәйне мин җөридем
Печәнлек өләшергә,
Безгә генә җазган икән
Хат белән сөйләшергә.

Алда була, гөл дә була
Минем тәрәзә фәрдәм.
Мин җугалсам, эзләмәгез,
Суларда булыр гәүдәм.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Симуллина Анна Михайловнадан (1870 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## *Уен җырлары*

### Дулия (түгәрәк җыры)

Утырмый ла булмам инде
Алма коелган җиргә.
Ерламый да булмам инде
Дуслар җыелган җиргә.

Ай-ли, Дулия,
Дули-ли, Дулия.

Чәчәк аткан гөлләремне
Куямын урам якка.

Былбыл балалары кебек
Төрлебез төрле якта.

Ай-ли, Дулия,
Дули-ли, Дулия.

## Гөлнизар-генәем

Агыйделнең аръягында
Җәяү йөрисем килә.
Гөлнизар генәем дә,
На базар гуляем.

Сөясеңме, сөймисеңме,
Шуны беләсем килә.
Гөлнизар генәем
На базар гуляем?

*Похвистиево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Канюкаева Миңнекамәр Газиз кызыннан (1928 елгы),*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Дыр-дыр, дыр инде

Сирпелдереп карыйсың,
Түбән игән башларыңны
Ник күтәреп карыйсың.
Дыр-дыр, дыр инде,
Хәзер аның күңелләре
Синдә генәдер инде.

Карыйсың күзләремә,
Зәгыфыран сарылары
Җибәрдең йөзләремә.
Дыр-дыр, дыр инде,
Хәзер аның күңелләре
Синдә генәдер инде.

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Алиева Маһиҗиһаннан (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Каен бәйрәме җыры

Ай урынына айлар тусае (*туса иде*),
Көн урынына көннәр тусае.
Көн урынына көннәр туды инде,
Быел җәйләр ямьле булды инде.

Әй яусае яңгыр, яусае,
Култыксада тамчы тамсае.
Ямьле Урдалы буйларында
Яңгыр булып дәүләт яусае.

### Каен бәйрәменнән икенче җыр

Әй бәйлибез, кызлар ла, әй, бәйлибез,
Чушманың, әй, буйлары.
Ялан бер яулыкны, әй, бәйлибез,
Ялан бер яулыкны без бәйлибез,
Асау җәйләребезне җәйлибез.

И сарылы яулык, сарылы,
Аны сандыкларга салмагыз.
Дөнья булгач, була төрле хәл,
Аны гаепләргә алмагыз.

(Каен бәйрәме – троица – вакытында яшьләр, урманга барып, кызлар ике каенның башларын бәйләп, ике егеткә тоттыралар. Кызлар ул каенга төрле яулыклар бәйлиләр. Ике егет янында төрле җырлар җырлашып авылга кайталар. Авылда каеннарны суга ташлыйлар.)

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Мария Фоминичнадан (1907 елгы),*
*Алексеева Евгения Павловнадан (1892 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

### Түгәрәк җырлары

Әй, күкрәккәем күтәралмыйм,
Бадъян чугын бүләрлек булам.
Беләмсез, туганнар, хәлләремне,
Сезнең өчен үләрлек булам.

Җирнең җиләккәйләре пешкән чакта
Җирләр дә ярылырга җитешә.

Яшь гомерләр бездән узды инде,
Йөрәгем ярылырга җитешә.

(Түгәрәккә басалар. Егетләр түгәрәкнең бер яртысында, кызлар икенчесендә. Җыр беткәч туктап торалар. Җыр башлангач тагы китәләр).

**Ат алыш уены**

Әйдим, әйдим, ник бармыйдыр,
Болар нинди чаман алаша.
Әле күргәнемә күп түгелдер,
Болай сагындыра тамаша.

Кара урманнарны чыккан чакта
Калды камчыларым каерылып.
Камчыларым өчен мин үкенмим,
Калды туганнарым аерылып.

(Бер якта кызлар, каршыда егетләр тезелеп торалар. Ике егет килеп, бер кызны егетләр ягына алып китәләр. Икенче башта тагы ике егет шулай йөртәләр. Барысы да җырлыйлар).

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Тазова Устинья Степановнадан (1890 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Җырсыз уеннар

### Керигереш

Бер егет, бер кыз парлашып торалар. Бер парга «Һай-ну», диләр, алар йөгереп китәләр, сөйләшеп йөриләр. Аннан икенче парга әйтәләр:

«Һай-ну, җибәрмә,
Безнең кызлар чибәрме,
Безнең кызлар бик чибәр...».

Шулай дәвам итә.

### Тәңкә салыш, үбеп табыш

Түгәрәккә утыралар. Бер кеше тәңкә сала. Икенчесе эзли. Тапкан кешесен үбә, ялгыш булса, тагын эзли. Дөрес тапса, шул кеше чыга.

## Яшерен сергә чыгу

Яшьләр җыелып утыралар. Бер парны сайлап тышка, яшерен сергә чыгаралар. Алар кереп, икенче парны чыгаралар.

## Ресторан

Түгәрәк буенча берәү төрле исемнәр кушып чыга: кашык, тәлинкә, чәйнек һ.б. Аннан соң шулар исемен кушып әкият сөйли. Исеме чыккан кеше әйләнеп алырга тиеш. Әйләнми калса, җәза бирәләр.

*Келәүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбән Гатиятулла улыннан (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

## Бию такмаклары

Бие, бие, биештән,
Иреннәре көмештән.
Хәзер инде закон чыккан
Җырлый-җырлый биештән.

Кызым, биеп багыгыз,
Янчек төбен кагыгыз.
Янчектә акча булмаса,
Сорап эзләп табыгыз.
Сорап эзләп тапмасагыз,
Әвен сугып алыгыз.

Яңа ширпы кабы,
Иске ширпы кабы.
Быел алган итегемнең
Үкчәсе тузды тагы,
Каты биедем ахры.

Бие, бие, бие шулай,
Биегәнең веселай.
Синең арттан күрә-күрә
Без дә биербез шулай.

Ары да барып биисең,
Бире дә килеп биисең.
Бигрәк оста да биисең,
Күз тияр дип белмисең.

Бас, бас, бас әле,
Без дә басарбыз әле.

Урындыкта гарнитур,
Ары утырма, бире утыр.
Синең өчен яшен түгә
Аргы очта бер матур.

Ишек алдым бораем,
Салкын белән ураем.
Кершән сөрткән шадраны
Жаным сөйми, Ходаем.

Цылтыр-цылтыр Мәликә
Чәй саладыр чәйнеккә.
Ун көлтәгә бер көлтәне
Ничек бәйләп өлгертә.

Берәр олы кешене кечкенә бала чакырырга килсә, аңа әйтәләр:

Аягың күчәркә,
Башың пумала,
Кулың грәблә –
Синнән зурраклар килсен.

*Похвистнево районы Иске Мәчәләй авылында*
*Алиева Маһиҗиһан (1909 елгы)*
*Ф. Әхмәтова язып алган. 1965 ел*

Бие, бие, Абдулла,
Ник торасың аптырап,
Суга төшкән чебеш кебек,
Ник торасың калтырап.

Бие, бие, биештән,
Икебезгә бер штан.
Утын киссә – ул кия,
Суга барсам – мин киям.

Биюченең итәгенә
Гөлҗимешләр җабышкан.
Биюче белән сандугач
Аякларын алышкан.

Бие, бие, бие әле,
Биегәнең юк әле;
Синең биегәнең булса,
Минем күргән юк әле.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Митрофанов Семён Герасимовичтан (1911 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел.*

Гали Фатыймасыннан,
Хөсни Хәтимәсеннән,
Хәдичә абыстай егылып төшкән
Шәрип эләүкәсеннән.

Садыйк ишәдер аркан,
Хәдичә килеп тарткан;
Эләүкәдән егылып төшкәч,
Авыртмадымы аркаң?

Гыйлемзада, Минзада
Кич утыра мунчада;
Әйттереп кал, типтереп кал,
Бик әз генә булса да.

Әйттерче, Хәери,
Әпәй саткан акчаңа,
Икәүләшеп әйттерәләр
Кырмавыклы бакчада.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйззәтуллина Камиләдән (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Бишек такмаклары

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала;
Атасына, анасына
Хезмәт итәр бу бала.

Атасы дегет чүлмәге,
Анасы күмер чүлмәге;
Андин туган кыз баласы
Пешкән кура җиләге.

Әрес, бәрес, пичтә бәлеш,
Аша да кит,
Балакаем, йокыга кит.

*Шенталы районы Денис авылында*
*Гыйззәтуллина Камиләдән (1902 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Бишек такмагы
(*балалар фольклоры*)

Әлли, әлли, бәбием,
Җокла, җокла, Гөлием;
Җокламасаң, Гөлием,
Өстеңә ни җабыем.

Әлли, әлли, Гөлием,
Бәлли итәр Гөлием;
Иртә җатып, соңга калсак,
Ни җаваплар табыем.

Әлли, әлли, әнкәсе,
Ник җокламый бәбкәсе?
Җокларие бәбкәсе,
Җокларие бәбкәсе
Имчәк бирми әнкәсе.

*Келәүле районы Назаровка авылында*
*Афанасьева Агафья Наумовнадан (1888 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Сүз уйнатулар

Карамалы картка чана карамалатырга биргән идем, карамалады микән, карамаламады микән. Карамаласа да алып кайт, карамаламаса да алып кайт.

* * *

– Кая барасың?
– Чабата башына.
– Әбәбең (сәбәбең) нәрсә?
– Бер ацы күмәц тә, бер төце күмәц тә умац.
– Атаң кем?
– Тамац.

* * *

Безгә мишәрләр килгән, киндер тукмаклашмаслар микән?

* * *

Арба өйдән чыкканда:
– Майламадың ла, майламадың ла, – дип бара икән.
Таудан төшкәндә:
– Хоть майлама, хоть майла,
Хоть майлама, хоть майла, – ди.
Тигез җирдә юрттырганда:
– Малайсаң да барам,
Майламасаң да барам,
Майласаң да барам,
Майламасаң да барам, – ди икән.

* * *

Безнең заманда,
Кәҗә команда,
Сарык сабанда.
Барам да, капканы ябам да,
Керәлмичә калам да.

* * *

Авыл очы сукыр Котдус,
Аның бу ягы Тыртара,
Тыртара, чабатасын кайтара.

* * *

Таз, таз, Тазина,
Төшмә әвен базына,
Әвен базы бик тирән,
Чыга алмассың таз бирән.

*Keләүле районы Иске Ярмәк авылында*
*Әхмәдуллин Сәүбән Гатиятулла улыннан (1909 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Табышмаклар

Агач түгел яфраклы.
Тун түгел тегелгән. (*Китап*)

Шәһәре бар, кешесе юк,
Диңгезе бар, суы юк. (*Карта*)

Канаты бар, йоны юк,
Үзе бара, юлы юк. (*Самолет*)

Безнең өйдә ут яна,
Аның мае елгада,
Белсәң нәрсә икәнен,
Әйтеп бирче миңа да. (*Электростанция*)

Ары лап-лап, бире лап-лап,
Сөңге саплап, киез каплап. (*Токмач җәю*)

Мич алдында бер комган,
Авызын-күзен йомган. (*Яшь килен*)

*Похвистнево районы Яңа Мансур авылында*
*Гафурова Розалиядән (1951 елгы)*
*Х. Гатина язып алган. 1965 ел*

## Мәкальләр

Җырның ертыгы юк,
Ямасаң җөе юк.

Сүз сүзне чыгара,
Йодрык күзне чыгара.

Язык казык башына,
Җавап алла каршына.

Иртә намаз, кич намаз,
Каккан казыгың калмас.

Кеше үлсә, мулла симерә.

Бик күп белсәң асарлар да кисәрләр,
Уртача белгәнне ил агасы ясарлар,
Бер дә белмәсәң, ил арбасы ясарлар.

Балта чапканчы кискә ял итә.

Сиңа биргән акчаны багур белән су төбеннән эзләргә
(ышанычсыз кеше турында)

Яхшы ат аягыннан симерә,
Начар җитәкче колагыннан симерә.
(ат симерсә – яхшы тарта, җитәкче симерсә,
кеше сүзен ишетми – бюрократ).

Ашадык ботка, эшләр китте ходка.

Кешегә бәйрәм дә, хайванга әйран.

Аюга да 40 елга бер бәйрәм була, ди.

Башыңны сат та мине ашат, дип әйтә ди үрдәк.

*Бу мәкальләрне Куйбышев өлкәсе авылларында*
*төрле кешеләрдән Х. Гатина язып алган. 1965 ел*


Коле 77
п 1
ед.хр. 14 (бет 12)

Үен җырлары-уеннар 4,
такмаклар – 12.
Бәетләр – 4.

ТЕТРАДЬ
1965 елда Куйбышев
өлкәсендә язып
алынган җырлар.
КИЯЛИ фольклор экспедициясе.
Язып алучы: Ф. Ахметова.
Июнь.


2. Ат алыш уены. 4
(кое алганда).
[illegible]
Кара урманнарны чыккан чакта
[illegible]
(Бер якта кызлар, каршыда егетләр тезелешеп торалар. Ике егет килеп, бер кызны егетләр ягына алып китәләр. Икенче башка тагы ике егет шулай итеп [illegible]).
Бу уеннарны әйтүче Тазова Усгиния Степановна, 1890 елгы.
Назаровка авылы, Клявлино р-ны.

Фольклор экспедициясе вакытында язып алынган материаллар (1965 ел, июнь. Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсе. Ф. Әхмәтова). (77 кол., 1 тасв., 14 сакл. бер.)


Коле 77
п 1
ед.хр. 20 (бет 12)

Туй җырлары – 84.

ТЕТРАДЬ №3
1965 елда Куйбышев
өлкәсендә язып
алынган җырлар.
КИЯЛИ фольклор экспедициясе. Июнь.
Язып алучы: Ф. Ахметова.


5. Француз [illegible]
[illegible]
6. Кара сыерларның каймагын
Каерып алырга килдек без
Әнкәйләренең бәбкәсен
Аерып алырга килдек без.
7. [illegible]
Ялмаенча китәр димәгез
Алырга килгән кызыбызны
Алмаенча китәр димәгез.
8. [illegible]
Югалмасын ара баласы.
9. [illegible]
Кыз алырга дип [illegible] без килдек.

Фольклор экспедициясе вакытында язып алынган туй җырлары дәфтәре (1965 ел июнь. Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсе. Ф. Әхмәтова). (77 кол., 1тасв., 20 сакл. бер.)



мәкаль, табышмак
мәкаль – 26
табышмак – 8
тәрмәләр – 9

ТЕТРАДЬ
СССР Фәннәр Академиясе
Казан фил., әдәбият һәм
тарих институтының
фольклор экспедициясе.
Куйбышев өлкәсе.
1965 ел.
Язып алучы Х. Гатина.



Мәкальләр



авыл тарихы – 6
истәлек – 6
легенда – 2

ТЕТРАДЬ
для
СССР Фәннәр Академиясе
Казан фил., әдәбият һәм
тарих институтының
фольклор экспедициясе.
Куйбышев өлкәсе.
1965 ел.
Язып алучы Х. Гатина

1965 елның июнь аенда Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсе татарларыннан язып алынган мәкаль-табышмаклар дәфтәре. Экспедиция җитәкчесе – Ф. Әхмәтова, язып алучы – Х. Гатина. (77 кол., 1 тасв., 23 сакл.бер.)



Яңа Мансур авылы турында.

Фольклор экспедициясе вакытында язып алынган авыллар тарихы, легендалар дәфтәре (1965 ел, июнь. Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсе. Х. Гатина). (77 кол., 1 тасв., 21 сакл. бер.)



бәетләр – 5
такмак – 1

Рукописный фонд
коп. 77
ед. хр. 28 (бит 12)

ТЕТРАДЬ

СССР Фәннәр Академиясе
Казан фил., әдәбият һәм тарих институтының
фольклор экспедициясе.
Куйбышев өлкәсе.
1965 ел.

Язып алучы Х. Гатина



(Ватан сугышы бәете)

Җәйнең ямьле чакларында
Герман сугыш башлаган,
Әткәйне үтерер өчен
Герман бомба ташлаган.
Рәхәтә ускан идем
Әткәм бар чагында.
Безнең әткәй чыгып китте
Олауларга утырып,
Әткәмне озатып без
Күзләрдә яшь тутырып.
Безнең әткәй киткән чакта
Кара бишмәтен киде,
Шаять кайтырмын диде.
Әткәмә хәбәр килде

1965 елда Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсендә язып алынган бәетләр. Язып алучысы: Х. Гатина. (77 кол., 1 тасв., 28 сакл. бер.)





1965 елда Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсе Келәүле районы авылларында язып алынган кыска җырлар (77 кол, 1 тасв., 18 сак.бер.) һәм мәзәкләр (77 кол., 1 тасв., 8 сакл. бер.) дәфтәрләре. Язып алучысы: Ф. Әхмәтова

1965 елда Куйбышев өлкәсендә
1) җыйган матер

| Өлкә, район, авыл. | Танышылган кешенең исеме, фамилиясе | Туган елы | Белеме | Профессиясе | Партийность |
|---|---|---|---|---|---|
| Куйбышев өлкәсе, Похвистнево р-ны, Иске Мәнчәр авылы. | Мамышева Хәкимә Шакировна | 1903 | укый-яза | пенсионер колхозчы | — |
| " | Булатова Шәмсенур | 1902 | " | " | — |
| " | Яхина Фатыйма Алиевна | 1905 | " | " | — |
| " | Исаева Зәкия Юсуповна | 1927 | 7 еллык | колхозчы | — |
| | Сапукова Миңсылу | 1914 | аз грамот. | " | — |
| " | Мурафова Нурҗиннәт Сибгатовна | 1924 | урта | библиотекарь | — |
| " | Канбокаева Миннекамар Газизовна | 1928 | 7 еллык | колхозчы | — |
| " | Алиева Мәхинҗиһан | 1909 | укый-яза | " | — |
| " | Аитова Шәмсерух | 1908 | " | " | — |
| " | Мамышева Разия | 1946 | урта | " | комсомол |
| Куйбышев өлкәсе, Похвистнево р-ны Яңа Мансур авылы | Шәмсетдинов Гыйльман | 1886 | аз грамот. | колхозчы | — |
| | Сагиров Касыйм Закиров | 1900 | урта | союзное пенсионер | партийный |
| | Сәйфетдинов Мөхәммәтҗан | 1881 | грамотасыз | колхозчы | — |
| | Гафурова Мәсгудә | 1937 | 6 класс | " | — |
| | Бухарметова Хәдичә | 1909 | аз грамота. | " | — |
| | Ихсанов Ярмөхәммәт | 1876 | " | " | — |
| | Ихсанова Лотфия | 1900 | " | " | — |
| | Галиуллина Зөләйха | 1932 | 7 класс | " | — |
| | Латыйпова Ләтыйфә | 1940 | 7 " | " | — |
| | Гафурова Розалия | 1951 | 7 класс | | |
| Куйбышев өлкәсе, Клявлино р-ны Иске Ярмәк авылы | Салахова Миннеса | 1912 | аз грамотлы | " | — |
| | Шәфиков Шәйхулла | 1902 | " | " | — |
| | Хәмдуллин Әмулла | 1889 | урта | пенсионер почта җитәкче | партийный |
| | Сәлимова Бәдриҗамал | 1892 | аз грамот. | колхозчы пенсионер | — |

Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсенә оештырылган фәнни экспедициянең (1965) бер отряды башкарган эш турында хисап. Отряд җитәкчесе – Ф. Әхмәтова, отряд әгъзалары – Х. Гатина, А. Йосыпов



1

...ольклор экспедициясенең бер отряды
...аллар турында отчет.

Отряд: Ф. Ахметова, Х. Гатина, А. Юсуповлар.
җыелган материаллар.

| җырлар | әкият-анекдотлар | бәет | сюжетлы җыр | уен җырлары | мәкаль табышмак | балалар фольклоры | [illegible] | Төрле... |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 – | – | – | 1 | – | – | – | 1 | |
| 4 – | – | – | 1 | – | – | – | – | |
| 9 | – | 1 | 1 | – | – | – | 1 | 2 |
| 10 | – | – | 2 | – | – | – | 3 | |
| 10 | | | | | | | 2 | |
| – | – | – | 1 | 1 | – | – | 2 | |
| – | – | 1 | – | 2 | – | – | | |
| | | | – | 1 | 2 м | 1 | – | 12 [illegible] |
| 60 | – | – | – | – | 1 м | – | – | |
| 170 | – | – | – | – | – | – | – | |
| 163 | – | – | – | – | | | | 2 [illegible] |
| | | | | | | | | 4 [illegible] |
| | | | | | | | | 1 [illegible] |
| 32 | | | 1 | | | | | |
| | | | 1 | | | | | |
| | | | 1 | | | | | |
| | | | 1 | | | | | |
| 4 | | | 1 | | | | | |
| 4 | | | | | | | | |
| | | | 1 | | | | | |
| 45 | | | | | | | | |
| 8 | 2 [illegible] | | | | | | | |
| 15 | | | 1 | | | | | |

2)

| Өлкә, район, авыл | Таныштырган кешенең исеме, фамилиясе | Туган елы | Белеме | Профессиясе | Партиялелеге | Эшч |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Куйбышев өлкәсе Клявлино р-ны Иске Ерметә авылы | Әхмәдуллин Сәүбән Галиәхмәтулла улы | 1909 | урта | библиотекарь | партияле | |
| " | Әхмәдуллина Энҗә | 1921 | югары | укытучы | партиясез | |
| " | Зиннуллина Гыйльмиҗиһан | 1902 | аз грамот. | колхозчы | " | 28 |
| Клявлино р-ны, Камышла авылы | Зәйнуллина Кәримә | 1909 | урта | колхозчы | " | |
| " | Абдуллина Зөләйха | 1939 | урта | медсестра | комсомол | |
| " | Туктарова Мәгъшүрә | 1915 | аз грамот. | колхозчы | партиясез | 6 |
| " | Мингазова Шәмсебәдәр | 1895 | " | " | " | 8 |
| " | Бәдретдинова Мәрьям | 1902 | 3 класс | " | " | 6 |
| Клявлино р-ны Балыкла авылы | Фәхретдинова Хәйрелвафа | 1887 | грамотасыз | – | – | |
| " | Шәмсетдинова Фәхирә | 1913 | 2 класс | колхозчы | | 4 |
| " | Насырова Вәсилә | 1900 | аз грамот. | " | " | |
| " | Вакиров Вәли Закирович | 1913 | урта | авыл советы председ. | партияле | 3 |
| " | Шәрәфетдинов Бурhан | 1927 | 5 класс | колхозчы | партиясез | |
| " | Нуриев | | | | | 3 |
| Клявлино р-ны Назаровка авылы | Алексеева Евгения Павловна | 1892 | грамотасыз | колхозчы пенсион. | " | 9 |
| " | Тазова Устинья Степановна | 1890 | " | " | " | |
| " | Тазова Мария Фоминична | 1907 | аз грамот. | " | " | 75 |
| " | Тазова Анна Ивановна | 1911 | " | " | " | 19 |
| " | Архипов Павел Михайлович | 1908 | грамоталы | лесник | " | 5 |
| " | Клементова Анна Захаровна | 1910 | " | колхозчы | " | |
| " | Тазова Анна Васильевна | 1913 | " | " | " | 4 |

Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсенә оештырылган фәнни экспедициянең (1965) бер отряды башкарган эш турында хисап дәвамы

Җыелган материаллар

| Җыр мәзәк | Бәет | Сюжетлы җыр | Чын җырлар | Мәкаль табышмак | Балалар фольклоры | Мәгънә төрле | Төрле |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14 мәз. | | | 14 [illegible] | | | | 2 [illegible] 8 [illegible] |
| | 1 | | | | | | 1 |
| | | 1 | | | | | |
| | 1 мон. | 3 | 1 | | | 3 | |
| | | | 1 | | | 1 | |
| | | 4 | | | | | |
| | | 2 | | | | | |
| | | 1 | | | | | |
| | | 1 | | | | 1 | |
| | 1 | [illegible] | | | | 1 | 4 [illegible] |
| | | | | | 4 мәз. | 1 | |
| | | 1 | | | | 1 | |
| | | | 2 | | | | |
| | | 8 | 2 | | | 10 | |
| | | 6 | [illegible] | | | 5 | [illegible] |
| | | 5 | [illegible] | | | 5 | |
| | | 4 | | | | | |
| | | 1 | | | | | |
| | | 2 | | | | | |

31

| Өлкә, район, авыл | Табылган кешенең исеме, фамилиясе. | Туган елы | Белеме | Профессиясе | Партиялеге | Җыр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Куйбышев өлкәсе Клявлино р-ны Назаровка авылы. | Алексеева Вера Васильевна | 1919 | аз грамоталы | колхозчы | партиясез | 22 |
| | Макарова Анна Васильевна | 1913 | " | " | " | 19 |
| | Егоров Григорий Ермолович | 1896 | " | " | " | 116 |
| | Афанасьева Агафья Наумовна | 1888 | грамотасыз | " | | 43 |
| | Егоров Павел Григорьевич | 1932 | 5 класс | " | " | |
| | Макарова Екатерина Павловна | 1910 | грамотасыз | " | " | |
| | Силушина Анна Михайловна | 1870 | " | " | " | 10 |
| | Митрофанов Семен Герасимович | 1911 | 4 класс | ферма мөдире | " | |
| | Андреева Анна Фоминична | 1902 | грамотасыз | колхозчы | " | 23 |
| | Петрова Екатерина Зиновьевна | 1916 | грамоталы | " | " | 15 |
| | Митрофанова Анна Фоминична | 1909 | грамотасыз | " | " | 10 |
| | Тазова Мария Ивановна | 1915 | " | " | " | |
| Шенталы р-ны Тат. Абдикеево авылы | Нуркаева Әҗилә | 1916 | аз грамоталы | " | " | |
| | Гимадиева Хәлимә | 1865 | грамотасыз | " | " | 12 |
| | Мортазина Фатыйма | 1909 | " | " | " | 16 |
| | Магдиева Рәхилә | 1946 | 7 класс | " | комсом. | 19 |
| | Гилязов Сибгат | 1880 | грамотасыз | " | партиясез | 12 |
| | Сәлимзянов Газимзян | 1898 | " | " | " | |
| | Зулкарнаев Хади | 1932 | 7 класс | " | " | |
| Шенталы р-ны Денис авылы. | Тимергалиева Закира | 1909 | грамоталы | " | " | |
| | Миңнанов Низаметдин | ? | ? | дәфтәрдән. | | |
| | Гыйззәтуллина Фатыйма | 1925 | 5 класс | " | " | |
| | Гыйззәтуллина Камилә | 1902 | грамотасыз | " | " | 38 |
| | Мансуров Гатаулла | 1898 | урта | укытучы пенсионер | " | |
| | Хаганшин Харисти | 1924 | 9 класс | с/с председ. | партияле | |
| | Нигъмәтуллин Әлимҗан | 1929 | югары | мәктәп директоры | " | |
| | Нурмухаметов Җәвит | 1931 | " | колхоз рәис. | " | |
| | Гилязетдинов Гариф | 1878 | грамотасыз | колхозчы | партиясез | 4 |
| | Гарифуллин Шәйхулла | 1891 | грамоталы | " | " | 12 |

Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсенә оештырылган фәнни экспедициянең (1965) бер отряды башкарган эш турында хисап ахыры

Җыелган материаллар

| Җыр, мөнәҗ. | Бәет | Сюжетлы җырлар | Чын җырлар | Мәкаль табышмак | Балалар фольклоры | Мәгънә бәйрәм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 13 | | | | | | |
| | | 1 | | 4 мәк. | | | | |
| | | 2 | 7 | | 1 | | | |
| | | 1 | 2 | | | | | |
| | | 7 | | | | | | 5 такмак |
| | | | 1 | | | | | |
| | | | | | | | | 5 такмак |
| | | 6 | | | | | | |
| | | 1 | | | | | | |
| | | 1 | | | | | | |
| | | 3 | | | | | | |
| 3 мөн. | | 1 | | | | | | |
| | | | | 10 мәк. | | | | |
| | 1 | | | | | | | |
| 2 [illegible] | | | | | | | | |
| | | 3 | | | | | | |
| | 1 | | | | | | | 1 такмакча |
| | 1 | | | | | | | 6 [illegible] |
| | 1 | | | | | | | |
| | 1 | | | | | | | |
| | 1 | | | | | | | |
| 4 мөн. 5 мөн. 6 мөн. 3 мөн. 1 мөн. | | 3 | | 14 мәк 8 таб. | | | | |
| 2/38 | 11 | 94 | 34 [illegible] | 34/8 | 2 | 37 отряд җырчысы [illegible] | | |

## Авторлар турында кыскача белешмә

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы** – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Булатова Миңнира Рәхим кызы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Галимов Салават Фәрхәт улы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Мөхәммәтшин Рөстәм Зәки улы** – геология-минералогия фәннәре докторы, Геология һәм нефть, газ технологияләре институтының (Казан федераль университеты составында) А.А. Трофимук исемендәге нефть һәм газ геологиясе кафедрасы доценты.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Шкляева Людмила Михайловна* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

**ЭЧТӘЛЕК**

КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6

ТАШЛАРГА УЕЛГАН ГОМЕРЛӘР
*Марсель Әхмәтҗанов*
26

ЭСПЕДИЦИЯ ТАБЫШЛАРЫННАН:
кульязмалар һәм китаплар хакында
*Салават Галимов*
44

ТУГАНДАШЛАР ТЕЛЕ ЯКЫН КҮҢЕЛГӘ
*Дария Рамазанова*
50

ҖИРЛЕ СӨЙЛӘШЛӘР ҺӘМ ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ
*Флера Баязитова*
63

САМАРА ТАТАРЛАРЫНДА ЗАМАН ФОЛЬКЛОРЫ
*Лилия Мөхәммәтҗанова*
100

ТАТАР УЛ КАЙДА ДА БАЛКЫП ЯШИ
*Ильмир Ямалтдинов*
127

О МУЗЫКАЛЬНОМ ФОЛЬКЛОРЕ ТАТАР
САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ
*Гузель Юнусова*
181

ОСОБЕННОСТИ НАРОДНОГО
ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОГО ИСКУССТВА
ТАТАР САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ
*Людмила Шкляева*
194

ФИЗИКО-ГЕОГРАФИЧЕСКАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА КРАЯ
*Рустам Мухаметшин*
220

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
*Миңнира Булатова*
225

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**

**ТАТАРЫ САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ**

2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**

**САМАРА ӨЛКӘСЕ ТАТАРЛАРЫ**

2 нче басма

Редакторлар *Я.М. Абдулкадырова, Л.Ш. Давлетшина*
Корректор *Л.Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*
Китапта *С.Ф. Галимов, Л.Х. Мөхәммәтҗанова, Р.З. Мөхәммәтшин, Л.М. Шкляева, И.И. Ямалтдинов* фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021
Форматы 60×84 $^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 17. Шартлы басма табагы 22.
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20